МИРАС

ЧЫН

ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№7/сентябрь 2012

Милли үзаң һәм мәгариф сәясәте

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ тууына 125 ел

ТАРИХИ, ӘДӘБИ, МӘДӘНИ МИРАС, ТӘНКЫЙДИ ФИКЕР, ЗАМАН ӘДӘБИЯТЫ, ЯҢАЧА КАРАШ

МЕДАЛЬ ЗА КАЗАНСКУЮ
ВЫСТАВКУ 1890 г.
А. Шумиловъ Казань.

МИРАС
ЧЫН
ФӘННИ-ПОПУЛЯР,
ӘДӘБИ-НӘФИС ЖУРНАЛ
№2-3 / ИЮНЬ 2012

Эчтәлек

ТАРИХ

10 **Татарлыгыбыз сагында.** *Индус Таһиров*
14 **Үткәнебез сәхифәләрен барлап...** *Рафаил Хәкимов белән Илдус Заһидуллин әңгәмәсе*
23 **Ак сөлге.** *Ренат Харис*
24 **1812 елгы Ватан сугышында һәм 1813-1815 еллардагы рус армиясенең Чит ил походларында татарлар.** *Илшат Фәйзрахманов*
31 **Бөтендөнья Сабан туйларының башкаласы — Казан!** *Равил Рахмани*
32 **«Кадимчеләр дийарыннан» бер әсәр.** *Әлфинә Сибгатуллина*
41 **Җыен сүзе.** *Лена Шагыйрьҗан*

ӘДӘБИЯТ

44 **Нәзыйрәчелектән — интертекстуальлеккә-әңгәмәдәшлеккә таба.** *Резеда Ганиева*
54 **Шагыйрь Һәмдәми яки Мелла Мамай.** *Марсель Әхмәтҗанов*
62 **Һәмдәминең «Нәсыйхәтнамә»сеннән үрнәкләр**
66 Йөрәк җырлый. *Флера Гыйззәтуллина*
68 **«Унҗиденче елның алдында уяндык без көлеп...»** *Фәридә Хәсәнова*
76 **Шигырьләр.** *Әбрар Сәгыйди*
80 **Якташларыма бәйрәм.** *Фәнис Яруллин.*
81 **Уйгану вә яңалык тарихы.** *Ризаэтдин Фәхретдин*
95 **Батыр тәкә.** *Шамил Маннапов*

БӘЙРӘМНӘРЕБЕЗ

98 **Тамырлар кая тоташа?** *Гамирҗан Дәүләтшин*
107 **Чабыш атлары.** *Салисә Гәрәева*
108 **«Сабан туе — безнең туй, сөлге-яулык сайлап куй».** *Рамил Ханнанов*
121 **Ул заманда.** *Ирек Сабиров*
122 **Федераль Сабантуй: тәҗрибә һәм үсеш перспективасы.** *Фәрит Уразаев*
133 **Сабан туенда.** *Рәшит Әхмәтҗанов*
134 **Катыктан акча эзләү.** *Зиннур Мансуров*
135 **Җыеннар.** *Закир*
140 **Казанда үтә торган Сабантуй бәйрәме — XIX гасыр рус газеталары битләрендә**
144 **Сабан.** *Карл Фукс*
149 **«Каенлыкта бүген Сабан туе...»** *Әхмәт Рәшит*
150 **Сабан туенда.** *Фатих Әмирхан*
154 **Алып батыр уллары.** *Газинур Морат*
155 **Ярыш.** *Рабит Батулла*
165 **Сабантуй булып узган мәйданда.** *Харрас Әюп*

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР
168 **Сүз ул — гәүһәр.** *Тәлгат Галиуллин*
173 **Иле иркеннең көне иркен.** *Гүзәл Нәбиуллина, Лилия Гыйләҗева*
178 **Яшә, Сабан туе!** *Лена Шагыйрьҗан*

ХУШЛАШУ
184 Шәүкәт Биктимеровны озату мәрәсимендә Роберт Миңнуллинның ясаган чыгышы
186 **Сабантуй.** *Мөхәммәт Мирза*
188 **Яңа китаплар**
191 **Тарих сәхифәләреннән**

Журнал «Татмедиа» ААҖ тарафыннан гамәлгә куелды.

Баш мөхәррир —
Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ

Редакция советы:
Марсель Әхмәтҗанов, Разил Валиев, Резеда Ганиева, Фәнзилә Җәүһәрова, Ринат Закиров, Дания Заһидуллина, Илдус Заһидуллин, Данил Ибраһимов, Ким Миңнуллин, Данил Мостафин, Рөстәм Мөхәммәдиев, Рафыйк Мөхәммәтшин, Гөлчәчәк Нәҗипова, Индус Таһиров, Рамил Ханнанов, Рафаил Хәкимов

Иҗат төркеме:
Илфак Ибраһимов, Рамил Ханнанов, Илдус Заһидуллин, Диләрә Нәүрүзова, Ренат Минигалиев, Ландыш Әбүдәрова, Лилия Гәрәева

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Телефон: (843) 222-09-83
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: 420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт

Заказ №6943.
Тираж — 2000 данә.
Формат 70 X108 $^{1}/_{16}$
Журнал айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды: 15.06.2012

Мәкалә авторларының фикере редакция хезмәткәрләренең фикере белән туры килмәскә дә мөмкин.

Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә.

Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.

Бу санда авторларның, Р.Якупов, Р.Әхмәтов, М.Шакирҗанов, Г.Хафизов, В.Туник, И.Латыйфуллин, В.Зотов, Л.Кузнецова һәм А.Эшкинин, ТРның Үзәк дәүләт архивы, Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, Халыклар дуслыгы йорты архивларыннан фоторәсемнәр файдаланылды.

Тышлыкның 1 нче битендә - Каенлыкта узган Казан Сабан туе. 1985 ел. М.Шакирҗанов фотосы; **2 нче битендә** - Болгар Җыены. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты архивыннан; **3-4 нче** битләрендә Р.Якупов фотолары.

Бөтенроссия «Белем көне» бәйрәме уңаеннан Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миңнеханов МӨРӘҖӘГАТЕ

Кадерле дуслар!

Укучыларны һәм студентларны, аларның ата-аналарын, педагогларны һәм тәрбиячеләрне, республика мәгариф системасының барлык хезмәткәрләрен Белем көне һәм яңа уку елы башлану белән чын күңелдән тәбрик итәм!

Безнең һәркайсыбызның мәктәп бусагасын тәүге тапкыр атлап кергән, парта артына утырган, беренче укытучыбыз белән очрашкан онытылмаслык 1 сентябре бар. Бүген дә меңнәрчә яшь татарстанлылар белем дөньясы белән танышуның дулкынландыргыч мизгелләрен кичерә, аның иксез-чиксез офыкларын ача.

Аларга бигрәк тә бу күркәм юлда зирәк, ярдәмчел педагоглар очравын, игелекле, тугрылыклы дуслар табуларын һәм тормыш биеклекләренә ирешүләрен телим!

Заманча мәгариф теләсә кайсы дәүләтнең уңышлы үсеше һәм чәчәк атуы нигезе булып тора. Бу безнең дәүләт сәясәтендә өстенлекле юнәлешләрнең берсе, аны гамәлгә ашыру Татарстанның күпмилләтле халыкларының лаеклы киләчәген тәэмин итәргә тиеш.

Узган уку елында республикада сыйфатлы, һәркем ирешә алырлык белем бирүне тәэмин итү буенча мөһим адымнар ясалды.

«Киләчәк» мәгарифне үстерү стратегиясен тормышка ашыруның беренче этабы төгәлләнде. Укытучыларга грантлар белән һәм матди ярдәм итү сизелерлек артты. «Бәләкәч» республика программасын уңышлы үтәү балалар бакчаларында унөч меңнән күбрәк урын булдырырга мөмкинлек бирде. Мәгариф учреждениеләрен җиһазландыру сизелерлек яхшырды. «Татарстан Республикасында электрон белем бирү» системасы үсә.

Сәләтле балаларга һәм яшьләргә булышлык формалары камилләштерелә. 1 сентябрьдә Универсиада Авылында сәләтле мәктәп балалары өчен IT-лицей-интернат ачыла. Казан янында Иннополис төзелә башлады, анда эшләү өчен бик күп яшь талантлы белгечләр таләп ителәчәк. Аны киләчәк шәһәре, дип атарга мөмкин, анда һәркем үз сәләтен ача, алган белемнәрен практикада куллана алачак.

«Татарстанда инглиз теле» программасы уңышлы үтәлә, республика шәһәрләрендә татар һәм рус телләрен укытуны камилләштерү өчен күп нәрсәләр эшләнә.

Гамәлгә ашырылучы комплекслы чаралар безгә мәгарифне югары нәтиҗәле, конкуренциягә сәләтле, тормышыбызны яхшырак һәм рухи яктан баерак итәргә мөмкинлек бирер, дип ышанам. Һәм монда җәмгыятьнең, һәркайсыбызның, хөрмәтле татарстанлылар, ярдәме һәм актив катнашуы аеруча мөһим.

Бәйрәм уңаеннан укытучыларыбызга, тәрбиячеләргә, профессор-укытучы корпус вәкилләренә, аларның җиңел булмаган, ләкин бик әһәмиятле һәм һәркайсыбызга, тулаем җәмгыятьтә кирәкле хезмәте өчен олы рәхмәтемне җиткерәм. Сезнең өчен яңа уку елы тагын да зуррак иҗади казанышлар һәм җиңүләр елы булсын!

Сезнең барыгызга да бәхет, тынычлык, муллык һәм иминлек телим, кадерле дуслар!

Татарстан Республикасы Президенты
Р.Н.МИҢНЕХАНОВ

ТАРИХ

Борынгыма якыная барам,
Төшсәм ерак еллар артына:
Сәхифәләр саен хәйран калам
Зур тарихлы батыр халкыма.

Нури Арсланов

ТАТАР ТЕЛЕ ЯЗМЫШЫ ТУРЫНДА КАЙБЕР УЙЛАНУЛАР

ИСКӘНДӘР ГЫЙЛӘҖЕВ,
тарих фәннәре докторы,
Казан федераль университеты профессоры,
Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир-әгъзасы

ТАТАР ТЕЛЕ ЯЗМЫШЫ ТУРЫНДА СОҢГЫ ДИСТӘ ЕЛ ЭЧЕНДӘ КҮПМЕ ЯЗЫЛДЫ, КҮПМЕ СӨЙЛӘНДЕ... БАРЛЫК ЯЗМАЛАР ҺӘМ ЧЫГЫШЛАРНЫ БӘЯЛИ БАШЛАСАК, АЛАРНЫҢ ТӨП ЮНӘЛЕШЛӘРЕ АЧЫКЛАНА. УЛ — ТЕЛЕБЕЗНЕ САКЛАП КАЛУ ҺӘМ АНЫ ҮСТЕРҮ ЧАРАЛАРЫ.

90нчы еллар башында бездә шактый күп эш эшләнде кебек — милли мәктәпләр, балалар бакчалары ачылды, телгә игътибар да артты, киләчәккә өмет белән карарга нигезләр дә барлыкка килгән иде шикелле. Ләкин, ни кызаныч, тормыш үзгәргән кебек, җәмгыятьтә телгә караш та тискәре якка үзгәрә. Дөнья куабыз, матди проблемаларны хәл итәбез — нәтиҗәдә тел мәсьәләсе яңадан икенче планга күчеп бара. Минемчә, бүген безнең татар халкы берничә хакыйкатьне төгәл аңларга тиештер. Беренчедән, тел — халкыбызның шулхәтле зур казанышы һәм байлыгы ки, без аны югалтсак, киләчәк буыннарга тапшыра алмасак, бу байлык җуелачак. Ул югалса, без аны яңадан торгыза һәм терелтә алмаячакбыз. Икенчедән, татар теле татардан

башка беркемгә дә кирәк түгел. Татар теленең бетүе татарны гына борчый. Аны саклап калу, үстерү рус телле дәүләтне бөтенләй кызыксындырмый. Телебезне саклап калу бары тик татар халкының эше. Мондый хәлнең табигый икәне дә көн кебек ачык. Зур дәүләт, телиме-теләмиме, һәрвакыт бертөрлелеккә омтыла. Этник яки дини чуарлык, төрлелек аның өчен артык, ул дәүләткә бары тик комачаулый торган фактор. Төрлелек таркалуга илтә, дип саный мондый дәүләт. Бу фикер, сирәк булса да, ачыктан-ачык яңгырый. 2011 елның февралендә Дәүләт Думасы рәисе урынбасары шундый сүзләр ычкындырды: «Мы не должны радоваться, что у нас многонациональное государство. Это наша беда!» Ә башка түрәләр башкача уйлыйлар микән? Бик тә шикләнәм.

Тагын бер мөһим нәрсәгә игътибар итәсем килә. Без еш кына телне саклауда хәлиткеч рольне татар авылы уйный дигән фикерне тәкрарлыйбыз. Анысы дөрес, әлбәттә. Шул ук вакытта шәһәргә күчкән авыл кешеләре еш кына татар теленең төп дошманнары булып чыгалар. Бер гыйбрәтле хәлне искә төшерәм. Танышларыбыз гаиләсендә оник туганнан соң, аның бабасы: «Бу бала татарча сөйләшмәсен, менә мин шәһәргә күчеп килгәннән соң, русча белмәгәч, күпме җәфаландым. Оныгым да җәфаланмасын», — дип, бик каты торды. Нәтиҗәдә, малай инде үсмер булды һәм бер авыз сүз татарча белми... Мондый карашлы кичәге авыл абзыйлары һәм апалары шәһәрдә аз түгел дип беләм. Каян килеп чыккан соң мондый караш?

Беренчедән, фикер тарлыгыннан. Үзе авылда үсеп, татарча сөйләшкән кеше, шәһәргә күчкәч, чыннан да, кайвакыт җайсызлык кичерә. Ничек инде — «культурный» шәһәр русча сөйләшә бит! Ә мин «авыл кабартмасы» булып чыгаммы? Юк инде, мин балама Эмиль, Артур, Эвелина, Аделина дигән «затлы» исем кушам, аның белән вата-җимерә русча сөйләшәм дә, нәтиҗәдә, минем балам да «культурный» булачак... Бер гади нәрсәне аңламый ул: аның баласы яки оныгы бөтенләй башка тел шартларында тәрбияләнә. Шәһәрдә үскәндә, ул, телиме-теләмиме, русчаны табигый рәвештә үзләштерәчәк. Бу шартларда, киресенчә, тырышып, максатчан рәвештә баланы икетелле итеп тәрбияләргә кирәклек аның башына да сыймый.

Икенчедән, авыл кешесенә практицизм яки прагматизм хас, ягъни шәһәрдә урнашкан авыл кешесе шунысын ачык күрә: татар теленең шәһәрдәге даирәсе бик тар. Шәһәрдә русчаны гына белеп тә яшәп була. Татар телен саклау өчен, барыбер күпмедер дәрәҗәдә рус теле йогынтысы белән көрәшү, көч сарыф итү мәслихәт. Ә көч-куәтне бары тик конкрет нәтиҗә яки файда китерә торган эшкә юнәлтергә кирәк. Шуңа күрә алар өчен: «Тел — ул рухи байлыгыбыз, тарихи хәтер, ата-бабаларыбыз калдырган мирас», — дип сөйләүләр, чын мәгънәсендә, буш сүз булып кала бирә. Ике тел белгән кеше, бертеллегә караганда, рухи яктан баерак, дип мең кат кабатласак та, хәзер шәһәрдә яшәүче «культурный прагматик» кашын да сикертмәячәк.

Тел сәясәтендә төгәл максат булып татар кешесендә милли горурлык, үзаң һәм җаваплылык тәрбияләү куелырга тиеш. Безгә бүген руслар һәм башка халыклар үзара бертигез, безнең хокукларыбыз бер, дип кенә сөйләнү җитми. Әлбәттә, юридик яктан бу фикер дөрес, ләкин аңсыз рәвештә бертигезлекне пропаганда-

лау татарның руслашу юнәлешен дә үзгәртә. Без бер дәүләттә яшибез, бер дәүләт гражданнары, ләкин без бертөрле түгел. Безнең башка халыкларныкы кебек үз тарихыбыз, узган юлыбыз, гасырлар дәвамында формалашкан телебез, традицияләребез, үзаңыбыз, мәдәниятебез бар. Алар барысы да кабатланмас, уникаль һәм дөнья мәдәниятенең бер өлеше булып тора. Россия дәүләтенең төп үзенчәлеге, уникальлеге һәм көче шул этник, дини, мәдәни төрлелектә. Дәүләтнең эчке, аеруча милли сәясәте зирәк икән, ул мондый төрлелекне, матурлыкны сакларга тиеш кебек, ләкин бүген Россия дәүләте башка идеалларны кайгырта... Һәрдаим шулай булмас дип уйлыйм, шуңа күрә татар, үз җаваплылыгын аңлап, шактый авыр шартларда, кулыннан килгәнен эшләп, үз милли язмышын үзе хәл итәргә хаклы.

Телебезне саклап калу өчен, мин шушы юнәлешләрдә хәрәкәт итәргә мөмкин дип саныйм:

1. Шәһәрдә чын татар мохитен булдыру. Шәһәр — Казанмы, башкасымы, татарча сөйләшми, татар теле шәһәрдә бары тик кунак кебек. Тегендә — «Ашамлыклар», монда «Китаплар» сүзе күренә, шуның белән вәссәлам... Хәтта атамасы татар «Бәхетле» кибетендә дә сирәкмирәк татарча язмаларны бик тырышып эзләсәң генә таба аласың, анысы да «Сөт» белән «Икмәк» сүзләре. Дөрес, башка кибетләрдә алары да күренми... Татар мохитен булдыруны, нигездә, гади нәрсәләрдән башларга кирәктер. Шәһәрдәге барлык белдерүләр, барлык язмалар, Татарстанда җитештерелгән барлык әйберләрнең язулары ике телдә булырга тиеш. Кемдер әйтер: «Бу бит бары тик матди чыгымнарга гына китерәчәк, без барыбыз да русча яхшы аңлыйбыз», — дип. Ләкин андый тышкы икетеллелек кешеләр психологиясен үзгәртүгә китерәчәк. Кеше, чыннан да, минем тирәдә ике тел яши, ул ике тел дә тормышта бертигез файдаланыла, дип уйлый башлый. Шул юл белән генә татар теле шәһәрдә үз урынын алып калачак, аның аерылгысыз элементына әвереләчәк. Әйе, акча да кирәк булачак, каршылык та очрар, каты кул да таләп ителер, ләкин башкача булмый.

2. Сыйфатлы, зәвыклы, шәһәр халкына да, авыл халкына да кызыклы, яхшы татар телевидениесен булдыру — телне саклауда зарури бер шарт. Хәзерге көндә «Татарстан Яңа Гасыр» бу юнәлештә эшли, «ТНВ-Планета» дигән канал да барлыкка килде. Ләкин кайвакыт бу каналларны карагач, татар тормышы бары тик җырбиюдән генә тора дигән фикер туа. Әлбәттә, бу очракта сыйфатлы, төрле темаларга багышланган, бар кеше кызыксынып карарлык тапшыруларны булдыру өчен, гыйлемле, үз эшләрен яхшы белгән журналистлар булырга тиеш. Минемчә, дәүләт бер төркем яшьләрне шундый максат белән чит илләргә, Европага, Америкага берничә елга җибәрсә, телевидениедә уңай якка үзгәрешләр озак көттермәс иде. Ләкин бирегә бары тик сәләтле, эшләрлек кешеләр җибәрелергә тиеш. Әгәр дә андый мөмкинлек булдырылса, шунда ук ниндидер әшнәләрнең, туган-тумачаларның балалары, җитмәсә, татарча белмәгән һәм татарга битараф булган яшьләр тулмагае ул төркемнәргә дип куркам. Телевидениенең хәзерге кешеләр тормышында тоткан урыны үлчәп бетергесез, аны кайберәүләр русча юкка гына «зомбоящик» дип атамыйлардыр. Халкыбызның күпчелеге хәзер телевидение экраны аша тәрбияләнә, аның фикере экран аша формалаша.

Шуңа күрә бу мәсьәләгә бик җитди карау сорала.

3. Тагын бер актив үсә торган юнәлеш — интернет һәм компьютер технологияләре. Татар телен саклауда интернет гаҗәеп роль уйнарга мөмкин, чөнки яшьләрнең күбесе көне-төне интернетта аралаша. Бу күренешне без үз файдабызга куллана алабыз. Инде үзгәрешләр дә күренә шикелле: татарча Twitter яки Facebook кебек иҗтимагый челтәрләр булдыру көн тәртибенә басты, хөкүмәт оешмалары, күбесе «үле» булса да, татарча рәсми сайтлар ача. Интернет челтәрендә татар телен саклауда максатчан эш-гамәлләр булырга тиеш. Анда татар телендә бары тик латин хәрефләре белән генә язсак, татар телен пропагандалау, өйрәтүне киңрәк оештырсак, яшьләр өчен яңа мавыктыргыч сайтлар арттырылса, уеннар татарчага тәрҗемә ителсә, һәрбер татар газетасы, журналы, массакүләм мәгълүмат чарасы үз сайтларын актив яшәтсә, татарча форумнар саны артса, интернет татар телен саклау һәм үстерү өчен алыштыргысыз бер мәйдан булыр иде.

4. Милли мәгариф һәм милли мәктәп язмышы һәр татарны борчыйдыр, мөгаен. Соңгы вакытта татар мәктәбе язмышы турында күп сөйләнде һәм сөйләнә. Борчулар да җитәрлек. Күпме сөйләсәк тә, язсак та, дөресен әйтик — тулы канлы, нәтиҗәле эшли торган, балаларны һәм ата-аналарны җәлеп итәрлек татар мәгариф системасын булдыра алмадык. Биредә мин төп ике сәбәпне күрәм. Беренчесе — безнең милли мәгариф системасы, күпме тырышсак та, барыбер китек булып калды, аның балалар бакчасы, башлангыч, урта һәм югары мәктәптән торган барлык баскычлары булдырылмады. Татарча югары мәктәп юк һәм, күрәсең, булмаячак та. Милли университет проекты шактый кызыклы иде, ләкин тормышка ашырылмады. Хәзерге Татарстан югары уку йортларында татар теле укытылса да, ул барыбер икенче-өченче пландагы тел булып калды. Хәтта татар телен һәм әдәбиятын өйрәтә торган фәнни үзәкләрнең саны да киметелде. Бу юнәлеш бүген бары тик Казан федераль университетында сакланды. Икенче сәбәп — татар мәктәбенең яшәеше Россия дәүләте кысаларында алып барыла торган сәясәткә турыдан-туры бәйләнгән. Бердәм дәүләт имтиханнарын татарча тапшыруны тыю, милли телләрне, тарихны, мәдәниятне укытуга чик куя торган 309 нчы законны кабул итү — болар күп ата-ананы сагайтты: «Нишләп минем балам мәктәптә татарча укырга тиеш, югары уку йортында ул кирәк түгел, чыгарылыш имтиханнарын бары тик русча гына тапшырып була, алдагы тормышта татар телен белү шулай ук ниндидер ташламалар бирми», — дип, ата-ананың күңелендә инде бу мәкаләдә элегрәк искә алынган «прагматик» аң уяна. Моны Россия хөкүмәте бик тә яхшы аңлый кебек тоела, милли телләр аңлы рәвештә мәктәп системасыннан кысрыклап чыгарыла. Искә төшерик: 2002 елның августында Казанга килгәч, Президент В.Путин бик тә мәгънәле сүзләр әйткән иде: «Полная дурь и бред, если кто-то где-то запрещает в многонациональной стране изучать родной язык или препятствует этому. Абсолютно недопустимо, вредно для страны в целом. Россия — это средоточие такого национального, культурного, языкового богатства, которого в мире нигде нет. В этом как раз сила нашего государства». Әгәр дә бу сүзләр чын күңелдән әйтелгән икән, 309 нчы законны кайда куябыз? Кызганыч, бездә шулай

эш итәләр инде: башта шундый законнар кабул итеп, тискәре шартлар тудырып, ата-аналарда «прагматик» аң уяталар, аннан соң матур итеп: «Ата-аналар үз теләкләре белән балаларын милли мәктәпкә бирмиләр», — дип, ялган күз яшьләре коялар.

Мәгариф өлкәсендә безгә бигрәк тә түбәндәге берничә моментка игътибар итәргә кирәк дип саныйм.

Беренчедән, укытучылар әзерләү сыйфаты. Татарча беләм дигән сүз ул әле татар телен укыта алам дигән сүз түгел. Татар телен сәләтле, әзерлекле белгечләр укытырга һәм бу процесс өзлексез, каты күзәтү астында булырга тиеш. Шәхестән күп нәрсә тора, тел өйрәтүдә бигрәк тә. Бер гыйбрәтле хәл искә төшә. Заманында, Казан университетында әле татар филологиясе һәм тарихы факультеты булган вакытта, безгә берничә тапкыр рус кызлары укырга килде. Гаҗәпләнеп, алардан: «Ни этәрде сезне татар филологиясен өйрәнергә?» — дип сораша идем. Барысының да җавабы бер: «Татар теле укытучыбыз бик әйбәт иде, татар теленә мәхәббәтне ул уятты», — диделәр. Ә берсеннән сорадым: «Синең бертуганнарың бармы?» — дип. «Энем бар», — диде. «Ул да татарча беләме соң?» — дип сорагач: «Юк, ул типичный рус малае», — дигән җавапны ишеттем һәм рәхәтләнеп көлеп җибәргән идем шул мизгелдә. Күрәсең, энесен башка укытучы укыткандыр. Менә бит укытучы шәхесе бу очракта нинди роль уйный! Димәк, әйткәнемчә, татар теле укытучыларын әзерләүгә игътибар арттырылса, аларга эшләре өчен Татарстан хөкүмәте тарафыннан социаль һәм матди ташламалар бирелсә, мәктәптә татар телен укыту эшен җайга салып була.

Икенчедән, мәктәп өчен татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре безне һаман да канәгатьләндерә алмый. Алар төрле булырга тиеш дип саныйм, авыл яки шәһәр балалары өчен аерым, татар телен камил, начар яки бөтенләй белмәгәннәр өчен аерым. Дәреслекнең төп максаты нинди? Нигездә, татар теле дәреслеге укучыны татарча камил аралашырга өйрәтергә тиеш, ә миндә кайвакыт шундый шик туа: «Бу дәреслекләр бар укучыдан да татар теле галимнәре ясауга юнәлтелгән түгелме?» Ә бит һәр кеше татар теле галиме булып бетә алмый, шунысы онытылып кала бугай. Дәреслек авторлары арасында табигый көндәшлек булсын, дәреслекләр әзерләүдә төрле методикалар файдаланылсын, татар теле дәреслекләрен язуга башка милләт галимнәре дә җәлеп ителсен иде. Алар татар телен укытудагы кыенлыкларны кайвакыт яхшырак күзаллыйлар. Бәлки шул очракта гына татар телен мәктәптә укыту эше уңай якка тизрәк үзгәрер.

Өченчедән, элекке татар-төрек лицейлары үрнәгендә шәһәрләребездә, районнарыбызда сыйфатлы белем бирә торган, татар элитасы әзерләүгә юнәлтелгән мәктәпләрне ачуны кирәк дип саныйм. Татар-төрек лицейлары, теләк булса, эш дөрес оештырылса, андый мәктәпләрне булдыру мөмкин икәнлеген исбатладылар. Заманча җиһазландырылган, иң яхшы укытучылар эшләгән, татар, рус һәм чит телләрне сыйфатлы укыткан, төрле фәннәр буенча төпле белем биргән мәктәпләр булса, әллә безнең «прагматиклар» балаларын андый мәктәпләргә бирмәс иде микән? Ябырылып килерләр, чиратка басарлар иде әле.

5. Татар телен оныткан, ләкин татар үзаңын югалтмаган, үзләрен татар дип саный торган милләттәшләребез белән эш алып бару бик тә актуаль

бурыч булып күренә. Бездә еш кына андыйларга кырын карыйлар. Имеш, татарча белми икән, ул инде татар түгел. Юк, җәмәгать, татар телен белмәүчеләр саны бездә арта бара, без аларны кирегә борырга, яңадан татар мохитенә кайтару турында уйланырга тиеш. Кызыксынучылар өчен татар теле курслары оештырырга, рус телендә татар тарихы, теле, әдәбияты, мәдәни казанышларыбыз, бөек шәхесләребез турында сөйләп торырга мөмкин. Андый «телсез» татарларга безнең чырай җыерып карарга хакыбыз юк, чөнки аларның йөрәкләрендә, күңелләрендә татар рухы әле сүнмәгән.

6. Татар теле, тарихы, мәдәнияте абруен арттыру өчен, тагын бер юл булып чит өлкәләрдә, чит илләрдә татар тематикасы белән шөгыльләнә торган галимнәргә игътибарны юнәлтү тора. Бу игътибар бүген бөтенләй юк диярлек. Ә татар теле, әдәбияты, тарихы белән кызыксынучы галимнәр дөньяда аз түгел. Үземнең танышларымнан Алмания галимнәренең берничәсен генә искә төшерәм. Гиссен университеты профессоры Марк Кирхнер инде күптәннән татар теле дәресләре оештырган, татар теле грамматикасы буенча инглиз телендә дәреслек яза. Бүген Берлинда яшәүче галим Михаэль Фридрих — Габдулла Тукайга багышланган саллы монография авторы. Шул ук Берлиннан Себастиан Цвиклински Алманиядәге татар диаспорасы тарихына багышланган китап бастырды. АКШ, Франция, Венгрия, Япония, әлбәттә, Төркиядә татарны дөньяга танытучылар шактый. Шуларны барлап, алар белән элемтә урнаштырсак, фәнни эзләнүләрендә яңа мөмкинлекләр ачсак, үзебез өчен нинди зур файда булыр иде! Авыз тутырып: «Менә, нинди зур галимнәр Алманиядә яки Япониядә яшәп эшләсәләр дә, татарны беләләр, милләтебезне олылыйлар, халкыбызның мәдәни казанышларын да өйрәнәләр», — дип әйтә алыр идек. Чит ил галимнәренә матди ярдәм кирәк тә түгел. Аларны Татарстан Республикасы чыгыш ясар өчен Казанга чакырса, безнең телевидение, газета-журналлар аша гыйльми эшчәнлекләре турында сөйләп торсалар, ягъни мораль яктан булышлык итсәк, ачык йөз күрсәтсәк, минемчә, галимнәр тулысынча канәгать булырлар иде.

Бу мәкаләдә мин телебез язмышы өчен мөһим булган кайбер юнәлешләргә генә тукталып уздым. Америка ачтым дип санамыйм. Шулай да ассызыклап әйтәсем килә: татар телен саклау һәм үстерү һәрберебезнең эше, җаваплылык аерым дәүләт, мәктәп яки гаилә өстендә генә түгел. Бу гамәлдә, әлбәттә, башка чаралар да тәкъдим ителде, ителә һәм ителәчәк. Биредә бер генә юнәлеш өстенлек алырга тиеш түгел — алар барысы да актуаль. Ә бездән нәтиҗәле эш оештыру таләп ителә. Ләкин, гадәтебезчә, бу эшне чираттагы күз буяуга гына әверелдерсәк, бары тик документ тутыру яки хисап язу белән генә чикләнсәк, бигрәк тә аяныч булыр. Чөнки бу очракта халкыбызның терәге, язмышы булган телебез хакында сүз бара. Кабатлап әйтәм: телебезне югалтырга безнең хакыбыз юк. Телебезне югалта калсак, ата-бабаларыбыз хәтере алдында бүгенге буын чын мәгънәсендә хыянәт кылган булыр иде. ◢

РОССИЯДӘ МИЛЛИ МӘГАРИФНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ

МАРАТ ЛОТФУЛЛИН,
физика-математика фәннәре кандидаты,
Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының
өлкән фәнни хезмәткәре

Мәгарифне кешеләрнең белем һәм күнекмә алу яки аларны камилләштерү буенча максатчан эшчәнлеге диеп билгеләп була. Гомуми һәм махсус белемнең дәрәҗәсе җитештерү таләпләре, фән-техника, мәдәниятнең халәте һәм иҗтимагый вазгыять белән билгеләнә [1]. Киң мәгънәсендә мәгариф — «җәмгыятьнең мәктәпләр, колледжлар, университетлар һәм башка институтлар аша буыннан-буынга үзенең мәдәни мирасын — тупланган белемен, кыйммәтләрен һәм күнекмәләрен тапшыру буенча максатчан процесс» ул [2].

Урта гасырларда ук укытуда ике төп юнәлеш барлыкка килә: мәдәнилек (культуросообразность) һәм табигыйлек (природосообразность). Бу юнәлешләрне данлыклы алман педагогы А.Дистерверг (1790-1866) үзенең классик «Укытуда мәдәнилек һәм табигыйлек» хезмәтендә ачыклый. Мәдәнилекне яклаучылар укытуның нәтиҗәләре укучы урнаштырылган мәдәни мохиткә (мәктәп бинасы, укытучылар, китапханә, компьютерлар һ.б.) генә бәйле дигән фикерне куәтлиләр. Укучыларның табигый сәләтләренең бер-берсеннән нык аерылуларын асылда исәпкә алмыйлар. Бу юнәлешнең үзенчәлеге булып барлык укучыларны бердәм программа һәм бер үк тизлек белән укыту һ.б. тора. Мондый ысул уңышлы булсын өчен, укучыларның белемен һәрвакыт контрольдә тотарга һәм өлгермәүчеләрне төшереп калдырырга кирәк. Бу таләп бозылганда (әлбәттә, һәрвакыт иң яхшы теләкләр белән) укырга теләмәүчеләр яки укырга сәләтсезләр (тәкъдим ителгән программа буенча) исәбенә укытуның нәтиҗәлелеге түбәнәя башлый һәм ае-

рым шартларда болай укытуның кире нәтиҗәләре уңай яклардан күпкә зуррак булырга мөмкин.

Белгечләр фикеренчә (Кумарин В. Среда влияет, природа определяет // Народное образование. 1998. № 7), мәҗбүри гомуми белем бирү мәктәбендә гаять зур төрле максатлы һәм табигый сәләтле укучыларны төшереп калдырмыйча укыту өчен табигыйлек юнәлеше кулайрак. Шуңа күрә укыту һәм тәрбия мәсьәләләрен чишү юллары укыту-тәрбия юнәлешенә карап, бер-берсеннән шактый аерылачак.

Безнең илдә педагогикада мәдәнилек юнәлеше хакимлек итә. Табигый сәләт урынына сәләт формалаштыру, укыту урынына «образование» терминнары кулланыла. Россиядә мәгариф чиновниклары элита сүзен акыл хезмәте өлкәсендә генә кулланалар («алтын куллар» әкиятләрдә генә калды). Россия мәктәбе инде күп еллар укучыларны югары уку йортлары өчен генә әзерли (җәмгыятьнең мөмкинлекләренә һәм ихтыяҗына карамый).

А.Дистерверг «әзлекле рәвештә һәм бертуктаусыз алга бару өчен ике юнәлешнең педагогикада да, җәмгыятьтә дә үзара килешүенә ирешергә кирәк», диеп күрсәтмә бирә һәм педагогика фәне алдына өч мәсьәлә куя:

«1. Ул шәхес белән исәпләшергә тиеш һәм аның табигый үзенчәлекләренә карап тәрбияләргә тиеш.

2. Тәрбия шәхеснең милләтенә бәйле үзенчәлекләр нигезендә алып барылырга тиеш.

3. Шәхес гомумкешелек максатлары буенча тәрбияләнергә тиеш».

Беренче мәсьәлә кешенең табигатен аңлау һәм аңа хас үсеш законнарын белү, шулай ук шәхеснең үзенчәлекләрен дөрес билгеләү юлы белән генә чишелергә мөмкин. Психологияне белү, күзәтү сәләте, шәхси сәләтне таба белү тәрбиятенең беренче зарури сыйфаты булып тора.

Икенче мәсьәләне чишү милли характерны белүне күз алдында тота, тәрбиячедән дә ул характерның булуын таләп итә.

Өченче мәсьәлә кешелек каршында торган максатларны аңлауны һәм үз көченнән килгәнчә аларны тормышка ашыруга омтылышның булуын шарт итеп куя.

Элек педагогика, беренче чиратта, әүвәлге мәсьәләне чишүгә омтыла һәм икенче, һәм өченче мәсьәләләр белән кирәк кадәр шөгыльләнми иде. Шуңа күрә без соңгы ике мәсьәләгә киңрәк тукталуны кирәк дип саныйбыз.

Һәр милләтнең табигый һәм тарихи үзенчәлекләре, милли рухы бар. Аның бер генә милли тормышы бар. Ул иректе үсеше һәм милли рухның эшчәнлеге яки милли мөстәкыйльлек, азатлык белән билгеләнә.

Шулай итеп, А.Дистерверг мәгариф үзенең асылында милли диган нәтиҗәгә килә.

Хәзерге Россия мәгарифе система буларак мәдәнилек юнәлешенә (культуросообразность) нигезләнгән (В.С.Библер, Е.В.Бондаревская, Н.Б.Крылова). Рус телендә белем алучы мәктәп укучысының мәдәни үзбилгеләнү мохите булып рус милли мәдәнияте тора. Шуңа бәйле рәвештә милли кыйммәтләргә нигезләнгән Россия гражданы тәрбияләү Россия мәгарифенең максатын тәшкил итә. Укытуның мәдәнилек юнәлеше бердәм программалы мәҗбүри урта белем бирү шартларында тормышка ашырыла. Нигә соң Россиядә ачыктан-ачык күренеп торган белем сыйфаты ягыннан кимчелекле укыту моделе кулланыла? Моның асылы 1866-1880 елларда Россиядә халык мәгарифе министры булган граф Д.А.Толстойның вакытында эшләнгән концепциясендә билгеләнә. «Мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә укытуны башта урындагы сөйләмдә яки аның ярдәмендә кертергә. Аннан соң, балалар русча телдән сөйләмне үзләштергәч, күбесенчә русча дәвам итәргә һәм ахыр-

да рус телендә генә укытуга күчәргә. Мәктәпләрнең һәм мәдрәсәләрнең бу классларда укыту 16 яшькә кадәр мәҗбүри барырга тиеш». Бу стратегияне тормышка ашыру Россия өчен бик зур һәм мөһим мәсьәлә булган, чөнки ул вакытта татарларның мөстәкыйль белем бирү системасы эшләп килгән.

Совет чорында татар халык мәгарифе дә дәүләт системасына күчә. Өстәвенә Россия халыклары телләрендә укыту гына милли дип атала башлый. Рус телендә укыту милли укытуга саналмый. Милли мәгариф тә халыкларны рус мәдәнияте рухында тәрбияләүгә һәм рус телен иркен белү дәрәҗәсендә өйрәтүгә юнәлтелә.

ТАССР оешкач, татар теле дәүләт теле дип игълан ителә һәм рус теле белән беррәттән мәктәпләрдә укытыла башлый. Милли мәгарифкә беренче зур һөҗүм латин графикасын кириллицага күчерү вакытында ясала. Бөек Ватан сугышы елларында, акча җитмәүгә сылтап, Россия төбәкләренең югары уку йортларында татар телендә белгечләр хәзерләү туктатыла, газета-журналлар ябыла. Милли мәгарифне бетерүгә китергән гамәлләр КПСС Үзәк Комитетының бердәм совет халкы төзү лозунгы астында тормышка ашырыла. СССРда кайбер халыклар туган телләрен югалту дәрәҗәсенә җиттеләр. Нәтиҗәдә, саклану реакциясе буларак, демократияләштерү шартларында Советлар Союзы таралды. Гомумдәүләт милли мәгариф системасы да сүтелде: Россия Федерациясендә гомумроссия милли мәгарифе белән идарә системасы бетерелде, халыклар телләрендәге укыту-методик әсбаплар белән тәэмин итү системасы таралды. Милли мәгарифне оештыру вәкаләтләре төбәкләргә бирелде. Укыту программаларына федераль һәм милли-төбәк компонентлары кертелде. Нәтиҗәдә, республикаларда милли мәгариф системасы торгызыла башлады. Милли мәгарифне төзү мәсьәләләрен һәр республика үзенчә хәл итте (фәнни тикшеренүләрдән алып, хокукый-норматив нигезләренә кадәр). Россия Федерациясенең башка субъектларында милли мәгариф 80 нче еллар дәрәҗәсендә кала бирде. Максатлар да төрлечә куелды: республикаларда — туган телдә укытуны аякка бастыру, ә төбәкләрдә башка телле балаларны рус мәктәбенә адаптацияләү [6].

Россия Федерациясе Конституциясе һәм законнары нигезендә, туган телдә белем бирү түләүсез һәм дәүләт системасында булырга тиеш булса да, төбәкләрдә туган телдә укыту проблемаларын күп очракта милли-мәдәни автономияләр хисабына хәл итәргә тырышалар, ә аларга дәүләт тиешле акча бүлеп бирми [7]. Нәтиҗәдә, төбәкләрдә гражданның туган телдә түләүсез белем алу турындагы конституцион хокуклары бозыла. Биредә гражданнарның үз хокукларын яклый белмәүләрен дә әйтеп китү сорала.

Федераль үзәк тә туган телдә белем алуны гражданнарның шәхси эше диеп саный һәм үзен түләүсез белем бирү дәүләт гарантияләрен үтәүдән азат итә.

Гомумән алганда, рус телле монокультуралы мәгариф мохите шартларында Россия халыкларының милли аңы үсүе Россия җәмгыятендә милләтара каршылыкларның куркыныч күренешләрен тудырды, шәхеснең чит халыклар мәдәнияте мохитенә күнегергә өйрәнмәгәнлеген күрсәтте. Бу тарихи шартларда шәхескә юнәлдерелгән мәгариф системасының аерылгысыз өлеше булып торган, мәдәниятара багланышларны тәэмин иткән, чит мәдәни кыйммәтләрне кабул итәргә әзер, шул ук вакытта үз мәдәниятен дә югалтмый саклаучы шәхес тәрбияләүгә юнәлтелгән яңа методология эшләү кирәк.

Хәзерге вакытта милли мәгариф проблемасы педагоглар җәмәгатьчелеге тарафыннан актив рәвештә тикшерелә [19-35].

РФ милли мәгариф сәясәте проб-

лемаларын чишү хәзерге милли мәгариф учреждениеләре эшчәнлегенә анализ белән дә тыгыз бәйләнгән. Бу тәҗрибәне гомумиләштерү күпмәдәниятле җәмгыятьтә милли мәгарифне үстерүнең оптималь юлларын эзләү өчен кирәк. Беренче чиратта, анализ милли мәгарифнең бөтен үзенчәлекләрен билгеләргә мөмкинлек бирәчәк. Икенчедән, милли мәгариф учреждениеләренең статусын билгели торган хокукый норматив документлар булмаган шартларда галимнәрнең милли мәктәп төрләрен билгеләүне законлаштыру буенча тәкъдимнәрен күзалларга мөмкин булачак.

Россиядә милли мәгарифкә бәйле бердәм һәм системалаштырылган фикер булмау милли мәгарифне оештыру эшендә дә күренә. Хәзерге көнгә кадәр законда гына түгел, теориядә дә милли мәгариф учреждениеләрен билгели торган бердәм критерийлар юк. Мәсәлән, Л.Г.Лазарева хезмәтендә милли мәгариф учреждениеләренә классификация ясау өчен, аларның милли составы тәкъдим ителә:

— моноэтник составлы (бер милләт балалары 70 проценттан күбрәк);

— составында 40-70 процент бер милләт балалары булган полиэтник;

— составында бер милләт тә өстенлек алмаган полиэтник мәктәпләр.

Уку-укыту процессын автор һәр группа мәктәп өчен аерым методология белән эшләргә тәкъдим итә.

Г.Н.Волков тәкъдим иткән милли мәгариф учреждениеләре классификациясенең нигезендә укыту теле һәм программаларның эчтәлеге ята. Шуңа күрә автор 7 тип милли мәктәп билгели:

1. Бөтен предметлар туган телдә укытылган мәктәпләр (Татарстан һәм Башкортстан).

2. 8 нче класска кадәр туган телдә белем бирелгән мәктәпләр (Якутия һәм Тува).

3. Башлангыч класска кадәр туган телдә укытучы мәктәпләр (Европа өлешендә урнашкан милли мәктәпләр).

4. 1-2 нче классларда туган телдә белем бирүче мәктәпләр (Бурятия, Мордовия, ненец һәм эвенклар).

5. Туган тел предмет буларак укытылган, рус телендә эшләүче мәктәпләр (Дагыстан, Төньяк Кавказ халыклары, Ерак Төньяк халыклары).

6. Туган тел факультатив рәвештә укытылган шәһәр һәм посёлок мәктәпләре. Туган тел укытылмаган мәктәп-интернатлар (саамнар, хантлар, манслар, эвенклар, чукчалар, ненецлар һ.б.).

7. Туган телне укыту-тәрбия эшендә кулланмый торган диярлек бермилләтле (рус булмаган) мәктәпләр (кареллар һ.б. бик күп республикалардан читтә яшәүче милләтләрнең мәктәпләре). Бу күпчелеге (75 %) Татарстаннан читтә көн итүче татарлар өчен тел һәм мәдәниятне югалтуга китерә.

Хәзерге заман милли мәгарифендәге педагогик концепцияләргә С.Л.Зубарева, Л.Ю.Понкуренко ясаган анализ нигезендә, хәзер укыту процессында милли мәктәптә 3 төп юнәлеш барлыкка килде диеп була: яңарыш (возрожденческий) (И.Г.Гончаров, Е.П.Белозёрцев, В.Ганичев); күпмилләтле (поликультурный) (Д.Бэке, Г.Д.Дмитриев, О.В.Гукаленко); методологик (Е.В.Бондаревская).

Бу юнәлешләр бер-берсенә каршы килмиләр, бер-берсенә өстәмә булып торалар. Аларны үсеш этаплары диеп карап була. Һәр концепция бер-берсенә нигезләнеп үсә. Милли мәктәпкә булган бу карашлар XXI гасыр мәктәбенең моделен күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

Яңарыш концепциясе XIX-XX гасырлар педагогикасына нигезләнә һәм халыкның күпгасырлык тәрбия тәҗрибәсен, мәдәниятен исәпкә ала, халык педагогикасы һәм дин нигезләренә таяна.

Күпмәдәниятле мәгариф халыклар арасында үзара бәйләнешне күз алдында тота һәм үзара аңлашып яшәү, теләктәшлек хисләре тәрбияли. Ул төрле мәдәниятләрнең үзара бәйләнешенә, мәдәни кыйммәтләрне үзләштерүгә һ.б. мәдәни кыйммәтләрне кабул итүне тәрбияләүгә нигезләнгән. Россия, башка күп илләр кебек, күпмилләтле җәмгыятьне берләштерә, шуңа күрә илне саклау өчен, халыкларның толерантлы яшәешен тәэмин итәргә кирәк.

Методологик юнәлеш, яңарыш юнәлешеннән аермалы буларак, булган мәдәни мирасны гына өйрәнми, уку процессында мәдәнияткә үсеш бирү юлларын да күрсәтә. Мондый тәрбия уку процессы белән бербөтен процесс булып бара. Күпмәдәниятле мәгарифтән аермалы буларак, методологик юнәлешнең нигезен бердәм гуманитар мохит тәшкил итә. Уку процессында гуманитар дисциплиналар төрле мәдәният мохитен тудыралар.

Бүген Россиядә яңарыш тибында милли мәктәпләр күп таралган. Күпмәдәниятле мәгариф узган гасырның 80 нче елларында Көнбатыш Европа илләрендә үсте. Россиядәге соңгы вакыттагы үзгәрешләрдән соң, поликультуралы мәгариф бездә дә үсеш таба. Методологик юнәлеш әлегә теория өлкәсендә генә чагыла.

Шулай итеп, Россиядә халыкларга сакланып калырга реаль мөмкинлекләр туа башлады. Милли мәгарифнең теоретик нигезләре барлыкка килде һәм гамәли эш башланды.

2000 елдан башлап Россия Федерациясе субъектлары мәгариф органнарына туган телгә бирелгән сәгатьләр санын кыскарту турында тәкъдимнәр килә, милли мәктәптә балаларның дөрес тәрбияләнмәве, патриотизм булмау, сепаратизм һәм изоляционизм турында мәкаләләр күренә башлады. Мәсәлән, Татарстанда да 2000 елдан бирле мәктәпләр 9,8 процентка кимеде, аларның күпчелеге (8%) — татар мәктәпләре. Бу кыскартуларның формаль нигезендә җан исәбеннән норматив финанслау принцибын тормышка ашыру ята.

2007 елның 1 декабрендә 309-ФЗ номерлы Федераль закон белән укыту программаларындагы милли-төбәк компоненты гамәлдән чыгарылды. Мәгариф белән идарәнең төбәк органнарыннан уку планнары, төбәк программалары һәм дәреслекләр әзерләү, бастырып чыгару вәкаләтләре алынды. 309-ФЗ законы мәгариф учреждениеләре эшчәнлегенә дә күп чикләүләр кертте; шул исәптән дәреслекләр сайлау һәм тәрбия эшен оештыруга бәйле. Хәзер мәктәпләрдә Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тәкъдим ителгән яки рөхсәт бирелгән дәреслекләр генә кулланыла. Милли-төбәк компоненты нигезендә эшләнгән һәм моңарчы кулланылган бер генә дәреслек тә күрсәтелгән исемлекләргә кертелмәгән. Россия Федерациясе субъектларында эшләнгән дәреслекләргә рәсми рецензия алу механизмы эшләнмәгән. Бу рецензияләрне РФ хөкүмәте раслаган оешмалар гына үткәрә ала, ә алар арасында, кызганычка каршы, татар телендә дәреслекләргә рецензия бирерлек квалификацияләре юк.

Укыту-тәрбия процессында Федераль исемлеккә кертелгән нәшриятларның методик әсбаплары гына мәктәптә кулланыла ала. Татарстан Республикасының бер нәшрияты да бу исемлеккә кермәгән. Шулай итеп, Федерация субъектлары мәгариф өлкәсендә хокукый-норматив документлар төзү һәм алар нигезендә милли мәктәпләр өчен туган телдә уку әсбаплары эшләүдән мәхрүм ителделәр.

309-ФЗ законы нигезендә укыту-тәрбия процессы укытуның Федерация дәүләт стандартлары нигезендә оештырыла, бу стандартларны эшләү һәм раслау федерация хөкүмәтенә тап-

шырылган. Закон нигезендә стандартлар 10 елга бер үзгәртелергә мөмкин.

Федерация хөкүмәте органнары укытуның федераль дәүләт стандартларында милли-төбәк компонентының әчтәлеге саклана, диеп ышандырсалар да, алар туган телдә белем алуны һәм туган телне өйрәнүне чикләүгә юнәлдерелгән. Бу Россия хөкүмәте раслаган дәреслек исемлекләреннән дә, методик кулланмалар чыгарырга рөхсәт бирелгән нәшриятлар исемлекләреннән дә күренеп тора. Туган телдә белем алу өчен көрәшергә туры киләчәк. Бу фикеребезне Россия Мәгариф һәм фән министрлыгының 2009 елның 28 ноябрендә кабул иткән 362 номерлы приказы да раслый. Бу приказ белән бердәм дәүләт имтиханнары үткәрү Нигезләмәсе расланган. Нигезләмәнең 5 нче пункты нигезендә барлык фәннәрдән (чит телләрдән башка) дәүләт йомгаклау имтиханнарын рус телендә генә үткәрергә мөмкин. Россиянең «Мәгариф турында»гы законының 4.2 пункты нигезендә, бердәм дәүләт имтиханнарының нәтиҗәләре югары һөнәри белем бирү учреждениеләре тарафыннан кабул итү имтиханы нәтиҗәсе диеп танылa. Шулай итеп, дәүләт имтиханнарын рус телендә генә үткәрү кешеләрнең югары белем алуга хокукын һәм кешенең төп хокукларын, ирекен чикли, тел һәм милләт билгеләре буенча дискриминация ясый. Югарыдагы приказ Россия Конституциясен дә боза. Конституциянең 19 нчы маддәсе кеше хокукларын социаль, раса, милләт, тел яки дин билгеләре белән чикләүне тыя. 26 нчы маддәдә туган телне куллану, аралашу телен, уку, тәрбия, иҗат телен сайлау ирекe төп кеше хокуклары ирегенә кертелгән. 68 нче маддәдә Россия Федерациясе халыкларына туган телләрен сакларга, аларны өйрәнүгә һәм үстерүгә мөмкинлекләр тудыруга гарантия бирә. Россия Конституциясе ачыктан-ачык бозылса да, барлык дәрәҗәдәге Россия судлары бу приказны үз көчендә калдырды. Хәзер бу приказ халыкара Страссбург судында карала.

2009 елдан бирле уку-укытуның Федерация дәүләт стандартларын эшләү бара. Стандарт белем үзләштерүгә, уку-укыту шартларына, тәрбия нәтиҗәләренә таләпләр булып кабул ителә. Элек эшләнгән стандартлардан аермалы буларак, яңа стандарт, Европага ияреп, һәр белем циклы буенча компетенцияләр формасында бирелә. Бу компетенцияләр «Европа Советы һәм Парламенты тәкъдимнәрендә» (2006 ел, 18 декабрь, №2006/692/ЕС) аңлатып бирелә. Аларны 2 группага бүлеп була: гомуми (универсаль, төп, һөнәрдән тыш) һәм махсус (һөнәри). Гомуми группага 8 төп компетенция керә, шулар арасында беренче урында — туган телне белү компетенциясе. Еврокомиссия тәкъдимнәре буенча Болон процессына катнашучы илләрдә балалар бакчасыннан алып югары белемнән соң укуга кадәр туган телдә аралаша алу иң мөһим һәм беренче компетенция диеп санала. Россиянең Болон процессына катнашуына карамастан, яңа стандартта туган тел белү компетенциясе дәүләт теле буларак рус телен белү компетенциясенә алыштырылган.

Әлбәттә, Россия Конституциясе һәм халыкара документлар нигезендә туган телне белү төп компетенция булырга тиеш. Туган телен белмәгән кешеләр белемле, укымышлы диеп саналмаска һәм белем турында документ алмаска тиеш.

Туган телдән компетенциянең яңа стандартка кертелмәве очраклы хәл түгел. Россиянең элекке Президенты Д.А.Медведев Федераль Собраниегә юлламасында (2008 ел, 5 ноябрь): «Мәгариф системасы халык тормышының яшәү рәвешен формалаштыра, яңа буыннарга милләтнең кыйммәтләрен тапшыра», — ди. Россия халыклары телләре милләт кыйммәтенә керә алмый, димәк.

Шулай да белемнең Федерация дәүләт стандартлары барлык Россия гражданнарының телләрен һәм мәдәниятен саклауны тәэмин итсен өчен бөтен көчебезне берләштерергә тиешбез. Татар халкы өчен бу бигрәк тә мөһим, чөнки аның 75 проценты Татарстаннан читтә яши һәм бүгенге көндә туган телне өйрәнү мөмкинлегеннән мәхрүм. Татар теле һәм әдәбияты, татар халкы тарихы буенча Федераль дәүләт белем бирү стандартлары булуы татар телен саклау һәм өйрәнү буенча хәлне яхшыртырга мөмкин. Татарстанда тупланган тәҗрибә бу мөһим эштә ярдәм итә ала.

Федерация дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә төзелгән үрнәк программалар туган тел һәм әдәбият укытуда ирешелгән нәтиҗәләрне Россиянең барлык укучыларына җиткерергә тиеш.

Уку программалары составындагы база уку планнарының Россия составындагы республика мәктәпләре өчен дә варианты булу бик мөһим принципиаль мәсьәлә. Республикаларның дәүләт телләрен төп программаның мәҗбүри өлешендә укыту Россиянең «Мәгариф турында»гы законында гына түгел, калган норматив актларда да ныгытылган булырга тиеш.

Бу юнәлештә Татарстан Республикасында түбәндәге эшләр эшләнә.

ТР Дәүләт Советы Россия Дәүләт Думасына 309-ФЗ законына Россия субъектлары, мәгариф идарәсе органнарына туган телдә укыту-тәрбия һәм туган телне укыту үрнәк укыту программалары эшләү хокукы биргән үзгәрешләр кертү буенча закон кабул итү инициативасы белән чыкты.

ТР Хөкүмәте карары белән Федерация дәүләт белем стандартларын эшләү һәм тормышка ашыру буенча комиссия төзеде. Комиссиянең эшче төркеме стандартларның проектын тикшерүдә актив катнаша. Татарстанның катгый таләбе белән төп белем бирү программасының мәҗбүри өлешенә 3 сәгать күләмендә туган телне укыту кертелде.

ТР күпмилләтле мәгариф системасы өчен дәреслекләр һәм методик кулланмалар хәзерләү буенча Федерация пилот проектында катнаша. Беренче класс өчен рус һәм татар телендә дәреслек комплектлары хәзерләнеп, экспериментта катнаша торган мәктәпләргә җибәрелде. Кызганычка каршы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы икенче класс өчен дәреслек комплектларын бастырып чыгаруга финанслар бүлеп бирмәде, авторларның эшкәртмәләре кулъязма хәлендә калды.

Хәзерге вакытта башлангыч мәктәп һәм төп мәктәп өчен Федерация стандартлары расланган. Туган телне һәм әдәбиятны укытуга таләпләр рус теле һәм әдәбияты белән бертигез куелган. Төп мәктәпне тәмамлаганда, туган телләрдән дәүләт йомгаклау имтиханы каралган. Ләкин туган тел һәм әдәбияттан үрнәк программалар эшләнмәгән, шулай ук дәреслекләр хәзерләүгә нәшриятларга эш бирелмәгән. Республикаларның дәүләт телләрен укытуны күз алдында тоткан база уку планнары варианты да каралмаган. Киресенчә, хәзер Россиянең «Мәгариф турында»гы законында республика дәүләт телләрен укытуны төшереп калдыру буенча Россия Федерациясе Дәүләт Думасында фикер алышу бара.

Безнең уебызча, Россиядә халыкларның телләрен һәм мәдәниятен саклап калу өчен, түбәндәге оештыру чаралары сорала:

1. 309-ФЗ законына Россия субъектларына туган телдә укыту-тәрбия һәм туган телне укыту үрнәк төп программаларын, укыту-методик әсбапларын эшләргә мөмкинлек бирә торган үзгәрешләр кертергә.

2. «Мәгариф турында»гы Федерация законына:

— гражданнарның Конституциядә каралган хокукын — туган телдә урта белем алуны;

— аккредитацияләнгән дәүләти булмаган мәгариф учреждениеләрен норматив нигездә бюджеттан финанслауны тәэмин итүче үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә;

3. Дәүләт һәм муниципалитет структураларына туган телдә укуны һәм туган тел өйрәнүне тәэмин итүче штат берәмлекләре кертергә;

4. Туган телдә уку-укыту методик әсбапларын, дәреслекләрне нәшер итү, рецензияләү буенча Бөтенроссия структурасы төзергә;

5. Федерация дәүләт белем стандартларына төп компетенция итеп туган телне белүне һәм 9, 11 нче класларда туган тел һәм әдәбияттан дәүләт йомгаклау имтиханнарын кертергә;

6. Бөтенроссия күләмендә расларга:

— туган телдә эшли торган балалар бакчасы, урта гомуми һәм өстәмә белем бирү учреждениеләренең нигезләмәләрен;

— туган телдә эшли торган мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләре өчен инструкцияләрне;

7. Туган телне өйрәнүгә һәм туган телдә укуга тудырылган шартларга федерация мониторинг системасы төзергә;

8. Урта гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына дәүләт йомгаклау аттестациясен рус телендә генә уздыру нигезләмәсен гамәлдән чыгарырга.

Хәзерге шартларда Россия халыкларын саклап калу өчен, мәгарифнең эчтәлеге күпмәдәниятлегә әйләнергә тиеш, ә мәгариф системасы табигыйлек юнәлеше принципларында төзелер дип уйлыйбыз. Милли мәгариф оешмалары формасы ягыннан заманча, эчтәлеге ягыннан милли булырга тиеш.

Әдәбият:

1. Александрова О.А. Образование: доступность или качество — последствия выбора // Знание. Понимание. Умение. — 2005. — №2. — С.83-93.
2. Воробьёв Ю.Л. Периферийный рынок образовательных услуг: взгляд из провинции // Знание. Понимание. Умение. — 2005. — №3. — С.62-70.
3. Библер В.С. Культура. Диалог культур: опыт определения // Вопросы философии. — 1989. — №6.
4. Бондаревская Е.В. Воспитание как возрождение гражданина, человека культуры и нравственности. — Ростов-на-Дону, 1995.
5. Крылова Н.Б. Как мы можем изменить культурные ценности образования // Народное образование. — 1998. — №9.
6. Овсянников К.К. Проблема адаптации иноязычных детей в русской школе // Актуальные вопросы национального образования: поиски, проблемы, решения. Тезисы докладов и тематические материалы V традиционной ежегодной научно-практической конференции «Культура и образование национальных обществ Сибири». — Новосибирск, 2002. — С.40.
7. Тихомирова Р.Ш. Роль Новосибирского областного Татарского культурного центра в деле сохранения и развития национального образования // Актуальные вопросы национального образования: поиски, проблемы, решения: Тезисы докладов и тематические материалы V традиционной ежегодной научно-практической конференции «Культура и образование национальных обществ Сибири». — Новосибирск, 2002. — С.23-25.
8. Актуальные проблемы развития национальных образовательных учреждений коренных малочисленных народов Ханты-Мансийского автономного округа / Под ред. Л.Г.Лазаревой. — Ханты-Мансийск: ГУО. Комитет по делам малочисленных народов Севера администрации ХМАО. — 1996. — С.21-28.
9. Волков Г.Н. Основные пути развития национальной школы и ее современные проблемы // Проблемы двуязычия в национальной школе. — Ижевск: Удмуртия, 1989. — С.33-34.
10. Зубарева С.Л. Развитие образования народов Севера в Ханты-Мансийском автономном округе (1990-е гг. — начало XXI века). Сургут: Изд-во СГПИ, 2003. — С. 32-34.
11. Пичкуренко Л.Ю. Развитие педагогической мысли в России и Германии в девятнадцатом-двадцатом веках в аспекте проблемы национального образования: Дисс... канд. пед. наук. — Саратов, 2001. — С.145.
12. Гончаров Н.К. Педагогическая система К.Д.Ушинского. — М., 1974.
13. Белозёрцев Е.П. О национально-государственном образовании в России // Педагогика. — 1998. — № 3. — С. 30-35.
14. Ганичев В.Н. Не быть иностранцами «посреди своей Родины» // Народное образование. — 1994. — №6.
15. Бэнкс Д. Мультикультурное образование: цели и измерения // Новые ценности образования. — 1996. — №4.
16. Дмитриев Г.Д. Многокультурность как дидактический принцип // Педагогика. — 2000. — №10.
17. Гукаленко О.В. Теоретико-методологические ос-

новы педагогической поддержки и защиты учащихся-мигрантов в поликультурном образовательном пространстве. — Тирасполь, 2000.
18. Бондаревская Е.В. Теория и практика личностно-ориентированного образования. — Ростов-на-Дону, 2000.
19. Автайкин И.Е. Проблемы национального образования в республике Мордовия // Успехи современного естествознания. — 2004. — №11. — С.47-48.
20. Бацын В.К., Кузьмин М.Н. Национальные проблемы образования в Российской Федерации // Школа и мир культуры этносов. — М., 1995. — Вып. 2. — С.5-30.
21. Гаврилюк В.В. Национальная культура и национальная школа // Образование в Сибири. — Томск, 1995. — №1. — С.62-67.
22. Галимов Р. О восстановлении в Москве национальных школ // Аргамак. — 1994. — № 1. — С.152-154.
23. Елаев Н.К. Настоящее и будущее бурятской национальной школы // Педагогика. — 1995. — № 2. — С.45-47.
24. Жирков Е.П. Как возродить национальную школу: Идеи и новые подходы. Концепция. Шаги Республики Саха (Якутия): Программа действий. Пути и механизмы реализации. — М., 1998.
25. Лотфуллин М., Гурьянова Р. Развитие национальной школы как общемировая тенденция // Татарстан. — 1996. — №6. — С.13-17.
26. Макаркин А.П. Национальные и региональные перспективы авторизованного образования [В Мордовии] // Вестник Моск. экстерного гуман. ун-та. — 1995. — №1. — С.22-23.
27. Максимовская М.В. Полиэтническая школа в Москве // Россия — 2010. — М., 1996. — №1. — С.67-68.
28. Морозов С. Школа Башкортостана: на пути к национальному возрождению // Народное образование. — 1994. — № 4. — С.84-95.
29. Национальная школа Российской Федерации: республиканские законы об образовании. / Сост.: В.Д.Данилов и др. — М.; Чебоксары, 1994.
30. Панькин А.Б. Образование для калмыков: (Истоки, реалии, перспективы): Моногр. — Элиста, 1997.
31. Попов А.А. Национальная школа у финно-угорских народов Европейского Севера Российской Федерации в 50-80-х гг.: На материалах Карел. и Коми респ. // Труды Института языка, литературы и истории. — РАН, Урал. отд-ние, Коми науч. центр. — 1993. — Вып. 56. — С.69-81.
32. Сукунов Х.Х., Величук А.П. Разработка типовой модели национальной школы (для школ Северного Кавказа) // Педагогика. — 1997. — №4. — С. 37-44.
33. Сулейманова Л.Ш. Создание и развитие национальных школ в Башкортостане в послеоктябрьский период. — Уфа, 1996.
34. Харисов Ф.Ф. Пути становления национальной школы // Научный Татарстан. — 1997. — №3/4. — С.79-82.
35. Целищева Н. Социальный институт нации: [Национальная школа] // Народное образование. — 1994. — № 4. — С.2-3.

КОНСТИТУЦИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Статья 26

1. Каждый вправе определять и указывать свою национальную принадлежность. Никто не может быть принужден к определению и указанию своей национальной принадлежности.

2. Каждый имеет право на пользование родным языком, на свободный выбор языка общения, воспитания, обучения и творчества.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯСЕ

34 нче маддә

1. Һәркем үзенең милләтен билгеләргә һәм күрсәтергә хокуклы. Беркем дә үз милләтен билгеләргә һәм күрсәтергә мәҗбүр ителә алмый.

2. Һәркем туган теленнән файдалану, аралашу, тәрбия, уку һәм иҗат итү телен ирекле сайлау хокукына ия.

Кушымта

Татарстан Республикасы мәгариф системасы турында кайбер статистик мәгълүматлар

2007-2012 елларда Татарстан Республикасында гомумбелем бирү учреждениеләре һәм аларда укучылар саны

	2007/2008 уку елы		2008/2009 уку елы		2009/2010 уку елы		2010/2011 уку елы		2011/2012 уку елы	
Белем бирү учреждениесенең тибы	Уч-ние саны	Уку-чылар саны	Уч-ние саны	Уку-чылар саны	Уч-ние саны	Уку-чылар саны	Уч-ние саны	Уку-чылар саны	Уч-ние саны	Уку-чылар саны
Барлыгы	2299	407708	2 352 (119 филиал)	400 224	2 298 (129 филиал)	393 658	2 164 (127 филиал)	383 355	1 913 (128 филиал)	379 003
Башлангыч	649	7281	769 (119 филиал)	7 487	735	6 932	633	6 209	503	5 697
Төп	225	11 397	232	11 477	221	10 216	236	10 302	283	14 326
Урта	1 333	375 455	1 259	366 872	1 249	362 372	1 207	354 270	1 044	347 097
Мөмкинлекләре һәм сәламәтлекләре чикләнгән балалар өчен мәктәпләр һәм класслар	53	5 671	52	5 653	51	5 796	51	6 083	51	610
Санатория мәктәп-интернатлары					3	302	3	300	3	303
Холкы начар булган балалар өчен мәктәпләр	1	52	1	49	1	73	1	79	1	76
Кичке мәктәпләр	31	6 896	31	7 744	30	7 073	24	5 043	17	4 171
Дәүләтнеке булмаган мәктәпләр	7	956	8	942	8	894	9	1 069	11	1 223
Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтә торган мәктәпләр	98	29 624	103	32 662	103	32 478	103	30 736	101	32 800
Гимназияләр	95	43 901	95	45 361	98	54 928	98	55 905	96	57 937
Лицейлар	42	14 574	43	16 879	42	24 312	41	24 574	44	27 545
Кадет мәктәпләр	14	3 085	15	5 530	17	6 396	17	7 532	17	8 052
Гомумбелем бирү мәктәпләрендә кадет класслар		1 017		2 176		2 556		4 014		3 281
Ятимнәр йортлары	14	537	11	475	12	585	12	544	12	474

Татарстан Республикасы шәһәр һәм авылларының гомумбелем бирү учреждениеләрендә укучыларның саны

Күрсәткечләр	2007/2008 уку елы	2008/2009 уку елы	2009/2010 уку елы	2010/2011 уку елы	2011/2012 уку елы	2012/2013 уку елы (прогноз)	2013/2014 уку елы (прогноз)
Гомумбелем бирү мәктәпләрендә барлык укучыларның саны	399 856	391 538	385 691	377 243	373 609	371 677	372 961
Шәһәрләрдә	283 117	280 201	279 863	277 670	279 753	281 253	284 528
Авылларда	116 739	111 337	105 828	99 573	93 856	90 424	88 433

Татарстан Республикасында милли мәгариф турында мәгълүмат

	2008/2009 уку елы	2009/2010 уку елы	2010/2011 уку елы	2011/2012 уку елы
Барлык татар гомумбелем бирү мәктәпләре	1 138	1 061	966	852
Аларда гыйлем алучылар	76 577	81 899	72 360	71 415*
Яңа типтагы татар уку йортлары	98	98 (аларның 24 рус-татар иннов. мәктәбе)	71	69
Аларда гыйлем алучылар	23 068	29 102	23 320	26 556
Катнаш мәктәпләр (татар-рус, рус-татар)	356	400	387	371
Аларда класслар	1 411	1 370	1 081	885
Укучылар	22 033	19 462	16 874	15 035
ТРда гыйлем алучы татарлар саны	202 904	192 371	185 392	180 621
Алардан туган телендә укучылар	96 599	93 079	85 516	80 222
Татар телендә укуның өлеше % ларда	47,6	48,4	46,13	44,41
ТР гомумбелем бирү мәктәпләрендә укучыларның саны	385 836	379 520	370 781	367 120
Алардан татар телен өйрәнүчеләр	385 508	379 520	370 781	367 120
Татар телен өйрәнүчеләр, % ларда	99,9	100	100	100
Чуваш этнокультура компоненты булган мәктәпләр саны, аларда укучылар	114/8 041	120/7 392	118/7 193	97/6 754
Мари этнокультура компоненты булган мәктәпләр саны, аларда укучылар	20/887	21/850	20/803	18/709
Удмурт этнокультура компоненты булган мәктәпләр саны, аларда укучылар	41/1 849	41/1 806	37/1 677	34/1 578
Мордва этнокультура компоненты булган мәктәпләр саны, аларда укучылар	5/112	5/103	5/122	3/88
Башкорт этнокультура компоненты булган мәктәпләр саны, аларда укучылар	1/27	1/12	1/11	1/9
Яһүд этнокультура компоненты булган мәктәпләр саны, аларда укучылар	1/257	1/221	1/270	1/251

* Татар телендә укытыла торган классларда — 65 187, ә рус телендә укытыла торган классларда 6 228 бала укый.

Якшәмбе мәктәпләрендә республикада яшәүче 28 милләтнең телен өйрәтәләр: мордва, чуваш, удмурт, башкорт, азәрбайҗан, украин, әрмән, осетин, таҗик, ассирий, әфган, грек, поляк, немец, яһүд, грузин һ.б. телләр.

Мәгълүматлар Татарстан Республикасы Мәгариф министрлыгының матбугат үзәгеннән алынды.

СҮНМӘС ЙОЛДЫЗЛАР

РӘДИФ ГАТАШ

Гасырларның караңгысын ерткан
Йолдыз булып туган театр,
Тукай васыятьләрен истә тотып,
Бик күпләрне әле уятыр.
Мәңге аны чорлар
Раушан көзге —
Бөек рух көзгесе санарлар.
Һаман исән —
Халык йөрәгеннән
Юлын алган бөек «Сәйяр» бар.
Гүя чатыр,
Түбәсенә — йолдыз
Айлы күкнең үзе ябылган,
Гүя
Берчак сүнгән йолдызларын
Сүнмәс итеп кабат кабызган
Театрда бәйрәм:
Гүя алар —
Волжская, Камал, Карилар,
Тинчуриннар —
Ерак йолдызлардан
Изге йортка сөенеп карыйлар.

...Еллар үткән саен актың арта,
Раушан көзгең тарта, театр.
Халык рухын киләчәккә илтер,
Бик күпләрне әле уятыр
Йолдызларың синең,
Театр,
Сүнмәс йолдызларың...

МОННАН 20 ЕЛ ЭЛЕК ТАТАРСТАНДА БЕРЕНЧЕ РЕСПУБЛИКА ТАТАР-ТӨРЕК ЛИЦЕЕ АЧЫЛА. ЮБИЛЕЙ УҢАЕННАН БЕЗ АНЫҢ ДИРЕКТОРЫ ФИЛОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ КАНДИДАТЫ, ЮГАРЫ КВАЛИФИКАЦИЯЛЕ УКЫТУЧЫ МӨХӘММӘТОВ ИЛДАР РИНАТ УЛЫНА БЕРНИЧӘ СОРАУ БЕЛӘН МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕК. СОРАУЛАРЫБЫЗ МӘГАРИФ ТОРЫШЫ, МӘКТӘПЛӘР, УКЫТУЧЫ ҺӘМ УКУЧЫЛАР, АЕРЫМ АЛГАНДА, УЛ ҖИТӘКЛӘГӘН УКУ ЙОРТЫ ТУРЫНДА ИДЕ...

КАЗАН КАЛАСЫНДА 2 нче ЛИЦЕЙ-ИНТЕРНАТ ОЕШУГА 20 ЕЛ

ЗАМАНА МӘКТӘБЕ

ИЛДАР МӨХӘММӘТОВ,
Казан каласының 2 нче лицей-интернаты директоры, филология фәннәре кандидаты

Казан шәһәренең Мәскәү районында урнашкан 2 нче лицей-интернат (элекеге татар-төрек лицее) Татарстан белән Төркия арасындагы хезмәттәшлек турындагы килешү нәтиҗәсендә ачыла. 1992 елның 31 августында Татарстан Республикасының беренче мәгариф министры В.Г.Гайфуллин кул куйган боерыкта бу уку йорты экспериментальь мәктәп статусын ала. Чыннан да, ул вакыт өчен бу яңа күренеш була. Дәүләтләр арасында әле, гомумән, хезмәттәшлек тәҗрибәләре бик булмаган шартларда, төрекләр белән бергә уртак фикергә килеп, яңа мәктәп ачу министрлык хезмәткәрләреннән һәм тәвәккәллек, һәм сабырлык, һәм алдынгы фикерле кешеләр булуларын таләп итә. Уку йортының 20 еллык тарихы 1992 елда башланган адымнарның дөрес икәнлеген раслый.

20 ел эчендә, әлбәттә, бик күп нәрсә үзгәреш кичерә. Бу — табигый процесс, һәрнәрсә үсештә булырга тиеш. Бүгенге көндә уку йорты, яшьлек чорын кичерсә дә, аның бай традицияләре, көчле һәм бердәм мөгаллимнәр командасы белән килеп җитте. Соңгы елда лицей коллективының Россия һәм Татарстан Президентларының рәхмәт хатлары белән бүләкләнүе уку йорты эшчәнлегенә иң югары бәя бирү дип аңларга була.

Лицейны башка мәктәпләрдән ни аера соң?! Аның белем һәм тәрбия бирү фәлсәфәсе нинди? Лицей балаларны 6 нчы сыйныфтан соң кабул итә. Мондый мәктәпләр Казанда 6 гына. Мәктәпкә бирелгән лицей статусы уку-укыту барышында игътибарны күбрәк төгәл фәннәргә юнәлдерүне сорый. Безнең мәктәп өчен бу табигый, чөнки лицеебызда бары тик ир-егетләр генә укый.

Икенчедән, лицей пансионат системасында эшли. Лицей каршында пансионат булу сәләтле балаларны Казаннан гына түгел, ә Татарстанның төрле районнарыннан, хәтта Россиянең төрле төбәкләреннән җәлеп итәргә мөмкинлек бирә. Мондый уку йортларының ачылуын үз вакытында «Яңа мәктәбебез» башлангычы астында Россия Федерациясенең элекке президенты Д.А.Медведев та хуплап чыккан иде. Дөнья тәҗрибәсенә күз салсак, бик күп илләрдә иң алдынгы уку йортлары нәкъ менә пансионат системасында эшли. Бу балаларны бердәм булырга, командада эшли алуга, компромисслар табуга, конфликтларны тыныч, салкынлык белән чишүгә өйрәтә. Нәтиҗәдә, балалар тормышка тагын да әзерлеклерәк, мөстәкыйльрәк булып чыгалар. Уку йортыбызның тәҗрибәсе дә моны яхшы раслый, әти-әниләрнең мәктәбебезне сайлауларының бер сәбәбе булып шушы фактор тора.

Өченчедән, лицейда бары тик ир балалар гына укый. Аерым укыту — дөньяда киң таралган күренеш. Аның фәнни нигезе дә бар. Кызлар белән малайлар төрлечә җитлегә. Гадәттә, кызлар яшьтәш ир угланнардан 1,5-2 елга тизрәк физиологик үсеш кичерә. Кыз һәм ир баланың уку үзенчәлекләре, мәгълүматны үзләштерү темпы, игътибарлылык дәрәҗәсе дә төрле. Бу юнәлештә дөньяда аерым фәнни институтлар эшләп, фәнни эзләнүләр алып баралар. Чит илдә чыккан фәнни әдәбиятны күзәтеп барудан аерым укытуның, чыннан да, нигезсез булмавын, уку процессына уңай йогынты ясавын аңлыйсың. Илебездә әле Совет чорында да билгеле бер вакытка кадәр аерым укыту таралган булган.

Дүртенчедән, уку йорты белем бирүдә күптеллелекне нигез итеп ала. Балалар рус, татар, инглиз,

төрек телләрен өйрәнәләр. Моннан тыш кайбер фәннәрне өйрәнүдә инглиз теле кулланыла. 7 нче сыйныфта балалар инглиз телен тирәнтен үзләштергәннән соң, 8 нче сыйныфтан математика, физика, химия фәннәре билингваль нигездә укытыла. Тел — ул мәдәниятнең аерылгысыз өлеше. Укучы күбрәк тел белгән саен камилләшә, көндәшлеккә сәләтлерәк була. Соңгы елларда Россия күләмендә полилингваль укыту системасы тагын да киңрәк тарала башлады, бүген эксперимент рәвешендә аны берничә төбәк кулланып карый. Татарстаныбызда да яңа ачылган уку йортлары полилингваль укыту системасын сайларга тырыша.

Бишенчедән, уку йорты сәләтле балалар белән эшли. Уку йортына кабул итү конкурс нигезендә бара. 2010 елда лицей сәләтле балалар белән эшли торган мәктәп статусын алды. Муниципаль мәктәп өчен бу яңа күренеш. Мәсьәлә шунда: Россиядә сәләтле балалар белән эшли торган мәктәпләр, гадәттә, югары уку йортлары каршында ачылалар. Шундыйлардан атаклы Мәскәү, Санкт-Петербург, Новосибирск, Екатеринбург мәктәпләрен атап була. Ә менә муниципалитетлар ачкан мәктәпләр бу көнгә кадәр андый статустан мәхрүм кала бирде һәм барлык балаларны кабул итәргә мәҗбүр иде. «Мәгариф турында»гы законны карап чыгып, без 50 нче маддәгә юлыктык. Анда Россия субъектлары һәм муниципаль хакимият үз карамакларында сәләтле балалар белән эшли торган мәктәпләр ача ала диелгән. Без шундый инициатива белән мәгариф идарәсенә чыктык. Ул безне хуплады. Нәтиҗәдә Казанда сәләтле балалар белән эшли торган 6 мәктәп барлыкка килде. Бу мәктәпләр рәсми рәвештә, хокукый яктан дөрес итеп конкурс игълан итә ала. Документ нигезендә конкурс ике турда оештырылырга тиеш. Моның өчен шәһәр комиссиясе төзелә. Бездә конкурсның беренче туры апрель-май айларында ук башлана. Беренче турга 6 нчы сыйныфта укый торган малайлар килә ала. Алар рус теле һәм математикадан тест узалар. Икенче турга без беренче турда яхшы нәтиҗәләр

күрсәткәннәрне чакырабыз. Алар 3 көн буена пансионатта яши, дәрескә йөри, спорт чараларында катнаша. Кыскасы, үзләрен һәрьяклап күрсәтәләр. Моның нәтиҗәсендә педагоглар баланың лицейда укый алу-алмавы турында карар бирә. Сүз уңаеннан шуны әйтергә кирәк: 2010 елда барлыкка килгән бу модель 2011 елда «Татарстан Республикасының иң яхшы 50 инновацион идеясе» конкурсында җиңеп чыкты, димәк ки, җәмәгатьчелек тарафыннан да уңай бәяләнде.

Сәләтле балалар белән эшне төрлечә оештырасың. Дәрес вакытында да, дәрестән соң да. Кызганыч, эшне киң һәм әтрафлы итеп оештыру өчен, финанс мөмкинлекләре җитеп бетми. Мондый мәктәпләрнең аерым финанс нормативлары булуы шарт. Берара бу турыда сүз куертканнар да иде. Ләкин үзгәрешләр күренмәде. Бүгенге көндә, әйтик, лицейда сәләтле балалар өчен 15 олимпиада клубы оештырылган. Клуб дип без төрле яшьтәге балаларның бер урынга килеп, аерым фән буенча җитәкче карамагында берөзлексез һәм системалы рәвештә шөгыльләнү оешмасын атыйбыз. Балалар өчен бу клуб эшчәнлегендә катнашу бушлай. Мәктәп мондый эшчәнлекне оештыру өчен, елына зур акча тота, без аны бюджет хисабына түгел, ә үзебез эшләп тапкан акчага оештырырга мәҗбүр. Әлбәттә, бу бик үк дөрес һәм гадел түгел, чөнки дәүләт сәләтле балаларга, һичшиксез, үсү шартлары тудырырга тиеш. Дәүләт тарафыннан мәктәпкә ярдәм итү юлларын табу мөмкин. Әйтик, республика министрлыгы сәләтле балалар белән эшли торган мәктәпләр өчен грантлар бирә алыр һәм бу акча, мәктәпләргә иң яхшы белгечләрне җәлеп итеп, эшне тиешле дәрәҗәдә оештырырга мөмкинлек бирер иде. Бүгенге көндә исә мәктәп җитәкчелегенә акча эзләргә, киләсе көн өчен борчылып торырга туры килә. Сәләтле балалар белән оештырылган мондый эшчәнлек зур нәтиҗәләр дә бирә. Күрсәткечләр югары. Лицей олимпиада хәрәкәтендә алдынгы урыннарда тора. 2003-2010 еллар арасында үткән Россия күләмендәге олимпиадаларда җиңүчеләр саны буенча лицей тарих һәм инглиз теленнән 50 мең мәктәп арасында I урында, ә биологиядән V урында тора. Башка бер мәктәп тә 3 юнәлеш буенча мондый күрсәткечкә ия түгел. Бу — мөгаллимнәр һәм балалар тырышлыгы. Димәк, эшне тиешенчә оештырсаң, нәтиҗә дә алырга мөмкин.

Алтынчыдан, лицейның мөгаллимнәр командасы бик тә үзенчәлекле. Ул 70% ир-ат укытучылардан тора һәм күпчелек педагоглар, бигрәк тә сыйныф җитәкчеләре, тәрбиячеләр — яшьләр. Бу лицейга килүче һәркемнең игътибарын җәлеп итә. Гадәттә, мәктәпләрдә ир-ат укытучылар саны 7-9% тан узмый. Бу безнең илгә хас күренеш. Ни өчен икәне аңлашыла булса кирәк. Яшь укытучыларга кайбер әти-әниләр шикләнеп карый. Булдыра алырлар микән дигән шик белән киләләр. Мондыйларга һәрвакыт лицейдагы укыту һәм тәрбия бирү үзенчәлеген аңлатырга туры килә. Шөбһәсез, өлгергәнлек чорына килеп җиткән малайларга үрнәк укытучы, тәрбияче абый моделе бик мөһим. Бу яшьтә балаларны урамның тискәре йогынтысыннан саклап калу, киңәш бирү, абыйларча аларга юнәлеш күрсәтеп тору тискәре күренешләргә каршы иммунитеты булган шәхесләр тәрбияләүдә бик кирәк. Моны тәҗрибәле олырак яшьтәге абый-апалар да эшли ала, әлбәттә. Тәрбия процессында алар да катнаша. Беркем инкарь итми, ләкин

алардан күпкә зур булмаган, аларны бик яхшы аңлаган, үзләре дә шул чорны күптән түгел узган, башларыннан кичергән яшь абыйлары аеруча тәэсирле авторитетка әйләнә. Кыскасы, лицейның белем һәм тәрбия бирү фәлсәфәсенең нигезендә бик гади нәрсә — үрнәк булырга тырышу, үгет-нәсихәттән бигрәк, хәл-хәрәкәт белән төрле социаль модельләрдә үз-үзеңне ничек тотарга тиешлеген күрсәтү ята. Бала, коры сүздән бигрәк, менә шул уңай атмосферада йөри-йөри, үзе дә эти-әниләренә, олыларга ихтирамлы, кечеләргә шәфкатьле, белемгә хирыс булырга өйрәнә. Бу процесс бик әкрен һәм сизелмәслек дәрәҗәдә бара. Гомумән, күп күзәтүләрдән соң шәхсән мин, кешенең, аеруча да бала кешенең бүгенге көндә шәфкать-мәрхәмәткә, җылы караш-сүзгә мохтаҗ булуын күрдем, ә әйләнә-тирә дөнья бик тә кырыс һәм дорфа.

Әлбәттә, кайвакыт сораулар да туа: балалар инсафлы, тәрбияле булып чыксалар, бу дөнья шартларында яши-эшли алырлармы? Моңа җавап бирү авыр. Ике юлдан берьюлы барып булмый: я алай, я болай. Лицейда укып чыккан егетләрнең югалып калмавы, үз урыннарын табулары, уңышларга ирешүләре мондый шикләрне тарата, минемчә. Лицейда тәҗрибәле, өлкән яштәге укытучылар да эшли, алар лицей белем бирү системасының умыртка сөяге булып торалар. Ул тәҗрибәле укытучылардан үрнәк ала-ала, яшьләр дә эшкә өйрәнә, педагогик тәҗрибә казана. Лицейның уңышлары да тәҗрибәле укытучыларның хикмәте, яшьләрнең дәртле җимеше, нәтиҗәсе. Менә шундый тәҗрибә алыш-бирешендә, бердәм хәрәкәттә, өлкән укытучыларның яшьләргә һәрвакыт юнәлеш биреп торулары барышында бердәм педагоглар, мөгаллимнәр командасы туа. Минемчә, мәктәп өчен, аерым укытучыдан бигрәк, бер фикер белән янып яшәгән, үз эшенә битараф булмаган педагоглар командасы тагын да әһәмиятлерәк. Мәктәп җитәкчесенең төп эше дә менә шундый команда булдыру, аны һәрдаим яңа җиңүләргә ялкынландырып тору. Кызганыч, күп очракта мәктәп системасында иҗади кешеләр эшли алмый, аларны көндәлек эшләр басып китә, андыйлар мәктәптән качу ягын карый.

Укытучыларның бертуктаусыз

һөнәри үсешен тәэмин итү дә мәктәп җитәкчелегенең төп эше булып тора. Бер урында туктап калган укытучы белән ерак барып булмый. Балалар шунда ук сканер рәвешендә кешенең интеллектуаль кырын сиземләп, үлчәп алалар. Әгәр укытучының тулы шәхес икәнлеге, гел үсештә, укучылар белән бергә гел эзләнүдә булуы ачыкланса, укучылар өчен андый педагог хөрмәткә ия. Юк икән, дәресләрдә «карга санау»лар, берберләре белән шыпырт кына гәп корып утырулар котылгысыз хәл. Без лицей укытучыларына мөмкин кадәр уңай шартлар тудырырга тырышабыз. Аларны төрле семинар, бәйге, конференцияләрдә катнашуга, мастер-класслар уздыруга, докладлар белән чыгыш ясауга этәрәбез. Узган ел, әйтик, лицей коллективының күп укытучылары Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан оештырылган «Сингапур белгечләре» курсларында катнашты. Дөньяда иң алдынгы технологияләр белән танышу укытучыларны үстереп җибәрде, аларны тагын да үз эшләрендә эшләргә кирәклегенә ышандырды. Быел исә узган елның иң яхшы белгечләре үзләре үк Сингапур белгечләре белән дәрес бирделәр, аларга ярдәм иттеләр, тьютор вазифасын башкардылар. Иң әһәмиятлесе: бер башланган процессны туктатмау, укытучыга һәрвакыт таяныч булып тору.

Быел без тагын бер проектка керештек. Лицей укытучыларының полилингваль шәхесләр икәнлеген истә тотып, Европа халыкара мәктәпләр ассоциациясе (ECIS) әгъзасы статусын алдык. Әйтергә кирәк, бөтен Россиядә андый мәктәпләр бишәү генә. Бу статус безгә нәкъ менә укытучыларның һөнәри үсешен яңа үрләргә күтәрү өчен кирәк, чөнки бу оешма бөтен җир шарыннан иң яхшы укытучыларны җыеп, бик кызыклы чаралар уздыра. Шул чараларда катнашу, һичшиксез, безгә дә дөнья күләмендә барган процессларны күзәтеп барырга, дөньядан артта калмаска ярдәм итәчәк.

Безнең мәктәп тә илебез мәгариф системасының бер өлеше булып тора, бездәге проблемалар барлык мәктәпләр өчен дә уртак мәсьәләләр. Телисеңме-теләмисеңме, илдә барган процессларга битараф калып булмый, ул проблемалар турында уйланырга, фикер алышырга туры килә.

Мәгариф өлкәсе дәүләтебездә өстенлекле юнәнелеш буларак игълан ителгән. «Мәгариф турында»гы канунда бу акка кара белән язылган. Башкачы булу мөмкин дә түгел. Илнең төп эше — халыкны аң-белемле итү. Калган бар юнәлешләр дә мәгарифнең торышына турыдан-туры бәйле. Кызганычка каршы, мәгариф тиз керем китерми. Дөресрәге, ул, гомумән, беренче карашка, керем китерми сыман. Аның кереме башка төрле, ул кеше потенциалына бәйле. Мәгариф алга киткән саен, икътисад та көчле, югары дәрәҗәле белгечләргә ия була, инновацион юнәлештә хәрәкәт итә ала, халыкның яшәү дәрәҗәсе арта бара һ.б. Кайвакыт җитәкчеләр: «Менә без мәгариф өлкәсенә бюджетның күпме өлешен аерып бирәбез», — дип горурланып сөйлиләр. Бик дөрес, ләкин бу бит табигый хәл. Ил халкының күпчелегенә бәйле булган мәгариф акчасыз утырырга тиеш түгел. Аның зур өлеше бит кеше потенциалын үстерүгә түгел, ә, гади итеп әйткәндә, биналарга тотыла. Алга карап эш иткән җитәкчеләр генә мәгариф өлкәсенә үз игътибарларын җитди рәвештә юнәлдерәләр, зур инвестицияләрне шунда җәлеп итәләр. Дөньяда иң алдынгы илләр тәҗрибәсе моны бик яхшы күрсәтә.

Безнең илдә мәгариф өлкәсенә игъ-

тибар җитәрлек дип әйтеп булмый. Ул әле ясалма, халыкка охшарга тырышып, электоратка ярап ниндидер формаль төс ала, вакыт-вакыт сәясиләштерелә. Республикада хәл башкачарак. Бездә, чын мәгънәсендә, алдынгы карашлы җитәкчеләрнең эшләве халык өчен бик зур бәхет. Соңгы елларда тормышка ашырыла торган проектлар, «Киләчәк», «Бәләкәч» программалары — моның ачык күрсәткече. Республиканың бер адым алда баруы — бәхәссез. Алга таба да бу ялкынлы хәрәкәт сүрелмәс дип ышанасы килә.

Мәгариф өлкәсендә мәктәпнең урыны түрдә, үзәктә. Ул нинди булырга тиеш? Карашлар төрле булырга мөмкин, бер фикер дә абсолют хакыйкатькә дәгъваламаса да, фикер алыш-бирешендә хакыйкать туа. Менә, мәсәлән, кайбер дөньякүләм танылган белгечләр, мәктәпкә күпме акча түкмә — укыту сыйфаты нык үзгәрми дигән фикер әйтәләр. Ягъни бер баланы укытуга 20 мең түктеңме син, әллә 200 меңме — әллә ни аерма юк. Пародокс, беренче карашка, ләкин монда дөреслек тә бар. Бу фикер ике яклы. Беренчедән, әгәр бер үк мөгаллимнәргә күбрәк акча түли башласаң, вазгыять, чыннан да, әллә ни үзгәрмәячәк. Баштарак бераз хәрәкәтләнү булса да, соңыннан ул сүреләчәк, кеше «камырын» үзгәртеп булмый. Мондый фикер сөреше дәүләт җитәкчеләре өчен бик уңай. Эш хакын күтәрмәсәң дә була, укытучы уртача тормыш алып бара алса, социаль киеренкелек дәрәҗәсенә җитмәслек тәэмин ителгән булса ярый дигән ялгыш фикер туарга мөмкин. Чынбарлыкта, зуррак эш хакын, һичшиксез, түләргә кирәк. Хәзер түли башласаң, аның нәтиҗәсе 10-20 елдан соң гына күренә. Ягъни егерме елдан гына мәгариф өлкәсендә локаль түгел, ә системалы үзгәрешләр барлыкка килә: мәктәпкә көчлерәк, әзерлеклерәк, иҗадирак мөгаллимнәр йөз белән борыла. Бүгенге көндә исә мәктәп совет чорында үзен бу эшкә багышлаган фидакарьләр һәм яшь энтузиаст, Ходайдан педагог сәләте бирелгәннәр җилкәсендә.

Педагог нинди эш хакына лаек? Иң кимендә, икътисад буенча түгел, ә сәнәгать буенча уртача эш хакының 30%тан артык. Шуннан соң гына аңа җәмгыятьтә караш уңай булачак. Башта ата-аналар, соңыннан балалар тарафыннан. Моннан да артыгы кирәк түгелме? Мин шәхсән, моннан да артып китсә, мәктәпкә мөгаллимнәр түгел, «акча җеннәре» җыелыр дигән шик белән яшим. Мәктәптә бит барысын акча белән генә бәйләп бетереп булмый. Укы-укыту, тәрбия барышында җылы сүзне, көләч йөзне, эштән соң калып, балалар белән бергә төрле чаралар оештыруны нинди акча белән бәялисең. «Акча кортлары» балаларга да акча букчаларына карагандай карар сыман.

Эш хакы арткан саен, мәктәпнең тышкы күрсәткечләре ничек үзгәрер иде, дигән сорау мине шактый уйландыра. Иң төгәл күрсәткеч, минемчә — мәктәптәге хатын-кызлар, ир-атлар саны. Ни өчен икәне аңлашыла булса кирәк. Ул катнаш, гади мәктәптә 60%-40% булса, димәк, системалы үзгәрешләр барлыкка килгән дигән нәтиҗә ясарга була. Әлбәттә, бер эш хакы белән генә мәгариф системасын үзгәртеп була, дип әйтү дөреслеккә туры килмәс иде. Укытучыларның һөнәри әзерлеге, яңа технологияләр, мәктәпләрнең төрлелеге — алдынгы мәгариф системасын кору өчен барысы да мөһим. Ләкин укытучының социаль статусы барысыннан да әһәмиятле. Ул хәл ителми торып, башка юнәлешләргә акча түгү — буш хыял. ◢

ЙОСЫФ АКЧУРА ШӘРЕХЛӘВЕНДӘ XX ГАСЫР БАШЫ ТАТАР МИЛЛИ МӘКТӘБЕ

ЙОСЫФ АКЧУРАНЫ БҮГЕНГЕ УКУЧЫ, БЕРЕНЧЕ ЧИРАТТА, XX ГАСЫР БАШЫНЫҢ КҮРЕНЕКЛЕ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ, ҮЗЕНЕҢ ИҖТИМАГЫЙ, ФӘННИ ЭШЧӘНЛЕГЕ БЕЛӘН ТАТАР-ТӨРЕК МӘДӘНИ БАГЛАНЫШЛАРЫ ҮСЕШЕНӘ ЗУР ӨЛЕШ КЕРТКӘН ГАЛИМ, ТӨРКИЯДӘ ГОМЕР ИТКӘН ЕЛЛАРДА АНКАРА, ИСТАНБУЛ УНИВЕРСИТЕТЛАРЫ ПРОФЕССОРЫ БУЛАРАК БЕЛӘ.

Йосыф Акчура татар байлары нәселеннән. Аның әтисе Хәсән Акчурин — күренекле Сембер фабриканты, атасы Сөләйман Акчуриннан мирас итеп алган тупас йон тукыма җитештерүче өч фабрика хуҗасы. Әнисе Бибикәмәртбану — Казан сәүдәгәре Габдерәшит Юнысов кызы.

Уллары Йосыф 1876 елда туа. Фабрикалары бурычка батып, төрмә, Себер белән белән куркытылган хуҗабикә, улын алып, 1883 елда Төркиягә качарга мәҗбүр була. Шулай итеп, Йосыфның балачагы һәм үсмер еллары Истанбул шәһәрендә үтә. Биредә ул 1883-1886 елларны башлангыч мәктәптә, 1886-1892 елларны тулы булмаган урта (рөшдия) мәктәптә белем ала.

1892-1896 елларда хәрби мәктәптә укып, лейтенант дәрәҗәсе белән училищены тәмамлый. 1889 елга кадәр туган ил белән элемтәләр хат язышу аша гына була. 1889-1890 елларда беренче тапкыр Россиягә кайтып, туганнар белән аралашу, авылда һәм Казанда яшәү, төрле шәһәрләргә сәфәр кылу рәвешендә үтә. Шул кайтуында ул Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Кырымда Исмәгыйль Гаспралы белән таныша, фикерләшә. Бер сүз белән әйткәндә, Йосыф Акчура татар дөньясында башланып килгән европалашу хәрәкәтенең барышыннан яхшы ук хәбәрдар була.

1896 елда ул Төркиядә Генераль штаб каршындагы югары хәрби уку йортына укырга керсә дә, анда берничә атна гына укый. Яшерен «Яшь төрекләр» хәрәкәтенә тартылган була, заговорда катнашуда гаепләнеп, 1897 елда кулга алына һәм үлем җәзасына хөкем ителә. Тиздән мәхкәмә карары

Ливиядәге Сахара ком чүленә гомерлек сөрген белән алыштырыла. Триполи шәһәрендә төрмәдән чыгарыла, аңа ирекле яшәү мөмкинлеге бирелә: гаскәриләрдә писарь һәм мәктәптә укытучы булып эшли. Күзәтүнең йомшаруыннан файдаланып, 1899 елда бер төркем хәрбиләр белән көймәдә Туниска кача.

Йосыф Акчура Парижга килә һәм 1899-1903 елларда Сәяси фәннәр мәктәбендә укый. Европа тарихчылары, философлары, сәясәтчеләре, социологлары хезмәтләре белән таныша, күренекле галимнәрнең лекцияләрен тыңлый, алар белән аралаша, француз һәм төрек газеталарында мәкаләләр бастыра. Парижда яшәү аңа Европа халыклары тарихы һәм үсеше белән чагыштыру аша төрки халыкларның дөньяда тоткан урыннары, киләчәк язмышы турында уйлау мөмкинлеге тудыра.

1902 елны Париждагы Сорбонна университетына укырга Садри Максуди килә. Фатыйх Кәрими аңа баргач та Й.Акчура белән танышырга киңәш иткән, хат язып та милләттәшләрне дуслашырга чакырган була. Бу да Й.Акчураны берникадәр татар мохитенә якынайта. 1903 елны Кырымда, Бакчасарайда, «Тәрҗеман» газетасының 20 еллык юбилеен үзләре башлап оештыралар. Кунакка килгән күренекле татарлар белән танышалар, алар белән милләтнең киләчәге турында фикер алышалар.

Шулай итеп, төрек урта һәм югары мәктәпләрендә белем алган татар егете, Европа югары уку йортын уңышлы тәмамлап, 1903 ел азагында Россиягә кайтканда, татар дөньясы турында берникадәр формалашкан була. Габдеррәшит Ибраһимов Россия мөселманнарының сәяси партиясен оештыру эшенә алынган көннәреннән аның янәшәсендә бу эшне оештыруда катнаша. Шуның нәтиҗәсе буларак, Мөселман иттифакы партиясенең Үзәк комитет сәркатибе итеп сайлана.

Йосыф Акчура Париждан Сембер губернасындагы Акчуриннар фабрикалары урнашкан Зөябаш авылына кайткан була. 1904 елда Казанга килеп, Галимҗан Барудиның «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә тарих, география, төрек әдәбияты укытучысы булып урнаша. 1908 елда Төркиядә «Яшь төрекләр» революциясе баш-

лангач, реабилитацияләнә. Россиядә хөкемгә тартылган Й.Акчура, чираттагы төрмә, сөргеннән качып, 1908 елның октябрь башларында Төркиягә китә. Революция көннәрендә ул Оренбургта нәшер ителә торган «Вакыт» газетасының махсус хәбәрчесе булып эшли. Революция хәрәкәте тәмамлангач, эшсез калган белгеч кабат укытучылык эшенә кайта: үзе кулга алынган хәрби мәктәптә, соңрак ятимнәр йорты мәктәпләрендә тарих укытучысы булып эшли. 1909 елда Истанбул университетының әдәбият факультетында белем бирә [1]. 1911 елдан университетта сәяси тарих укыта башлый. Й.Акчура 1912 елда «Төрек учаклары» җәмгыятен оештыруда башлап йөри һәм җәмгыятьнең матбугат органына әйләнгән «Төрек учаклары», «Төрек йорды» исемле фәнни-популяр журналлар мөхәррире буларак хезмәт итә.

1912-1913 елларда Балкан сугышында катнаша. 1916-1917 елларда «Кызыл Ай» җәмгыятенең Германиядәге мөселман-төрки әсирләр арасындагы илчесе, 1919-1923 елларда кәмаллылар революциясе ягында көрәшә. 1925-1933 елларда — Анкара хокук мәктәбендә, 1933-1935 еллар арасында Истанбул университетында укыта. Галим 1935 елның 11 мартында вафат була [2].

...«Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә тарих укыта башлагач, Йосыф Акчура шәкертләренә кулланма рәвешендә, татар шәкертләрен һәм тарих укытучыларын Европадагы яңа тарих фәне методологиясе белән таныштыру максатында, «Голум вә тарих» исемле фәнни-теоретик хезмәт яза, аны 1907 елда бастырып чыгара...

1908 елның 16 сентябреннән октябрь урталарына кадәр — бер ай вакыт дәвамында — Төркиягә китәр алдыннан, «Вакыт» газетасында теоретик эчтәлекле, зур булмаган, хәтта тезислар рәвешендәрәк язылган мәкаләләр циклы бастыра. Цикл дүрт мәкаләдән тора. Аларның исемнәре: «Тел сугышы», «Милли мәдрәсәләр һәм әдәбият», «Мәдрәсәләрдә тарих дәресе укыту турында», «Мәдрәсәләр һәм гарәп теле». Мәкаләләр азагында авторның имзасы юк. Беренче ике имзасыз мәкаләләрнең «Вакыт»та редакцион мәкалә итеп урнаштырылуын исәпкә алып, бу язмалар тарих фәненә зур игътибар биргән редактор Ф.Кәриминең яисә мәшһүр галим Р.Фәхретдин хезмәтләре түгелме икән дигән фикер дә туа. Өченче мәкаләдә авторның: «Бу ике мәкаләмдә», — дип искәртүе хезмәтләрнең алдан ук бер цикл итеп эшләнүенә ишарә ясый. Язмаларда Й.Акчураның стиле, фикерләү-язу рәвеше, лексикасы шик калдырмаслык дәрәҗәдә күзгә бәрелеп тора.

Йосыф Акчура мәкаләләре татар милли мәктәбен эчтән белеп, Европа социология һәм педагогика фәне югарылыгында язылган. Ул еллардагы күпсанлы мәктәп-мәдрәсә темасына багышлап вакытлы матбугат битләрендә дөнья күргән кырыс тәнкыйди реализм стилендәге язмалардан аермалы буларак, автор, эмоцияләргә бирелмичә, үз фикерен дәлилләр ярдәмендә укучыга җиткерә.

Әлбәттә, Йосыф Акчураның хезмәтләре XX гасыр башы татар милли мәктәбен күздә тотып, аны киләчәктә реформалау юлларын билгеләргә омтылып язылган. Балаларга туган телдә белем бирү, милли әдәбият, тарих укыту өлкәләрендә бүген, йөз елдан соң, аларда күтәрелгән мәсьәләләрнең бер өлеше инде күптән хәл ителде.

Бер үк вакытта Йосыф Акчураның туган тел, милли әдәбият, тарих укытуның милли тәрбия һәм үзаң тәрбияләүдәге мөһим урыны турын-

дагы фикерләре бүген дә игътибарга лаек. Ислам динендә милләтләр (милләт — үзе милләт) юк, «татар теле әшәке тел» дип сөйләнүче кадимче муллаларның сүзләренә каршы килеп, Йосыф Акчура: «Мәктәп һәм мәдрәсәләрдә үз телләренең кагыйдәләрен өйрәнмәгән, үз телләренең кадерен белмәгән бер халыкта күпме миллият хисе булсын? — дигән сорау куя. — Күп милләтләр яшәгән җәмгыятьтә һәр халыкның туган телендә белем алуы киләчәген билгели, ул сәяси мәсьәләгә тиң», — дип ассызыклый.

«Милли мәдрәсәләр һәм әдәбият» исемле мәкаләсендә автор балаларны милли мәктәптә укыту теләгенең нигезендә аларны «үз кешебез, милли кеше итеп үстерү теләге» ята, дип билгеләп үтә. Аның милли мәктәптән, башлыча, әдәбиятыбызга хезмәт итүчеләр чыгарга тиеш дигән фикерен үстерсәң, милли мәктәп, беренче чиратта, гуманитар юнәлештә булырга тиеш дигән нәтиҗә барлыкка килә сыман.

«Мәдрәсә вә тарих дәресләре» исемле өченче мәкаләдә Й.Акчура тарих фәнен «гыйлем өйрәнүчене үз милләтен яклаучы итәр өчен җайланган дәресләрнең иң тәэсирлесе. Бу тәэсирдә иң көчлесе тарих дәресләре икәнендә шөбһә юк», — дип ачыктан-ачык яза. «Шуңа күрә милли мәдрәсәләребездә, тарихи вакыйгаларны үзебезчә тикшереп, үз ноктабыздан карап укытылырга тиеш». Икенче зур бурыч итеп автор татар галимнәренә туган халкы тарихын язу мөһимлеген куя.

Бер үк вакытта күп халыклар арасында яшәгән татарларның милли уку йорты күршеләрнең тарихы һәм мәдәнияте белән таныштыруны, күпмәдәниятле җәмгыятьтә алып торган үз урыннары хакында күзаллау булдыруны игътибар үзәгендә тотарга тиеш дигән фикерне дә уздыра.

Әдәбият:

1. Яңа төрек дәүләтенең уңчылары. — 1928. — Б.14.
2. Гиндогду Габдулла «Йосыф Акчурага күрә бүюк көчләр вә Османлы дәүләтенең екылышы. — Истанбул, 2010. — Б.20.

ТЕЛ СУГЫШЫ

Әгәр милләтләр аз гына уяна башласалар, алар «тел сугышы» башлыйлар. Македониядә болгар, серб, әүлаһ [румин], грек кебек халыкларның хәзергә кадәр булган барлык сугышлары тел өчен булганы кебек, моннан соң Төркиядә иң мөшкел булган мәсьәлә — тел мәсьәләсе булачак. Чөнки бер милләтнең ана теле, милләтнең рухы ул — милләтнең хәяте, ул — милләтнең киләчәге. Тел бетү — халык бетү, инкыйраз булу димәктер. Төркиядә шуның өчен хөрриятнең иң беренче көннәреннән үк тел һәм милләт мәсьәләсе кузгалды. Төркиядәге болгарлар, греклар, әрмәннәр үз телләрендә башлангыч, урта һәм югары мәктәпләр ачарга теләделәр. Төрекләр моңа разый булмыйлар. Башлангыч мәктәпләрдә ана телендә укытыра рөхсәт бирсәләр дә, урта һәм югары мәктәпләрдә төрек телен мәҗбүри итәргә тырышалар. Бу мәсьәлә барган саен кискенләшәчәк. Бераз милли хисләре кузгалу белән, Төркиядә, үз алдына, аерым яши торган арнаудлар [албаннар], гарәпләр, көрдләр дә үз телләрендә укытырга, үз телләрендә сөйләшергә,

мәхкәмәләргә үз телләрен кертергә таләп итәчәкләр. Әгәр моны төрекләр бирсәләр, хаким милләт үз кул астындагы төрле милләтләрне үзенә бәйләп, бер фикерлелеккә, бер хискә җыя алмаячак. Чөнки фикер һәм хис телгә буйсына. Әгәр бирмәсәләр, тел һәм миллият низагы, бетмәс-төкәнмәс дәвам итеп, илнең үсешенә һәм күтәрелешенә киртә булачак. Германиядә полякларга мәктәпләрдә дин дәресләрен дә үз телләрендә укыттырмыйлар, җыелышларында үз телләрендә сөйләштермиләр. Французлар Җәзаир гарәпләрен башлангыч сыйныфларыннан ук французча укыталар. Французлар, сан ягыннан күп, икенче яктан, мәдәният ягыннан да ул кавемнән өстен. Әмма төрекләр, Төркия дәүләтенең төрле халкы арасында 30-35%тан артык түгел. Мәгариф, мәдәният өлкәсендә дә греклар, болгарлар, әрмәннәрдән күп алда түгелләр. Македониядә «тел сугышы» өчен үз партияләрен булдырып, канлы көрәшкә күтәрелеп килгән төрле кавемнәрне «госманлылык», «төреклек» кул астына җыю үтә кыен эш. Төркиянең Милләт мәҗлесе — парламенты ачылгач та, бу тел һәм милләт сугышы бик нык сәхнәгә чыгачак. Төркиягә бик күп уңайсызлыклар китерер кебек күренә. Аеруча, Балкан ярымутравында, ничек булса да, тынычлык булмавын, төрекләрнең Европадан куылуын тели торган кайбер чит дәүләтләр бу тел һәм миллият мәсьәләсен аякландырырга тырышачаклар, һәм, хәзер дә нык тырышулары дикъкатькә алынса, Русиянең «җир мәсьәләсе» урынына Төркиянең тел мәсьәләсе аякка калкуы бик ихтимал. Балкан кавемнәренең «ана теле» өчен җан фида итәргә әзер торуларына карап, татар голәмәләреннән кайберәүләренең «Татар теле әкъбахел лисан» [әшәке тел], дигәннәрен күз алдына китерсәк, без сәясәттән ни дәрәҗәдә гафил [надан], миллияттән никадәр ерак булганыбыз бик ачык күренәчәк. Мәктәп һәм мәдрәсәләрендә үз телләренең кагыйдәләре өйрәтелмәгән — үз телләренең кадерен белмәгән бер халыкта күпме миллият хисе булсын?! Әгәр газета мөхәррирләре андый сүзләрне «картайган» һәм акчасыз шәкертләргә генә каратып әйтсәләр, әлбәттә, Галимҗан әфәнде хаклы булыр иде. Ләкин картайган һәм акчасыз шәкертләрдән башка, угылларын, энеләрен иске мәдрәсәләргә җибәреп укытырга һәм шул эшкә шактый күп акча тотарга әзер торучы һәм акча тотучы татар байлары да аз түгел, һич булмаса, баштагы вакытта шуларның балалары гыйлем, фәннәр, сәнгатьләр һәм сәүдә мәктәпләрендә укып чыксалар, картайган һәм акчасыз шәкертләргә ярдәм итүчеләр җитешә башлар иде. Әмма моңарга да өмет күренми.

Вакыт. — 1908. — № 370. — 16 сентябрь.

МИЛЛИ МӘДРӘСӘЛӘР ҺӘМ ӘДӘБИЯТ

Гәзитәләрдә мәдрәсә ислахы, мәдрәсәләрнең җитешмәгәнлеге хакында шулкадәр күп язылды ки, укучылар инде ул темага язылган мәкаләләрне укымастан ташлап үтәргә мәҗбүр була торганнардыр.

Мәдрәсәләр турында сөйләү күп булса да, сөйләнгән сүз [проблема-

лар] ул кадәр күп түгел. Мәдрәсәләр [бу сүзләр нәтиҗәсендә] үзләре алга китмәгән шикелле, алар турында язучылар да һаман бер урында әйләнәләр: иске мәдрәсәләрдә «Мохтасар» яки «Хөләса» укучылар, һәр көз сабакларын «Китабет-тәһарәт вә ән-нәҗасәт»тән башлаганнары кебек, мәдрәсә турында язучылар да әллә ничә еллар элек язылган нәрсәләрдән уза алмыйлар.

Искитмәслек түгел: мәдрәсәләребездә үз әдәбиятыбыз укытылу мәсьәләсе әлегәчә тиешенчә язылмаган, хәтта күтәрелмәгән! Һәммә җанлы, тере милләтләр берсе икенчесеннән башка үзләренә махсус мәдрәсәләр салдыралар. Боларда укытыла торган гомуми фәннәр барысында да бертөрле: хисапта, һәммәсендә ике икең — дүрт. Җәгърәфиядә, һәммәсендә, җир — биш кыйтга [материк]. Ни өчен һәр милләт үз мәктәбенә сарыла? Үз мәктәбе өчен тартыша, талаша — җиһад кыла? Тел өчен түгелме?! Рус мәктәпләрендә, иң мөһим дәрес — урыс теле, урыс әдәбияты. Немец мәктәпләрендә — немец теле, немец әдәбияты. Гарәп мәктәпләрендә — гарәп теле, гарәп әдәбияты. Фарсы мәктәпләрендә — фарсы теле, фарсы әдәбияты. Бер учлык [кечкенә] милләтләр — әрмән, норвегияле, даниялеләр мәктәпләрендә — һәммәсендә иң мөһим дәрес — үз телләре, үз әдәбиятлары. Без мескеннәрнең исә ислах ителгән мәдрәсәләребездә дә, атнага бер дәрес булсын, үз әдәбиятыбыз укытылмый! Яңа ысул милли мәдрәсәләребезне тәмам иткән егетләрнең үз әдәбиятыбыздан хәбәрдарлыклары — мөгаллимнәреннән рөхсәтсез укыган әкиятләр һәм газеталар аркылы гына түгелме? Яңа мәдрәсәләребез кануннары да укучыларының үз әдәбиятыбыз белән шөгыльләнүен теләми. Түбән сыйныфларда да сарыф төрки (төрки грамматика һәм имля [орфография] кагыйдәләре икенче дәрәҗәдәге дәресләр арасында, вак-вак нәрсәләр дип кенә күрсәтелгәнен инкяр итә алмыйбыз. Ә бит шул «әһәмиятсез нәрсәләр» ысул җәдитчеләрнең язуларын искеләрнеке [кадимчеләр] белән чагыштырып булмас дәрәҗәдә төзәтте. Әмма шуның белән генә чикләнеп калырга тиеш түгел иде.

Безнең мәдрәсәләребезнең иң әһәмиятле дәресе — үз телебез булырга тиеш. Балаларны ни өчен безнең мәдрәсәләргә бирәләр? Фән күрү, мәгърифәт хасыйл итү булса, рус һәм хөкүмәт мәктәпләре безнекеннән ун өлеш файдалылар. Балаларны, динле булсын өчен, безнең мәдрәсәләргә тапшыручылар да бу елларда күп булмаса кирәк. Чөнки мәдрәсә тәмамлаган кешеләрнең әхлак һәм динлелекләре, иманнары башлангыч мәктәп белән генә чикләнгән кешеләрнекенә караганда ныграк икәнен исбат итү читен. Күрәсең, балаларны милли мәдрәсәләребезгә бирүнең максаты — гадәттәгечә, фәннән хәбәрдар һәм мәгълүматлы булулары белән бергә үз кешебез, милли кеше итеп үстерү теләге күз алдында тотып эшләнә. Ә моның өчен барлык милләтләр тоткан юл — үз телен, үз әдәбиятын төпле итеп өйрәтү сорала. Кешеләрне яңа фикерләр белән баетуга да әдәбиятның тәэсире зур. Шуңа күрә шәкертләргә үз әдәбиятыбызны укыту аларның күңелләренә милләт һәм дин рухы сеңәчәгенә, хезмәт итәчәгенә шигебез юк. Моның өстенә без мәдрәсәләребездән кемнәр чыгуын көтәбез? Яңарган мәдрәсәләребезнең шәкертләре муллалыкка бик үк ихлас илә китмиләр. Ихлас илә яки мәҗбүри рәвештә сәүдәгәрлеккә китүче шәкертләр күп булса да, безнең яңа

мәдрәсәләрнең сәүдәгәрлеккә файдалылыгы муллалыкка файдалылыкларына караганда ким дәрәҗәдәдер.

Безнең мәдрәсәләребездән, башлыча, әдәбиятыбызга хезмәт итүчеләр чыгарга тиеш. Әдипләребез җитешер өчен иң мөнасиб [яраклы] урын — мәдрәсәләребездер. Казан, Оренбург, Уфадагы зур мәдрәсәләр, һәркайсы, әдәбият өчен бер әнҗемән [җәмгыять, түгәрәк, клуб] ролен уйнарга тиеш.

Телебезнең кагыйдәгә салынуына, төзәлүенә, матураюына, аны башка телләргә тиң үз бурычын үти алыр хәлгә китерүгә мәдрәсәләребез бурычлы һәм җаваплы. Әдәбият ысулы һәм тарихы турында язылган китапларыбыз юк дип, җиңел җавап белән акланып маташмыйк. Теләк булсын. Мәдрәсәләрдә таләп булгач, хаклы рәвештә йөз төрле гыйльме халь китабы чыгарылганын күреп торабыз.

Җәгърәфия, тарих, риазият [математика] китаплары да, түбән сыйфатлы булсалар да, берсе артыннан берсе агыла башладылар. Акрынлап чибәрләнә дә баралар. Шул тәҗрибәләргә таянып, ышанып әйтеп була ки: әгәр низамлы рәвештә [фәнни принципка нигезләп оештырган] мәдрәсәләребездә телебезнең художество ысулы [поэтикасы] һәм әдәбият тарихы дәрес итеп кертелсә, башта, кимчелекле булса да, укытучылар табылачагы һәм тиздән тиешле китаплар нәшер ителә башлаячагына шикләнмәскә була.

Вакыт. — 1908. — № 371. — 18 сентябрь.

МӘДРӘСӘЛӘРДӘ ТАРИХ ДӘРЕСЕ УКЫТУ ТУРЫНДА

Әлеккеге мәкаләбездә милли мәдрәсәләр өчен әдәбиятыбыз укытылуның әһәмиятен бәян итмеш идек. Милли мәдрәсәләрдә әдәбият янында ук мөһим нәрсәләр — тарих дәресләредер. Мәдрәсәләрне миллиләштергән нәрсәләрнең берсе дә тарих китапларының, тарих укытылуның рәвешедер.

Төрле дин әһелләре арасында дин тәгълиматы бер-берсеннән аермалы [башка] булганы кебек, төрле милләтләр арасында тарих тәгълиме дә шулай ук бер-берсенекенә башкадыр. Дин мәсьәләсе буенча ике капма-каршылык: «Берсе изге, рәхмәт яугыры, ахирәттә җәннәтлек. Икенчесе явыз, мәлгунь, тәмуглык», — дип хөкем ителсә, дөнья өчен тарих та шундый ук хөкем чыгарадыр. Берсенә каршы торган ике гаскәрне, ике милләтне, берсен — хаклы, файдага йөргән, икенчесен — хаксыз, зыянга йөргән итеп күрсәтү — тарих эшедер. Хәят [яшәеш] ызгышларны тасвирдан гыйбарәт булган тарих, инглиз мәктәбендә — инглизләрне, немец мәктәбендә немецләрне хаклы итеп күрсәтәдер. Бу күрсәтүләрнең саф калебне яшьләргә тәэсире гаҗәеп дәрәҗәдер. Гыйлем өйрәнүчене үз милләтен яклаучы итәр өчен җайланган дәресләрнең иң тәэсирлесе, бу тәэсирдә иң көчлесе тарих дәресләре икәнендә шөбһә юк. Анда, бер дә сиздерелмәгән бер рәвештә, гүя ки фән һәм хаклык [хакканият] исеменнән бер милләткә — ихлас, икенче милләтләргә нәфрәт хисе кузгатыла. Бу фикер белән бәхәсләшергә

мөмкин: фән тәгассебтән [фанатизмнан] югары торырга тиеш. Дөрестән дә, тарихның да миллилектән өстен торган китаплары бар. Һәм аз да түгел. Ләкин, гөнаһ шомлыгына диик, һичбер милләтнең урта дәрәҗәдәге мәктәпләрендә тарих дәресләре милләт тәгасебеннән котылганы юк. Миллият рухы көчәйтелгән дәрәҗәдә, [бер халыкның] тарих китаплары [икенчеләрнекеннән] үзгәрә бара.

«Милләт рухы нигә кирәк?» — дип сораучылар табылыр. Әмма безнең сүзебез милли мәдрәсәләр турысында. Аны торгызырга теләгән кешеләр өчен милләт рухы, ягъни миллият [миллилек] шәхес рухы шикелле үк котылгысыз мәҗбүри нәрсә. Шуңа күрә милли мәдрәсәләребездә тарихи вакыйгаларны үзебезчә мөхакәмә итеп [тикшереп], үз ноктабыздан карап укытылырга тиеш. Мәдрәсәләрдә тарихны милли рухлы итүнең икенче төрле кирәклеге дә бар. Һәр милләтнең тарихын җыеп язу сорала. Бу эш шул милләтнең үзенең эше булырга тиеш. Үзенең нәселе турында сөйләгән бер руска җиде бабасыннан бирле католик бер француз: «Синең нәфрәтләндергеч бабаларың турында тикшеренергә нигә кирәк?! Фәнгә хезмәт булырлык нәрсәдер теркәгәннәр икән, рәхмәт. Әмма алар моны синең тарихың булсын дип эшләмәгәннәр», — ди. Без халкыбыз тарихы булдыру бурычын үзебез үтәргә тиешбез. Моңа без бурычлыбыз. Милләтебез тарихыннан сибелгән, таралган нәрсәләрне үзебез эзлик. Булдыра алган кадәр табып-җыеп, шуларны мәйданга куйыйк. Шул юлда хезмәт итәргә сәләтле, яраклы эзләүчеләрне, алар эшен оештыручы оешмаларны булдырыйк. Шундый эшкә әзерлекле кешеләр тәрбияләү мәдрәсәләребез өстенә йөкләнә. Яңа ысулдагы мәдрәсәләребезне тәмамлаучылар тарихыбыздан, хәзергә кимчелекле дәрәҗәсендә генә булса да, азмы-күпме мәгълүмат алып, тарихи мәгълүматларны ничек җыярга икәнен белеп, күп йөздән берсенең, тарихка бирелгәне табылса, милләткә һәм тарихка зур хезмәт күрсәтүе өмет ителә.

Әлхәмдүлиллаһ! Яңа ысул мәктәп вә мәдрәсәләребездә тарих укытыла башлады. Аз вәкилчелекле укытучылар да, шөбһәсез, бик күп файда китерде. Әмма мәдрәсәләребезнең иң зур кимчелеге һаман тарих укыту өлкәсендә икәнен әйтмичә булмый. Мәктәпләрдә укыла торган «Кыйссасел әнбия» һич тарихка керми. Башка милләтләр моны дин дәресләре арасында гына укыталар. «Ислам тарихы» дип укытыла торган нәрсәләрнең дә исеме генә тарих, «Кыйссасел әнбия» дәвамы дип кенә саналырлык. Хәтта менә шуңардан да, һаваланып, мәдрәсәләргә хәзерге истилахча [термин] «дини мәдрәсәләр» исемен бирүдән тартыналар! Һәвәсе бар мөгаллимнәр христиан мәктәпләрендә христианлык тарихы ничек укытылганын күзәтсеннәр иде!

«Гомуми тарих» исемен зур шатлык белән программаларда күрәбез. Ләкин «исемен күрү» генә җитми. Башка милләт мәктәпләрендәге дәрәҗәдә укытылырга да тиеш. Әмма бездә дин тарихы, милләт тарихын башка милләт мәктәпләрендәге дәрәҗәдә укыту табылмый. Мәдрәсәләребезне тәмам иткән егетләр үз милләтләрен башкалардан яхшырак белә торган булып чыксалар, шулчакта мәдрәсәләребезгә «милли» исемен бирергә ярый.

Әмәвия, Габбасия, Госмания хәлифәләренең бер-берсенә охшашлы күпкатлаулы исемнәрен күңелдән өйрәнү өстенә, XIII (һиҗри) гасыр-

да исламның ничек яшәгәне, ничек көчәйгәне һәм ничек зәгыйфьләнгәне тәфсыйле җитәрлек дәлилләр [факт-лар] илә күрсәтелсә, мәдрәсәләребезгә «диния» сыйфатын тагарга килешер. Мәдрәсәләребез милләтебез тарихының башка милләтләр тарихлары янында урын алуына хезмәт итсәләр, динебез тарихын, башка милләтләрнең үз диннәре тарихын белүләре чамасында үз күзләре белән күреп белүенә васитә булсалар, менә шулчакта алар «милләт мәдрәсәсе, ислам мәдрәсәсе» була алырлар. Юкса мәдрәсәләргә, Гаяз әфәнде таккан «йөдәгәннәр йорты», «им-томсыз авырулар ятагы» исемнәре мәңгегә ябышып яшәячәк...

Вакыт. — 1908. — № 374. — 25 сентябрь

МӘДРӘСӘЛӘР ҺӘМ ГАРӘП ТЕЛЕ

Моннан элек язган ике мәкаләдә мәдрәсәләребездә әдәбият һәм тарих дәресләре укыту турында сүз кузгаткан идек. Бу мәкаләне иң күренекле урын тоткан гарәп теле дәресләренә багышлыйбыз. Дин исламның нигез китаплары гарәп телендә булганлыктан, дини мәдрәсәләребездә гарәп теленең әһәмияте мәңгелектер. Төркичә телебездә бик күп гарәп сүзләре бар. Ул гына да түгел, гарәп теле системасы да сизелерлек тәэсир күрсәткәнгә, үз әдәбиятыбызны яхшы төшенер өчен һәм төркичә иркен һәм хатасыз яза белер өчен дә, билгеле бер микъдарда гарәп телен белү сорала. Гарәпчәдән хәбәрдар булмаган мөгаллим хәзерге хәлдә, төркичә яхшы укыта алмаганы кебек, гарәпчә яхшы төшенмәгән шәкертнең имамлыкка һәм дин мөгаллимлегенә дә әзерлеге кимчелекле була. Гыйбадәт һәм догаларны, иман һәм ислам, әхлак турында булган кагыйдәләрне гарәп телендә йөртү бездә гадәткә кертелмәгәнлектән, аңлы мөселман булыр өчен дә гарәпчә белү сорала. Гыйбадәттә ни укыганыңны, Аллага мөнәҗәттә ниләр сөйләгәнлегеңне үзең төгәл аңламасаң, ул камил ышанулы һәм ихласлы дәрәҗәдә була алмый. Гыйбадәт һәм мөнәҗәт иң камил дәрәҗәдә булыр өчен, тел белән күңел арасында иң тыгыз бәйләнеш мөнәсәбәте булуы, телнең — калеб [күңел] сизгән нәрсәне генә сөйләве шарт. Гарәп теле бөтендөнья мөселманнары өчен уртак бер тел булганга, дини мәдрәсәләр өчен аның бу яктан да әһәмияте зур.

Мәдрәсәләребез өчен дин тарихы дәресе кирәклеге турында язган идек. Ислам дине, тарихын яхшы белер өчен, гарәп телен үз ана телең кебек төшенүдән башка чара юк.

Кагыйдәлелеге, нәфислеге, әдәбиятының колачлылыгы ягыннан, Көнчыгыш телләре арасында беренчелеге һәм дөньяның барлык телләре арасында тәфсилләп кагыйдәгә салынганлыгы ягыннан да, дини яктан, күз алдында тотылмаганда да, гарәп телен белүнең никадәр әһәмиятле нәрсә булганы аңлашыла. Шулай була торып та, иске мәдрәсәләребездә гарәп теленә тиешле игътибар каратылмады. 12-15 ел мәдрәсәдә ятучыларның уннан тугызы гарәпчә белмичә, ягъни белемсез чыгулары гаҗәп саналмый иде. Русиядә генә укып «мөтәләгасе чыккан» [белемле] зирәк кешеләргә

хәйран калалар иде. Ул замандагы укыту буенча гарәпчә аңлау дәрәҗәсенә ирешү гаҗәп калмаслык та түгел. Гарәп әдәбиятыннан бөтенләй хәбәрдар булмаган кешеләрдән генә укып, гарәпчә белүгә Сибуянең үзенең исе китәр иде. Мәдрәсәләребезнең бу кимчелеге телгә алына, язмаларда күренә башлагач та, голәмәләребезнең һәм шәкертләребезнең бу кимчелеккә җитди игътибар каратулары сәбәпле, мәдрәсәләребездәге ислахатьнең [яңаруның] шуннан башлануы бик табигый килеп чыкты. Гарәп телен аңлату өчен, төркичә китаплар языла башлау, гарәп теле мөгаллимнәре арасына гарәп әдәбиятыннан хәбәрдар кешеләр кушылу мәдрәсәләребездә гарәп телен укытуны шактый җанландырды. Дөрес, биредә, туңлыгыннан куптару, урыннан кузгатуда гарәпчә белмәүләрен ишетеп-аңлап гарьләнгән шәкертләрнең иҗтиһад күрсәтүләрен билгеләп үтү тиеш. Укыту ысулының берникадәр җиңеләюе — шул иҗтиһад җимеше. Соңгы 15-20 ел эчендә бик нык тырышып, укыту куәтенең яртысын шуңа сарыф итеп, гарәпчә укыту искедәге түбән баскычтан кузгалды. Әмма камиллеккә ирешүгә әле бик ерак. Бу уңышсызлыкта гарәп теленең барча башка телләргә караганда да читенрәк, кагыйдәләре искерәк, хәзерге кулланышыннан аермалырак булуларының да катнашы бар. Әмма төп сәбәпне укытучыларыбызда, китап [дәреслекләр] язучыларыбызда күрергә хаклыбыз. Чөнки хәзер дә әле гарәп теле мөгаллимнәре арасында гына түгел, укыту китаплары язучылар эчендә дә гарәп әдәбиятын төшенгән кешеләр, өйрәтү теле һәм аның китаплары ничек язылырга тиешлеген белгән кешеләр бик сирәк. Чын хәлне белмәгән кеше — ышанырлык түгел: «Карабаш»ны [иске тәҗвид китабы исеме] гына укып чыгарылган тәҗвид китаплары әле дә булганы кебек, «Будан» [фарсы телендәге борынгы гарәп теле грамматикасы] гына күргән язучылар тарафыннан язылган гарәп теле грамматикасы китаплары бар.

Моның өстенә шәкертләребезнең гарәп телен өйрәнергә керешкәннәрендә дә үз телләре кагыйдәләрен белмәүләре эшне кыенлаштыра. Чөнки ана теленең кагыйдәләрен яхшы белгән шәкерткә генә чит тел кагыйдәләрен аңлату ансат. Гарәп теле шикелле мең кагыйдәле телне начар дәрес китаплары буенча, үз телен белмәгән балаларга төшендерү мөгаллимнең картаюына мәдрәсә һавасыннан да яманрак тәэсир итәдер. Шуларны искә төшергәч, ихтыярсыз, таныргага мәҗбүр буласың: яңа ысулдагы мәдрәсәләребездә дә гарәп телен укыту яңартуга бик мохтаҗ һәм түзеп торырлык хәлдә түгелдер. Бер чакта гарәпчә белмәвебездән көлгән заман, инде гарәп телен өйрәнүне төзәтү белән артык та озак маташуыбыздан көлсә кирәк. Безнең тәртипле мәдрәсәләребездә дә гарәп теленә сарыф ителгән кадәр вакыт һәм мәшәкать белән күршеләребез 2-3 чит тел өйрәнәләр. Мәсәлән гимназия һәм реальныйларда рус балаларының французча-немецчә өйрәнер өчен сарыф иткән вакытлары безнең шәкертләрнең гарәп телен өйрәнүгә сарыф иткән хезмәтеннән җиңелрәк һәм кызыграк икәне шөбһәсез.

Билгеле булганча, яңа мәдрәсәләребездә гарәп телен өйрәнүне яңартканда, гарәп теле дәресләренең санын иске мәдрәсәләргә караганда 3-4 өлеш күбәйтергә тырышылды. Дәресләрнең кызыклыгын һәм рәвешен яхшырту урынына өйрәнү вакыты һәм дәресләр саны гына арттырылды. Гарәпчә укытуның күп мәшәкать һәм

күп вакыт соравына гына игътибар ителгәч, аны өйрәнергә теләүчеләр саны кимүенә гаҗәпләнергә туры килми. Гарәпчә өйрәнүнең аз матди файда китерүе дә искә алынырга тиеш. Мәшәкате башка телләргә караганда күбрәк. Дөньяда файдасы азрак булган телне савап өчен генә өйрәнүчеләрне табарга җиңел булмас. Гарәпчә бөтенләй белмәгән кешеләрнең дә савапка өметләре аз гына дә ким түгеллеге шәкертләргә дә яшерен түгел. Милләткә хезмәт итәр өчен, гарәпчә белмәгән кешеләргә дә бик күп эш бар. Замананың: «Кирәген кара!» — диюе һәм үзләштерү — уку вакытын кыскартырга мәҗбүр итүе тәэсирендә яшьләребезнең күңеле суынуы якынлыгын да онытмау зарур. Моннан соң ата-аналарның да балаларының гомере бик озак гарәп телен өйрәнеп узуыннан ризасызлануы, балаларына күбрәк файда китерә торган мәктәп эзли башлаулары бар. Мәсәлән, мөфти хәзрәт һәм казый хәзрәтләре, һәм милләтебезнең мәшһүр кешеләре үз балаларын мәдрәсәгә бирмәй, башка урыннарда укытуларыннан гыйбрәт алучылар күбәер. Французларның «Пападан да артык католик була алмассың», — дигән мәкальләрен үзгәртеп: «Мөфтидән артыграк мөселман була алмассың», — дия башларлар, мөселманлыкларын балаларын мәдрәсәгә бирүдән башка гына «җиренә җиткерергә» керешерләр. Мәдрәсәләребездә аз нәрсә өчен күп вакыт сарыф ителгәне яшьләр һәм картлар арасында фаш булып бетсә, аларга кем генә укырга килер? Гарәп телен аз вакытта файда китерерлек өйрәтүнең чарасы табылмаса, аны (госманлы мәктәпләрендәге кебек) милли мәктәп һәм мәдрәсәләребездән бөтенләй чыгарылу ихтималы күңелгә килә. Шуларны игътибарга алгач, мәдрәсәләрдә гарәп телен саклап калуның, гарәпчә укытыла торган мәдрәсәләребезгә заманның яман җилен кагылдырмас өчен, бер генә юл кала, ул да булса: мәдрәсәләрдә гарәп телен иң камил ысуллар белән укытып, бик тиз өйрәтү һәм гарәп телен өйрәтү өчен файдаланыла торган материалларның кызыклы һәм бай мәгълүматлы булуы. Бу максатка ирешер өчен, гарәп теле кагыйдәләрен өйрәтә торган дәреслекләрне һәм уку китапларын төптән яңарту, моннан да бигрәк, гарәп теле укытучыларының гарәпчә белемнәрен тиешле югарылыкка күтәрү сорала. Өйрәтелүе җиңеләйтелмәсә, гарәп теленең татарлар арасында да юкка чыгасы бәхәссез нәрсә. Замана үзгәрүеннән хәбәрдар булу, аның таләпләренә җавап бирә белү сорала. Гарәп телен белүне Коръәнне аңлауга васита [арадашчы] итү дә, бу телне саклауга ярдәм итәчәк. Ә бит әле һаман: «Гарәп телен шактый озак (4-5 ел) өйрәнмәстән торып, Коръән мәгънәсен аңлар өчен кулланырга ярамый», — дип тыялар.

Гарәпчә укытуның ысул рәвешләре турында язарга бу мәкаләдә урын калмады. Язылган кадәреннән дә төп максат аңлашылса кирәк. Ул гарәпчә укытырга сәләте бар мөгаллим һәм мөдәррисләребезнең бурычы — гарәпчә укытуны бик җиңел яңа ысулга кую. Дәрес материалларын кирәкмәгән нәрсәләрдән арчып, өйрәтү срогын мөмкин кадәр кыскарту дигән таләпкә кайтып кала. Гарәп телен өйрәнүгә татарлар арасында шуннан башка чара юк.

Вакыт. — 1908. — № 377. — 3 октябрь.

Кереш мәкаләне һәм текстны басмага филология фәннәре докторы ***Мәсгут Гайнетдин*** *әзерләде.*

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕ ИЯСЕ, ШАГЫЙРЬ

НУРИ АРСЛАНОВ

(19.09.1912 — 14.04.1991)

ШАГЫЙРЬГӘ

Булса синдә Әфләтунның акылы,
Садәлеге керсез сабыйның,
Дәрвишлеге Хуҗа Насретдинның,
Исәрлеге Мәшрәп сафиның,
Телгә оста булсаң Чичән кебек,
Уйга — йөгерек, дала атыдай,
Гаделлеккә Нәүширваннан гадел,
Юмартлыкка булсаң Хатом-Тай...
Анда да син камил түгел, шагыйрь!
Җитми әле Хәйям касәсе,
Һәрдәм тулы шатлык шәрабына!
Бар әле, бар күкрәп-яшьнәсе,
Салават күпере салып күңелләргә
Коясың бар хисләр ләйсәнен,
Кирәк сиңа Мәҗнүн мәхәббәте
Һәм илһамы гүзәл Ләйләнең!..

Син кәрванбаш нар дөягә охшаш —
Күпме йөкләр сиңа артыла!
Тик истә тот: иң мөкатдәс йөгең —
Тугрылыклы булу халкыңа.

*Татар халкының күренекле шагыйре Нури Арслановның кайбер сүз энҗеләрен журнал битләреннән чүпли аласыз.

2012 ЕЛ — ТАРИХИ-МӘДӘНИ ҺӘЙКӘЛЛӘРНЕ САКЛАУ ЕЛЫ

КРЕМЛЬ ДАМБАСЫ: ҮТКӘНЕ ҺӘМ БҮГЕНГЕСЕ

Фото А.Дубин коллекциясеннән

Инде берничә ай дәвамында Кремль транспорт дамбасында үзгәртеп кору эшләре бара. Башкалабызның Вахитов һәм Мәскәү районнарын тоташтырган әлеге дамбаның тарихи исемнәре — «Кизик» яки «Хижик дамбасы» (Кизическая, Хижицкая дамба), совет чорында — «Ленин дамбасы», ә 90 нчы елларда бирелгән рәсми иseме — «Кремль транспорт дамбасы». Әмма Казан халкы һәм башкалабыз кунаклары өчен «Ленин дамбасы» исеме һәрвакытта да үз һәм якын. Бу дамбаның шактый бай һәм кызыклы тарихын күпләр әле белмидер дә, мөгаен.

1687-1692 елларда Казансу елгасының уң як ярында Кизик монастыре ачыла, тора-бара монастырь тирәсендә халык саны артып, XVII гасырның азагы — XVIII йөз башында бу тирәдә бистә оешып китә. 1825 елда Кизик һәм Кәҗә бистәләре

рәсми рәвештә шәһәр эченә керә. Бу вакытта бистәләр белән шәһәрне Казансу аша басма күпер тоташтырып торган. Казансу елгасының киңлеге 20-50 метр, тирәнлеге 1,5-2 метр чамасы булган. Табигый ки, язгы ташулар вакытында елга тагын да киңәйгән. Казансудагы су күтәрелү турында тарихчы М.Г.Худяков: «Казан язгы ташу вакытларында, шәһәрне өч яктан да су әйләндереп алганда күркәм күренә... Шәһәр суда йөзеп барган әкияти утрауга охшый. Елның бу вакытындагы Казан каласының матурлыгы белән Мәскәү, Бакчасарай, Вильна, Сарайчык кебек Көнчыгыш Европаның бер генә шәһәре дә ярыша алмый», — дип яза. Су киткәннән соң, бу урында

Дамбаның 1914 елгы планы.
М.М.Перевощиков басмасы нигезендә

гүзәл болыннар, күлләр, елга кушылдыклары һәм сазлыклар хасил булган. Айлар буена сузылган язгы ташу һәм басма күпернең ел саен агып китүе, елга үзәнендә калган сазлыклы җир хәрәкәт өчен комачаулык тудырган. XIX гасыр азагында шәһәрдә сәүдә мөнәсәбәтләре һәм җитештерү сәнәгате үсү, Казансуның ике як ярында да халык саны арту дамбага һәм күпергә ихтыяҗны арттырган. 1891 елда ачлык булу сәбәпле, крестьяннар Казан каласына күпләп агылганнар. Ачларга ярдәм итү максатыннан, аларга җәмәгать эшләре оештырыла, шул исәптән дамбаны да гади крестьяннардан төзетәләр. Дәүләт бу дамба-күперне төзергә 43 мең сум акча бүлеп бирә, җитеп бетмәгән 10 мең сумны шәһәр идарәсе финанслый. Ә 1915 елда дамбаны киңәйтү эшен Беренче бөтендөнья сугышында әсир төшкән солдатлар (австралиялеләр һәм венгрлар) башкара. Совет чорында дамба Ленин исеме белән атала башлый. 1926 елда шактый куәтле булган язгы су ташулары дамбаның күп өлешен юып алып китә, ә күпер җимерелә.

Казансу аша басма күпер. А.Дюран рәсеме

Фото А.Дубин коллекциясеннән



Фото А.Дубин коллекциясеннән

Казансуда язгы ташу

XIX гасыр азагыннан сакланып калган иске дамбаның кисәкләрен хәзерге Декабристлар урамының сул ягыннан күрергә мөмкин. Аның да бер өлеше «Казметрострой» корылмалары астында калган.

Әмма тиз арада дамба төзекләндерелә. 1926 елның 1 сентябрендә аның аша башкалабызда беренче номерлы автобус йөри башлый. Узган гасырның 30 нчы елларында Казансуның уң як ярында яңа сәнәгать оешмалары барлыкка килү, халык

В.Зотов фотосы

Күпер ремонт вакытында

Л.Гобәйдуллин фотосы

Дамбада реконструкция эшләре бара

саны арту күпер һәм дамба аша хәрәкәтне арттыра. 1933 елда Ленин дамбасы буенча трамвай юллары сафка баса һәм 9 нчы номерлы маршрут ачыла. 1948 елда Ленин дамбасы аша шәһәрдә беренче троллейбус юлы ачыла. Троллейбус һәм трамвайлар шәһәр үзәгеннән авиазаводка кадәр пассажирлар йөрткән. 1957 елда Жигули ГЭС һәм Куйбышев сусаклагычы төзелү сәбәпле Казансу ярлары тагын да киңәю, сугыштан соң шәһәр үсеше, яңа кварталлар барлыкка килү агач күпер урынына яңа, заманча гидротехник корылма төзүне таләп иткән. Шулай итеп, 1955-1957 елларда Ленин дамбасындагы агач күпер тимер-бетон корылмалар белән алышына. Ә 2010 елның декабреннән дамбаның көньяк ярыннан 30 метрга кадәрге тирәнлектә Казан метрополитенының Үзәк линиясе эшли башлый.

Ленин дамбасы узган гасырның икенче яртысында төзекләндерү өчен кыска вакытлы срокка берничә тапкыр ябыла, җәяүлеләр өчен Казансу аша басма төзелү очрагы да була. Дамба Казан каласының меңьеллыгы алдыннан, 2000 елларда өлешчә реконструкцияләнә. Аның Казан шәһәренең Мәскәү районына илтә торган ягы өч юллы итеп эшләнә. 2010 елда трамвай линиясе бетерелә, шуның нәтиҗәсе буларак, транспорт юлларының саны арттырыла.

Елдан-ел башкалабыз үсештә булу, соңгы елларда яңа сәүдә үзәкләре, торак-йортлар сафка басу, 2013 елда булачак Универсиада янәдән заманча, киң дамба һәм күпер төзүне таләп итә. Шул сәбәпле 2012 елның июнь аеннан, Кремль дамбасын тулысынча заманча үзгәртеп кору максатыннан, транспорт агымы вакытлыча махсус төзелгән күпергә күчерелә.

Күрүебезчә, Кремль транспорт дамбасы — Казан каласының иң төп транспорт юлы. Күз алдыгызга китерегез: бер генә сәгать бу дамбада транспорт агымы тукталса да, шәһәр йөрәге тибүдән туктый. Күпер һәм дамбаның шәһәрдә икътисад, мәдәният үсеше, халык саны арту, яңа кварталлар барлыкка килү белән үзгәреше, яңаруы — бу заман таләбе.

Абдулла Дубин һәм Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

ӘДӘБИЯТ

Саф җанлы кеше дөньяны
Шигырьдә күрә икән...

Нури Арсланов

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

УЛ КАБЫЗГАН УТЛАР БАЛКЫШЫ

ТАТАР ДРАМАТУРГИЯСЕНӘ, МИЛЛИ ТЕАТР СӘНГАТЕНӘ НИГЕЗ САЛУЧЫЛАРНЫҢ БЕРСЕ, ӘСӘРЛӘРЕ, АКТЁРЛЫК ҺӘМ РЕЖИССЁРЛЫК ОСТАЛЫГЫ БЕЛӘН БҮГЕН ДӘ СҮЗ ҺӘМ СӘХНӘ СӘНГАТЕ ӨЛКӘСЕНДӘ ХАЛЫККА ХЕЗМӘТ ИТҮЧЕЛӘРГӘ ҮРНӘК БУЛГАН КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ ТУУЫНА 15 СЕНТЯБРЬДӘ 125 ЕЛ ТУЛДЫ. ШУЛ УҢАЙДАН БЕЗ БӨЕК КЛАССИК ӘДИБЕБЕЗНЕҢ ИСЕМЕН ЙӨРТКӘН ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫНЫҢ БАШ РЕЖИССЁРЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГАН СӘНГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ, РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕНЕҢ АТКАЗАНГАН АРТИСТЫ РӘШИД МУЛЛАГАЛИ УЛЫ ЗАҺИДУЛЛИНГА МӨРӘҖӘГАТЬ ИТТЕК.



– Рәшид әфәнде, татар халкының әйдәп баручы дәүләт театрларының берсе Кәрим Тинчурин исемен йөртә. Сез баш режиссёр булган әлеге сәнгать учагы әдипнең традицияләрен ни рәвешле дәвам итә?

— Беренчедән, без К.Тинчурин әсәрләре буенча спектакльләр куябыз. Соңгы 18 ел эчендә безнең театр сәхнәсендә К.Тинчурин пьесалары буенча 7 спектакль дөнья күрде. «Йосыф һәм Зөләйха» (безнең театрда «Хәйләсез дөнья файдасыз» исеме белән барды), «Назлы кияү», «Сүнгән йолдызлар», «Хикмәтле доклад», «Американ», «Сакла, шартламасын!» — болар мин сәхнәләштергән спектакльләр. Һәм «Җилкәнсезләр» әсәре чакырылган режиссёр Р.Галеев тарафыннан куелды. Бу спектакльләр безнең театр сәхнәсендә озак еллар дәвамында зур уңыш белән барды. Ә «Сакла, шартламасын!» бүген дә репертуардан төшми. Театрыбыз бинасында төзекләндерү эшләре башкарылу сәбәпле, уйнаудан вакытлыча туктатылып торган «Американ» әсәрен юбилейга һәм Кәрим Тинчурин исемендәге театр фестивале уңаеннан янәдән сәхнәгә кайтарабыз. Барлык декорация һәм костюмнар бөтен килеш саклана, минемчә, актёрлар уены һәм яңа табышлар нәтиҗәсендә Тинчурин драматургиясенең бөеклеге яңа төс алыр.

Икенчедән, бу — киләчәккә юнәлдерелгән перспектива, бөек драматург истәлеген мәңгеләштерү максатыннан, Кәрим Тинчуринга мәрмәр бюстлар кую теләге бар. Берсен — театр фойесында, икенчесен — драматургның исемен йөрткән урам янындагы паркта. Юбилей бәйрәм ителәсе көнне драматург бюсты торачак урынга тантаналы рәвештә таш куелыр дип көтелә. Республикабыз җитәкчелеге һәм бөтен иҗат берлекләре безгә әлеге эштә ярдәм итәрләр дип уйлыйм.

Һәм өченчесе... Үзем дә, режиссёр буларак, драматург Кәрим Тинчуринның исемен популярлаштыру юнәлешендә эшлим. Бу авторның әсәрләрен сәхнәләштерергә бөтен режиссёр коллегаларыма тәкъдим итәм, әмма монда бер бик зур киртә бар: аның пьесалары рус теленә тәрҗемә ителмәгән. К.Тинчуринның әсәрләре барган һәр театрның үз тәрҗемәләре (подстрочниклар) бар, тик алар бөтен әдәби кануннарга туры килеп бетми, димәк, боларны әдәби тәрҗемә дип булмый. Шунлыктан әлеге тәрҗемәләр автор фикерен һәм әдәби телнең кабатланмас үзенчәлеген тулысынча ачып бирә алмый.

Тәрҗемә эшендәге авырлыклар белән мин Анкарага спектакль куярга чакырылгач очраштым. Төрекләр ягыннан Төркия һәм Татарстан Республикалары мөнәсәбәтләре тарихында моңа кадәр күзәтелмәгән уникаль проект тәкъдим ителде. Драматургия һәм сәхнәгә кую — Татарстаннан, ә актёрлар һәм декорация белән костюмнарны Төркия үз өстенә алды. Төркия Республикасы Дәүләт театрларының генераль директоры Леми Бельгин әфәнденең мин сәхнәләштергән «Сүнгән йолдызлар» спектаклен

күргәне бар иде һәм ул мине Кәрим Тинчуринның нәкъ шул пьесасын куярга чакырды. Минем тарафтан Тинчуринның берничә пьесасы, нигездә, аның комедияләре, тәкъдим ителгән иде. Ләкин Леми бәй бик акыллы сүз әйтте: «Әлбәттә, комедияне сатарга җиңелрәк, әмма «Сүнгән йолдызлар» кебек драма йөрәктә озаграк саклана!» — диде. Минемчә, «Сүнгән йолдызлар» пьесасының һәм, тулаем алганда, Кәрим Тинчурин драматургиясенең уңышы нәкъ менә шунда.

Тәрҗемә итү авырлыкларына кайтып... «Сүнгән йолдызлар» әсәренең татар теленнән төрек теленә әдәби тәрҗемәсе белән югары профессиональ дәрәҗәдәге өч белгеч эш итте. Безнең яктан Казан федераль университеты доценты А.Гарифуллина һәм төрекләр ягыннан тагын ике профессиональ лингвист-тәрҗемәче. Мин моны ни өчен әйтәм, чөнки әдәби тәрҗемә — бик авыр эш, ул фәкать белгечләр эше. Киләчәктә Кәрим Тинчурин пьесалары рус теленә тәрҗемә ителсеннәр, хәтта рус телендә аерым китап булып дөнья күрсеннәр иде дигән бик зур хыялым бар. Бу драматург иҗатына иң зур һәйкәл булыр иде. Әлеге катлаулы эшне 125 еллыкка башкарып чыгып булмый инде, әмма Кәрим Тинчуринның 130 еллыгына бу хыял тормышка ашар дип ышанасы килә.

– К.Тинчуринның актёрлык, режиссура һәм драматургиягә бәйле карашлары бүген актуальме? Ни өчен?

— Кызганычка каршы, Кәрим Тинчурин актёрлык осталыгы буенча бернинди теоретик мәгълүмат калдырмаган. Ләкин бездә аның ниндидер бер спектакль репетициясе төшерелгән видеоязмасы саклана, әлеге кадрларда актёрларның режиссёр Тинчуринны нинди кызыксыну белән тыңлаулары күренә. Болардан мин аның репетицияләре үзләре үк кызыклы актёрлык осталыгы дәресләре булган, дигән нәтиҗә чыгара алам. Ә инде Тинчуринның драматургиясе өйрәнү һәм алга таба эшләр өчен бик кызыклы хәзинә. Шуңа күрә аның пьесаларына төрле буын татар режиссёрлары һәрдаим мөрәҗәгать итеп торалар. Әсәрләрне сәхнәгә куючыларның һәрберсе Тинчурин иҗатында ниндидер бер яңалык һәм үзе яшәгән заман белән тәңгәллек күрә. Классикларның әсәрләре, шул исәптән К.Тинчурин пьесалары һәрвакыт актуаль, чөнки алар вакыт сынавын үткәннәр. Бу авторлар мәңгелек турында язган, шуңа да алар заман кешесе өчен кызыклы.

– Киредән К.Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» әсәренә кайтыйк әле. Ул күп еллар дәвамында сәхнәдә зур уңыш белән барды. Моның сере нидә?

— Ике бер-берсен өзелеп сөйгән, әмма кавышырга насыйп булмаган йөрәкләр тарихы һәрвакыт кызыклы. Дөнья әдәбиятында моның үрнәкләре күп: Ромео һәм Джульетта, Тристан һәм Изольда, Фәрхад-Ширин һ.б. Татар классикасында Исмәгыйль белән Сәрвәрнең бәхетсез мәхәббәте тарихы һәм шулай ук кызганыч образ Мәхдүм сурәтләнә. Авторның кызыклы сюжеты, ихлас мәхәббәт һәм Салих Сәйдәшев иҗат иткән матур музыка... Минемчә, Кәрим Тинчуринның әлеге пьесасының уңыш сере нәкъ менә шунда яшеренгән.

– Төркия тамашачысы «Сүнгән йолдызлар»ны ничек кабул итте? Бай тарихы булган төрек театр дөньясында К.Тинчуринның фикерен халыкка җиткерә алырлык актёрлар бармы?

— Спектакльнең премьерасы 2011 елның 12 апрелендә Анкараның Дәүләт театры сәхнәсендә үтте. Төрек артистлары белән эшләүдән мин бик канәгать калдым. Алар үз эшләренең профес-

сионаллары диясем килә. Шуны да әйтергә кирәк: сайлау мөмкинлеге зур иде. Репетицияләр башланганчы, Анкараның дәүләт театрларыннан килгән 300 артист арасында кастинг үткәрдем. Андагы театрларда көчле контракт системасы булганлыктан, эшкә караш башкачарак, шунлыктан иҗади көндәшлек тә зур. Төп рольләргә яхшылардан-яхшылар сайланып алынды. Миңа бигрәк тә Сәрвәр (Дениз Уелмаз) һәм Мәхдүм (Җан-Али Чалышандемир) рольләрен башкаручылар белән эшләү ошады. Күмәк сәхнәләргә өстәмә парлар кертергә туры килде, чөнки хәтта «массовка»га да артистлар сайлау мөмкинлеге зур иде. Спектакль инде икенче елын зур уңыш белән бара. Быел алар Төркиянең Кара диңгез буенда урнашкан шәһәрләренә сәяхәт кылдылар. Бөтен җирдә спектакль зур популярлык казана. Мин төрек дусларым белән интернет аша аралашып торам, спектакль турындагы соңгы мәгълүматларны да алардан беләм.

– Совет чорында күп драматурглар пьесаларын заказга яза. Шул исәптән Кәрим Тинчурин да. Арада куелмыйча калганнары, «зарарлы» дип табылганнары байтак була. Хөкүмәтнең әсәрләргә идеологик «дөрес юнәлеш» бирүе К.Тинчуринның каләмендә сизеләме?

— Бу сорауга җавап бирер алдыннан, үз тәҗрибәмнән бер мисал китерәсем килә. Мәскәүдә мин режиссёрлык дипломын Кәрим Тинчуринның «Хәйләсез дөнья файдасыз» («Йосыф һәм Зөләйха») пьесасы буенча куелган спектакль белән «бишле»гә якладым (1993). Спектакльне карап бетергәннән соң, В.Щукин исемендәге театр институтының имтихан кабул итүче бөтен профессорлары миңа бары тик бер сорау бирделәр: «Авторны кайчан атып үтерделәр?» Алар Кәрим Тинчуринның әлеге әсәрен Николай Эрдманның «Самоубийца» пьесасы белән чагыштырдылар һәм үзләре өчен бөтен эчке дөньясы белән Советка каршы булган яңа сәләтле драматург ачтылар.

Кәрим Тинчурин дәүләт цензурасының барлык идеологик капкыннарын читтән урап үтә алган. Бу максатны тормышка ашыру өчен, ул кайвакыт пьеса-спектакль жанрының буяулары күләгәсенә яшеренгән. Мәсәлән, «Җилкәнсезләр» әсәрен автор комедия дип атаган, чынлыкта исә пьеса — татар халкының инкыйлаб вакытында бәргәләнүе, башыннан кичкәннәре турындагы драма. Ә «Американ» белән «Сакла, шартламасын!» хөкем сөргән стройга кискен сатира рәвешендә язылган. Әлбәттә, аның «Кандыр буе», «Ил» әсәрләре кебек социаль заказ буенча язылган пьесалары да бар, ләкин без аны хөкем итә алмыйбыз. Чөнки без ул заманда яшәмәгән, тоталитар строй шартларында исән калу юлларын эзләү газаплары безгә таныш түгел.

– Алга таба К.Тинчуринның тагын кайсы әсәрен репертуарга кертергә ниятлисез?

— Хәзерге вакытта безнең репертуарда «Сакла, шартламасын!» спектакле бара. Махсус фестиваль өчен «Американ» спектакле яңартыла. Киләчәктә аның «Җилкәнсезләр» һәм «Зәңгәр шәл» кебек пьесаларын кую теләге бар.

– Сезгә әлеге зур эшегездә уңышлар телибез. Кызыклы һәм эчтәлекле әңгәмәгез өчен рәхмәт!

Әңгәмәдәш — Рамил Ханнанов

НӘСЕЛ ИСЕМЕ

РАБИТ БАТУЛЛА,
Татарстанның халык язучысы

Борынгы татар телендә «чура» сүзе «кол» мәгънәсендә кулланылган. Ләкин колларны, ягъни чураларны азат иткәннән соң да, алар баеп китсәләр дә, исемнәренә «чура» сүзе тагылган. Тора-бара «чура» кәлимәсе «зыялы» дигән мәгънәне алган. Әйтик, татарның мәгълүм зыялыларының Чура Батыр, атаклы байларының исемнәре Акчура, Байчура, Колчура, Бикчура, Карачура, Янчура, Тынчура булуы табигый. Шулай итеп, атаклы драматург, әдип, режиссёр, актёрыбызның нәсел исеме дә шулай ясалганы көн кебек ачык. Тын чура, сабыр, түзем кол — Тынчурин, Тенчурин. Иске документларда Мөхәммәт Кәрим Тенчурин, Заһидә Тенчурина дип язылган. Гарәптән — латинга, латиннан кириллга күчкәндә, ул «Тинчурин»га әверелеп кала.

Чыннан да, Али (гарәпчә язылышында «Гали») Тинчурин көр тормышлы нәселдән. Аның балконлы, чарлаклы ике катлы таш йорты, яхшы каралты-курасы, мал-туары ишле була. Кыскасы, Тинчуриннар түнтәрелешкә чаклы татар авылының тоткасы, совет заманасында әйтелгәнчә, авылның кулагы була. Кулак исеме тагылса да, Али башка кулаклар кебек ялчылар тотмый. Каралты-курада, имана җирендә бу гаилә үз көче белән мал таба. Ир-атлар, кызлар — барысы да эшчән, барысы да җир кешесе, туфрак хуҗасы.

Көр Алинең күзе күрше Шылдавыч авылы мулласы Енакаевның кызына төшә. Ләкин гүзәл, укымышлы Мәхмүдәнең күңеле төшкән башка егете була. Бөреләнә башлаган бу яшерен мәхәббәт шулай сер килеш кала. Мулла абзый чибәрләрнең чибәре, укымышлы кызын күрше авылның

Тынчура нәселле Алигә бирә. Патшабикәләргә тиң горур кыяфәтле Мәхмүдәнең авыл мужигы Тынчура Алиенә чыгуы күзәтүчән бәгъзеләрне аптыраштa калдыра. Ләкин йола шулай куша, ата сүзеннән чыкты юк.

Ни өчен соң мулла абзый сөекле кызын авыл мужигына никахлый, дигән сорауга әле бүген дә төгәл җавап табылмаган. Мәрхүм Кәрим Тинчуринның тол хатыны Заһидә ханымның әйтүенә караганда: мулла абзыйның Али нәселенә олы бурычы булган икән дә, Мәхмүдәне никахлау бәрабәренә шул бурычны Тынчуралар Енакаевларга кичергән, имеш. Бәлки шул сәбәпле Али белән Мәхмүдәнең арасында мәхәббәт яралмый, ярашып яшәү була алмый да. Бары тик язмышка буйсынып, түзеп яшәү генә кала. Олы мәхәббәт Мөхәммәткәримгә төшә. Мәхмүдә алты баласы арасыннан Мөхәммәткәримне аеруча нык яраткан.

— Мәхмүдә ананың баласы Кәримгә булган мәхәббәте турында китаплар язарга, поэмалар иҗат итәргә кирәк! — ди торган иде Заһидә ханым Тинчурина.

Театр тирәсендәгеләр ярым шаяру, ярым җитди рәвештә Заһидәне үртиләр, Кәрим белән ике араны бозарга тырышалар.

— Заһидә ханым, Кәрим бит анасын синнән күбрәк ярата! — диләр. Заһидә югалып калмый, ул чәтләтеп:

— Кәрим ул анасын ана буларак ярата, мине хатыны буларак сөя! Ә мин каенанамны үз анамнан да ныграк сөям! — дип тегеләрнең авызын каплый.

Дөрестән дә, Заһидә ханым әйтә торган иде мәрхүмә:

— Мин үз анамнан наз күрмәдем, мин аның өчен артыкбикә идем, үз анамнан күрмәгән назны мин Кәримнең анасы, каенанам Мәхмүдәдән күрдем. Урыны җәннәттә булсын!

Бәхетле зат булыр өчен, дүрт нәрсә кирәк: ана мәхәббәте, сөекле хатыныңның мәхәббәте, халкыңның мәхәббәте, балаңның мәхәббәте.

Кәримнең анасына, ананың баласына булган бөек мәхәббәте турында Заһидә ханым сәгатьләр, көннәр буе сөйли торган иде.

Али белән Мәхмүдәнең арасы һәрвакыт киеренке була. Гауга куптарып талашмасалар да, ир кеше кырыс, хатын кеше сабыр, түзем. Ләкин Мәхмүдә бер-бер артлы уллар таба, кызлар алып кайта, аларның барысы да куәтле, эшкә батыр булып, ата кеше Али кулы астына керә башлый. Имана җире артканнан-арта бара. Ләкин Мөхәммәткәрим генә җиргә түгел, китапка, белемгә тартыла. Али бай улының белемгә тартылуына каршы булып, Мөхәммәткәрим киләчәктә җир кешесе, ярдәмче булыр дип өметләнә.

Заһидә ханым белән Кәрим Тинчурин арасындагы саф яратышу да — дастаннарга тиң хисләр.

Кәрим белән Заһидә ярашкан гаилә коралар. Алар 18 ел бәхеткә чумып яшәп калалар.

Тинчуринның (бер гаепсезгә) ике тапкыр театрдан куылган чакларында да, нахак яла ягып, төрмәгә алып киткән вакытта да, еллар буе хәбәрсез югалган чакларда да, иренең атып үтерелгәне турында ишеткәч тә, Заһидә ханым иренә хәерхаһ булып калды, сугыш вакытында халык дошманының хатыны буларак, Казаннан сөрелгәндә дә, үз йортыннан куылып, фатирдан фатирга, почмактан почмакка ташынып йөргәндә дә, ашарга ипие, эчәргә чәе булмаган заманнарда да Заһидә ханым иренең әйберләрен сатмады, кулъязмаларын күз карасыдай яшереп саклады, күпме димләсәләр дә, башкага кияүгә чыкмады, Тинчурин фамилиясен горур йөртте. Бу Заһидә ханымның Тин-

чуринга булган самими хисләре, олы мәхәббәтенең дәлиле булып тора.

Сабыйларны яратучы, үзе дә сабый күңелле Кәримгә, кызганыч ки, бала атасы булу насыйп булмаган икән шул. 1921 елда ачлык вакытында Заһидә ханым, урамда егылып, үле бала таба һәм ана булу насыйбыннан мәхрүм кала.

Әмма тәкъдире фаҗигале булса да, Кәрим Тинчуринның тагын бер олы бәхете, олы мәхәббәте бар, ул — халык мәхәббәте һәм ул мәңгелек. Аның китапларын укучылар мәхәббәте, спектакльләрен, пьесаларын яратып карый торган тамашачылар мәхәббәте. Бәхетле иҗат. Могҗизалы иҗат. Ул хикәяләр яза, «Мәрҗәннәр» кыйссасының беренче өлешен язып ташлый, калганын язып өлгерә алмый, аны 1937 елда кулга алалар, 1938 елда атып та үтерәләр. Урыны җәннәттә булсын!

Актёр буларак, К.Тинчурин һәрвакыт баш рольләрне башкара. Армый-талмый иҗат итә, шаяра, көлә, мәҗлесләрнең уртасында кайный, һәр


Форма № 5

Отдел записей актов гражданского состояния № 45

при г. Казани 1924 год.

ВЫПИСЬ О БРАКЕ

1.	№ записи	239	
2.	Число и месяц заключения брака	12 мая 1924 г.	
		с женихе	о невесте
3.	Фамилия и имя	Тенчурин Карим	Ахмерова Загида
4.	Возраст (число, месяц и год рождения)	36 л.	27 л.
5.	Постоянное местожительство (указать подробный адрес)	Петропавловская ул. дом № 13-14 кв. 1	
6.	Род занятий	артисты	
		Холост, вдов, разведен	Девица, вдова, разведена
7.	Семейное положение	холост	девица
8.	В который по счету брак вступает	в первой	

язган пьесасы, һәр куйган спектакле зур уңыш казана. Әлбәттә, артык гайрәтле шәхеснең көндәшләре дә, дошманнары да күп була. Гадәттә, бер-беренә тиң кешеләр көндәш була. Ләкин үзе дә талантлы кеше башкаларга яла якмый, сәләтләре чамалы булганнар, үзләре булдыра алмаганнар талантны күрә алмыйлар. Тинчурин театр эчендәге шикаятьчеләрнең барысын да белә, ләкин беркайчан да алардан үч алу, аларны кысрыклау юлына басмый. Тинчурин театр өчен алыштыргысыз талант иясе була. Аны театрдан чыгаргач, театрның сукасы ташка терәлә, эш бармый, Тинчурин пьесалары репертуардан алына, яңа пьесалар юк, булганы да бик зәгыйфь каләм белән язылган, режиссура юк, театрга халык йөрми, Тинчуринны янә театрга чакыртып кайтарырга мәҗбүр булалар.

Тинчурин аклангач, театрдагы шикаять, нахак яла ягучыларның исемнәре Заһидә ханымга мәгълүм була, ләкин киң күңелле, олы җанлы Заһидә ханым ирен харап итүдә катнашканнарның берсенә дә үпкә сүзе әйтми, үч алмый.

— Аларны вөҗданнар хөкем итсен, алар Аллаһ каршында җавап бирсен! — дип кабатлый иде мәрхүмә.

Нәкъ Коръәндә язылганча:

— Җәза бирсәгез, үзегезгә бирелгән җәза микъдарында гына җәзалагыз. Ләкин (үч алмыйча) сабыр итсәгез, һичшиксез, сезнең файдага булыр (16, Нәхел, 126).

Кәрим гайбәтләр, нахак ялалар алдында каушап кала, ул янындагы кешеләрне (астыртын чагучыларны) аңламый, пошаманга төшә. Аның актёр, режиссёр, драматург буларак театрны бер кулда тотуы астыртыннарга ошамый, шулар өстенә Тинчуринның статский советник Шаһбазгәрәй кызына (дворянкага) өйләнүен дә гаепкә саныйлар. Тинчуринның иң яхшы пьесалары Заһидә Әхмәровага өйләнгәч язылган, бу — чынбарлык. Димәк, Заһидә ханым ире Тинчуринга илһам өстәүче, аның пьесаларын беренче булып укучы, киңәш-табыш итүче, Тинчуринга иҗат терәге булып тора.

Тинчурин көне буе театрда, репетицияләрдә, театр мәшәкатьләре белән мәшгуль. Пьесаларын ул төнлә яза. Төне буе пьеса язып тәмамлагач та, Заһидә ханымны уятып, пьесаны иң беренче аңа укый. Әдәбият-сәнгать белгече буларак, Заһидә ханым иренә киңәшләр бирә, ире язган әсәрләрнең миһербанлы тәнкыйтьчесенә әверелә. Шулай итеп, татар драматургиясенең «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр» кебек шаһәсәрләре барлыкка килә. Аның «Зәңгәр шәл» пьесасы инде күптән Гиннеслар китабына кертелергә тиеш, ул пьесаны куймаган татар театры юк, ул пьеса әле һаман, бер гасырдан артык репертуардан төшми уйнала килә.

Тинчурин могҗизасы барлыкка килә. Каян килә соң ул могҗиза? Күпкырлы талант, миһербан иясе нинди шартларда формалаша.

Шартлар төрле: Тинчуринның февраль инкыйлабы алдыннан дөньяга килүе. Аның буыны революцион идеяләрне аңга сеңдерә баруы, ул буын 1905 елгы инкыйлаб тәэсирендә җитешкән буын булу һ.б. 1917 елда инде Тинчурин — өлгергән шәхес, үз зиһене белән үз юлын сайлаган зат. Тинчурин миһербан иясе, сәнгать кешесе өчен миһербанлы булу — иң беренче шарт. Аның шәхесендә ике бөек мәдәният килеп очрашкан: Шәрык белән Европа мәдәнияте. Беренче мәдәниятен ул төрки телләр, гарәп культурасы аша алган булса, Европа мәдәниятен ул рус теле, рус культурасы аша сеңдергән. Муллалыкка укый башлап та, укыту шартлары белән килешә алмый мәдрәсәне ташлап чыккан Тинчурин турыдан-туры заманави сәнгатькә кереп чума. 1917 елда инде шөһрәт казанган атаклы драматургның утыз яшьлек бәйрәме олылап уздырыла. 1926 елда 25 еллык иҗат хезмәте өчен аңа шәрәфле «ТАССРның атказанган артисты» исеме бирелә.

Икенче көнне «Красная Татария» газетасында бәйрәмдарның ачык хаты басылып чыга.

«Уважаемый товарищ редактор! Разрешите мне, в связи с 25-летием моей работы, отмеченным 28 мая, выразить через вашу газету большую благодарность и искреннюю признательность. Я горячо благодарю областной комитет партии и правительство нашей орденоносной Татарской республики за болъшую честь, за теплоту и заботливость, оказанные мне в моей небольшой и скромной работе на поприще советской татарской литературы и театра.

...Я верю, что моя любовь к нашей дорогой социалистической Родине даст мне и в далънейшем еще болъше сил, еще больше страсти в борьбе за наше социалистическое строителъство. К.Тенчурин».

Ул чорда Русиядә имәнгеч (абсурд) хәлләр бик еш булып тора. Имәнгеч тәкъдир Тинчуринны да сагалап тора. Аны хөкүмәт бүләкләре тулы өеннән, кочак-кочак чәчәкләр эченнән төрмәгә алып чыгып китәләр. Тәхеттән — ләхеткә!

Зинданда Тинчуринны изеп кыйныйлар, һәр допростан соң аның канлы гәүдәсен аңын җуйган килеш камерага өстерәп алып кертеп ташлыйлар.

Бер камерада утырган язучы Мирсәй Әмир хатирәсе:

— Ул нык рухлы кеше иде. Аңына килгән вакытларда ул безне юата иде: түзегез, дусларым, түзегез, бу мәхшәр барыбер бетәчәк, бу аңлашылмаучанлык кына, хакыйкать кайтачак, — ди торган иде.

Тинчуринның 1923 елда язылган «Сүнгән йолдызлар» исемле пьесасында каһарманнарның берсе төш күргәнен сөйли: аждаһа бөтен яхшы кешеләрне, миһербан ияләрен йотты, күктәге йолдызлар кинәт сүнде, ди. Бу аллегория әүлиялык кебек яңгырый. Коточкыч аждаһаның куркыныч шәүләсе 1937 елда күренер, һәм ул Тинчуринның йолдызын да йотар.

Тинчуринның алдан күрүчәнлеге көчле була. 1928 елда ул «Хикмәтле доклад» пьесасын яза. Сталинның тәхеттә ныгып килгән чагы. Буш куыклык, бюрократиянең, дөреслеккә охшаш ялганның чәчәк ата башлаган чоры. Аяк киеме әртиленең башлыгы Мортазаның купшы сүзләр белән ялган аша тәхеткә үрмәләве турындагы пьеса язып куйдыруы — Тинчуринның гражданлык каһарманлыгы. Шул пьесаны тентүчеләрдән яшерепсаклап калу — Заһидә ханымның

каһарманлыгы.

Вафаты алдыннан (1988) Заһидә ханым әйтте:

— Мин озак тормам, Батулла, — диде. — Каберемә таш куйдырырга акча калдырам. Шул ташта өч исем булырга тиеш. Атам Шаһбазгәрәй Әхмәров. Кәримнең үз гүре юк, шуңа күрә минем кабер ташыма аның исемен дә яздырырсың. Минем гүрем Кәримнең гүре булыр. Чәчәкләрегезне шунда китерерсез.

Татар зираты капкасыннан кергәч тә, сул якта, Фатыйма Ильская каберенә каршы якта ташына: «Кәрим Тинчуринның хатыны, укытучы, «Сәйяр» артисткасы, Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы Заһидә Тинчурина» дип язылган.

Кабер ташы янында уйланып торам. Такташ 16 яшендә үзенең олы шагыйрь икәнен исбат итә алган. Утыз яшендә һәлак булган. Җәлил 13 яшендә үзенең өлгергән шигырен язган. Утыз сигез яшендә һәлак булган. Тинчурин 19 яшендә драматург буларак танылган. Илле яшендә һәлак булган.

Без хәзер җитмешнең өстендә. Без әле кырык яшьтә дә яшь язучылар хисабында йөрдек.

Безнең шулай соң өлгерүебезнең сәбәбе нидә? Әлбәттә, ялкаулык та бардыр. Мәктәп тәрбиясендә дөрес юнәлеш бирмәүләре дә бардыр. Миңа калса, сәбәп тирәндәрәк. Өлгергәнлек аттестаты алсак та без пешмәгән, өлгермәгән булганбыз, чөнки без Ахматова, Цветаева, Зощенко, Булгаков, Платонов, Бунин, Набоков кебек атаклы шәхесләрнең иҗаты турында мәгълүматсыз яшәгәнбез. Безгә егерме-егерме биш яшьләр иде, без Рәмиев, Дәрдмәнд, Ибраһимов, Галәүләр, Туфаннар, Тинчуриннар турында ишетеп тә белми идек. Әдәби авитаминоз, «кара тишек», вакуум-бушлык иде безнең милләрдә. Ул бушлыкны тутырыр өчен еллар, дистәләрчә еллар кирәк.

Татар кешесе гомер-гомергә Йосыф белән Зөләйха, Таһир белән Зөһрә, Фәрһад һәм Ширин, Ләйлә белән Мәҗнүн турындагы шигъри кыйссаларны укып, аларның фаҗигале мәхәббәтләре өчен җан атып яшәгән. Татар әдәбиятын шушы исемнәрдән башка күзаллавы да кыен. Мәхәббәт турында сүз чыкса, без хәзер дә шушы изге исемнәрне телгә алабыз, үрнәк итәбез, гыйбрәти мисал буларак күрсәтәбез. Алардан соң Хәлил белән Галиябану, Миркәй белән Айсылуларның фаҗигале тәкъдирләре килә. Күңелләрне нәрсәсе белән шулай тарта соң бу язмышлар?

Мәхәббәткә тугрылык, саф хисләр, өзелеп сөю һәм изге тойгылар өчен үзеңне корбан итү кебек каһарманлык магниттай тарта, сихерле. Бу исемнәр, гүзәл хисләр үрнәге булып, халкыбызның күңелендә, милләтебез аңында мәңге яшәячәк. Шөкер, әдәбиятыбыз шундый кыйссаларга бай.

Ә тормышта, мәшәкать, золым баскан заманнарда шундый илаһи хисләр, шушындый мәхәббәт була аламы соң? Әйе, була!

Мин андый кешеләрне беләм, авылдашларым арасыннан да үрнәкләр китерә алам. Һөнәрдәшләрем арасында да бар шундый самими, саф хисләр белән янып, кушылып, аерылгысыз гомер кичергән парлар, һәм аз түгел, шөкер. Ләкин мин шундыйларның фаҗигалесе турында сөйләмәк булам.

Алар — Кәрим белән Заһидә! Мәшһүр драматург, атаклы «Мәрҗәннәр» кыйссасының авторы, актёр, режиссёр Кәрим Тинчурин белән артистка, мөгаллимә Заһидә ханым Тинчурина-Әхмәрова язмышы Йосыф кыйссаларыннан, Таһир-Зөһрәләрнекеннән һич тә ким түгел.

Кара язмыш аларны гомергә аера. Һич гаепсез Кәримне кулга алалар. НКВД кешеләре Тинчуринның

кыйммәтле әйберләрен, кулъязмаларын, китапларын төяп алып чыгып китә, шул китүдән ул байлык кире кайтмый, КГБ подвалларында да табылмый, байлыкны коммунист кыгыбычылар үзләштергән булып чыга. Аяусыз кыйнап, Кәримнән мәгънәсез сорау алалар:

— Халык дошманы, контр, кабахәт Гаяз Исхакыйның энесе Хәсән Исхакый — япун шпионы! Син, Тинчурин, шул шпион аша япуннарга безнең илне сатып яткан кеше! Син дә шпион! Шпионлык эшләрегез турында сөйләгез!

Кәрим бу уйдырмаларны үз өстенә алмый. Тагын кыйнау башлана. Кыйный торгач, аны имгәтеп бетерәләр һәм шомлы төннәрнең берсендә 1938 елның 14 октябрендә атып үтерәләр. Каберенең кайда икәнлеге дә төгәл билгеле түгел. Заһидә иренең утыз сигезенче елда ук атылганын белми, һаман Кәримне көтә. Төрмәдән төрмәгә йөреп, эзсез югалган ирен эзли. Үзен дә утырту куркынычы була торып, ул төрмә нәчәлникләренең бусагасын таптый, шулай каңгырып йөри торгач, аңа әйтәләр:

— Ирегез кайтмаслык җиргә, еракка сөрелде, — диләр. Нәселдән-нәселгә килгән үзенең кыйммәтле әйберләрен сатып, Заһидә, ире Кәримгә атап, төрмәгә акча китерә тора, ләкин ул акчалар Кәримгә барып җитми, төрмәчеләр кесәсендә оялап кала. Заһидә, халык дошманының хатыны буларак, үз өеннән куыла, аны берике төенчеге, Кәрим Тинчуринның НКВДдан яшереп-качырып калган кулъязмалары белән урамга чыгарып ташлыйлар. Яраткан эше — укытучылыктан да сөрәләр. Фатирдан фатирга күченүләр башлана. Урнашып җиттем дигәндә генә аның «халык дошманы хатыны» икәнен белеп алалар да хуҗалары тагын куып чыгаралар. Шулай итеп, бичара Заһидә торыр урын-

сыз, ач-ялангач кала. Ләкин күпме генә ачыкса да, ул иренең әйберләрен базарга чыгарып сатмый, кулъязмаларын ышанычлы урынга яшерә дә үз әйберләрен сатып көн итә башлый. Сугыш башлангач, Заһидәне «ышанычсыз элемент» дип Казаннан да, Татарстаннан да куалар. Өйдән өйгә, ерак юлларда йөргәндә, Кәрим Тинчурин үз куллары белән сатып алган кадерле әйберләр югала, ватыла, шулай да Кәримгә Кариев бүләк иткән алтын сәгать, көмеш стакан оясы һәм көмеш балкашыгын Заһидә саклап кала. Сугыш беткәч, ниһаять, Заһидәне Казанга кайтаралар. Кеше аралыкларында йоклап, шәхси дәресләр биреп, наданрак коммунист балаларын институтларга әзерләп, ул көн күрә башлый. Эш белән фаҗигане онытырга тырышып, ул ирен, Кәримен сабыр гына көтә. Көннәрдән бер көнне Заһидәне НКВДга чакыртып алалар.

—Тинчурин фамилиясеннән ваз кич! Кияүгә чык! Киявең фамилиясенә күч! Шулай итсәң, сиңа бәйләнүче булмас. Эш тә табарбыз, торыр урының да булыр, рәхәт яшәрсең! — диләр.

— Нишләп мин кияүгә чыгыйм? Нишләп мин иремнең фамилиясеннән ваз кичим? Мин иремне көтәм! — ди Заһидә һәм йортсыз, эшсез тормышын дәвам итә.

Яшерен-батырын түгел, бәгъзе мәшһүрләребезнең хатыннары ирләренә афәт килгәч, хаиннәрчә качтылар, ирләре өстеннән әләкләр яздылар, «җинаятьче» иренең фамилиясен югалтыр өчен, башка иргә чыктылар, ирләре аклангач, акча даулап йөрделәр.

Юк! Заһидә ханым кияү эзләп китмәде. Тинчурин исемен дә ташламады, пычратмады, Тинчурин фамилиясен Заһидә ханым аеруча горурлык белән йөртә иде. Кыен чакларда да ул:

— Мин действительный статский советник Шаһбазгәрәй Әхмәров кызы Заһидә Тинчурина буламын! — дип горур кала белде.

— Мин гомерем буе Кәримне көттем, — ди торган иде мәрхүмә. — Аның төсен онытмас өчен, Кәрим кулы тигән әйберләрне сакларга тырыштым.

Ниһаять, Кәрим кулга алынганнан соң ун ел узгач кына, Пләтән төрмәсе нәчәлниге Локман Ногманов, Заһидә ханымны күргәч:

— Нигә сез кияүгә чыкмыйсыз? Нигә үз тормышыгызны рәтләмисез? — дип сорый.

— Мин иремне көтәм! — ди Заһидә.

— Юкка көтәсез, — ди Локман Ногманов. — Аны утыз сигезенче елда ук аттылар. Бер төндә ике йөз кешене судсыз-нисез атарга дип кәгазь килде. Шул ике йөз кеше арасында Тинчурин да бар иде.

Кулга алынганнан соң, егерме еллап вакыт узгач кына Кәримне аклыйлар. Тинчуринның исеме шаулый, аның пьесалары сәхнә түрендә, Күчмә театрга Кәрим Тинчурин исеме бирелә. Аның Заһидәсе саклап калган кыйссасы «Мәрҗәннәр» кат-кат басылып чыга. Дөнья шаулый, халык Тинчурин исемен теленнән төшерми, Тинчуринга шик белән караганнар да, аның өстеннән язганнар да Заһидә ханымны котларга йөгерә. Заһидә Тинчурина үзе генә сикереп шатланмый. Нинди шатлык бу? Заһидә иренең даһи икәнен, гаепсез икәнен һәм барыбер акланачагын белеп яшәде ич. Бу сукырларның күзе ачылгангамы ул сөенсен, аларның күңел күзе сукыр булганга, шул сукырлык пәрдәсе бүген генә ертылгангамы ул куансын?

Бик сабыр, мәгърур кабул итте Заһидә ханым иренең аклану вакыйгасын. Таныш хатыннары тагын аптыраашта:

— Таш бәгырьле бит ул Заһидә ханым, ирен кулга алгач та еламады ул. Эштән куылса да, йортсыз калса да,

театрга, концертларга йөрде. Әнә күр, бөтен дөнья шаулый Тинчурин турында, ул берни булмагандай тыныч, — дип пышылдаучылар аз булмады.

Кәрим аклангач та әле Заһидә Тинчурина һаман кеше өстендә яшәргә мәҗбүр була. Совет хөкүмәте аның үз йортын кайтармый. 1968 елда гына, җитмеш бер яшендә генә Совет власте аңа бер бүлмә бирә. Шул бүлмәгә ире Кәримнән калган әйберләрне куеп, ул үзенә күрә кечкенә генә музей ясый. Кәрим чәй эчәргә ярата торган тустаганнар, балкашык, Кәримнең берике сәгате һәм НКВДдан яшереп, качырып калган берничә кулъязма, фоторәсемнәр, вәссәлам! Заһидә ханым ире турындагы хатирәләр белән юанып тормыш итте. Кәримнең кулы тигән шушы әйберләр арасында ул туксан бер яшенә чаклы яшәде. Җан биргәндә, аның телендә өч кенә исем булды: Аллаһ, атасы Шаһбазгәрәй һәм Кәрим Тинчурин.

Аның беркеме дә юк иде. Булган туганнары белән мөнәсәбәте бик тәкиеренке иде, чөнки алар иң кыен вакытларда Заһидә ханымга зыян салган, аны үз йортыннан куган кешеләр, иң авыры — алар Кәрим Тинчуринны «халык дошманы», дип атаган кешеләр. Заһидә ханым аларның барысын да гафу да иткән булыр иде, аның ирен, миһербан иясе, эчкерсез, саф кешене, шул кешеләрнең үзләренә күп ярдәм күрсәткән кешене «халык дошманы» дип әйтүчеләрне ул кичерә алмады. Ул аларга мәете янына килергә дә рөхсәт бирмәде.

Аның янына Равил Шәрәфи белән хатыны Раушания еш килә иде, минем хатыным Рузия белән балдызым Фидания вафатына кадәр тәрбия итте, карады.

Заһидә апа 1988 елда, 13 август көнне туксан бер яшендә безнең кулда җан бирде.

Аның кабер ташына: «Саф намус, тугрылык һәм батырлык үрнәге — ул СИН», дип яздырдык.

Заһидә Тинчурина бу сүзләргә лаек тормыш кичерде.

Авыр туфрагы җиңел булсын! Аллаһ Кәрим белән Заһидәнең урыннарын җәннәттән әйләсен! Амин!

КҮПКЫРЛЫ ОЛЫ ТАЛАНТ ИЯСЕ

ГАЛИ АРСЛАНОВ,
сәнгать фәннәре докторы, профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы

XX гасыр татар әдәбияты һәм сәнгате үсешенә зур өлеш керткән, мәдәният тарихында тирән эз калдырган бөек шәхесләр арасында драматургиябез классигы, актёр, режиссёр, театраль педагог, Татарстан АССРның атказанган артисты (1926) Кәрим Тинчурин иң дәрәҗәле урыннарның берсен алып тора. Күпкырлы талант иясе үзе яшәгән чорда милләтебезнең иң күренекле вәкилләренең берсе була. Үзе эшләгән татар театр сәнгате өлкәсендә аның белән янәшә торырлык, аның белән ярышырлык шәхесләр сирәк. Шуңа күрә дә ул калдырган иҗади мирас әле бүген дә искерми, милли сәхнә сәнгатенең хәзергесе һәм алдагы көннәре өчен ышанычлы нигез санала. Ә иҗатка килә торган яшьләр өчен ул тиңдәшсез үрнәк, тирән тәҗрибә мәктәбе булып саналырга хаклы.

Кәрим Гали улы Тинчурин 1887 елның 15 сентябрендә Пенза өлкәсенең Бедный Демьян районы Таракановка (Белоозёрка) авылында күпбалалы хәлле крестьян гаиләсендә төпчек бала булып дөньяга килә. Башлангыч белемне гаиләдә һәм күрше авыл мәдрәсәсендә ала. 1900 елда Казанга килә һәм «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә укырга керә. Мәдрәсә еллары (1900-1906) яшүсмернең әдәбиятка, сәнгатькә тартылуында һәм дөньяга карашы киңәюендә хәлиткеч роль уйный. Ул үзлегеннән күп укый, белемен арттыра, мәдрәсәдәге шәкертләр

хәрәкәтендә актив катнаша. Протест йөзеннән, 1906 елда мәдрәсәгә реформа таләп иткән шәкертләр белән бергә, К.Тинчурин да «Мөхәммәдия»не ташлап чыга. Шуннан соң урман каравылчысы була, Түбән Новгородта мөгаллимлек итә. 1910 елда К.Тинчурин беренче татар профессиональ театр труппасы «Сәйяр»гә актёр булып эшкә урнаша һәм шул вакыттан алып үзенең бөтен гомерен, сәләтен татар театр сәнгатен һәм драматургиясен үстерүгә багышлый.

К.Тинчурин үзенең беренче сәхнә әсәрен — «Моназәрә» («Бәхәс») исемле комедиясен 1906 елда, мәдрәсәдә укыган чорда яза. 1910 елдан башлап исә ул ел саен диярлек берәр-икешәр пьеса иҗат итә. Аның «Хәләл кәсеп» (1910), «Шомлы адым» (1910-1912), «Беренче чәчәкләр» (1913), «Ач гашыйк» (1915), «Җилкуарлар» (1916), «Назлы кияү» (1916), «Соңгы сәлам» (1917) кебек драма һәм сатирик комедияләре Октябрь алды чоры татар драматургиясенең үсешен билгеле торган кыйммәтле үрнәкләр булып тора.

Октябрь революциясенең беренче көннәреннән үк К.Тинчурин татар театрын төзү эшенә алына. Гражданнар сугышы чорында башта Кызыл Армия сәяси идарәсе карамагындагы унөченче театр труппасының баш режиссёры һәм җитәкчесе, соңыннан 1920 елда Идел аръягы хәрби округы политик Идарәсе тарафыннан Самара шәһәрендә ачылган беренче Татар театр студиясенең җитәкчесе һәм актёр осталыгы, режиссура фәнен укытучы вазифаларын башкара. 1921 елда исә драматург Оренбургта Студия чыгарылыш шәкертләреннән төзелгән «Г.Кариевка хатирә» татар пролетар театр труппасына җитәкчелек итә, аннары берникадәр вакыт Ташкент шәһәрендә Гыйльми советның театр сәнгате бүлеге мөдире булып эшли. 1922 елда Татарстан хөкүмәте чакыруы буенча Казанга кайткач, аңа, күренекле татар артистларын җыеп, Дәүләт труппасын оештыру эше тапшырыла һәм ул булачак труппаның баш режиссёры итеп билгеләнә. Шул рәвешчә, К.Тинчурин җитәкчелегендә 1922 елның 8 ноябрендә Казанда беренче тапкыр махсус бинада, соңрак Кызыл Октябрь исемен алган үрнәк Татар Дәүләт драма театры ачыла.

Театр сәнгате өлкәсендәге оештыру эшләреннән тыш, К.Тинчурин бу елларда театр теориясе буенча мәкаләләр яза, татар театрының киләчәге, тоткан юлы һәм формасы турында уйлана. Актёр буларак, сәхнәдә җитди рольләр башкара, язучы буларак та иҗат активлыгын арттыра. Иң мөһиме «Зар» (1922), «Тутый кош» (1923), «Казан сөлгесе» (1923), «Американ» (1923), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Нәни абый» (1925), «Җилкәнсезләр» (1926), «Зәнгәр шәл» (1926) кебек күренекле комедия һәм драмаларын иҗат итә. Бу әсәрләрдә К.Тинчурин, революциягә кадәрге һәм аннан соңгы беренче еллар иҗатында ук ачык билгеләнгән сатирик юнәлешне дәвам иттереп һәм үстереп, егерменче еллардагы нэпман, вак буржуа тормышын, гадәтләрен фаш итә, искелек, торгынлык яклыларның бетүгә таба юл тотканнарын раслый. Тискәре типларның тулы бер галереясын тудыра. Аеруча «Американ», «Җилкәнсезләр» сатирик комедияләре үзләренең социаль яңгырашы, сәнгатьчә эшләнеше, сыйфаты, камиллеге, образларының күптөрлелеге белән кыйммәтле.

Егерменче еллар һәм утызынчы еллар башы К.Тинчурин иҗатында мөһим урынны «Казан сөлгесе» (1923), «Сүнгән йолдызлар» (1923), «Зәңгәр шәл» (1926), «Ил» (1929),

«Кандыр буе» (1932) кебек әсәрләр алып тора. Бу музыкаль драма һәм комедияләр шул чор күп татар профессиональ театр коллективлары һәм үзешчән труппаларның төп репертуарына әверелә. Татар халкының күренекле композиторы Салих Сәйдәшев музыкасы белән баетылган әлеге әсәрләр татар сәнгатендә М.Фәйзинең «Галиябану»ыннан башланган музыкаль драма жанры традициясен алга таба үстерәләр.

Утызынчы елларда К.Тинчурин шул чор чынбарлыгын чагылдырган «Корыч орчык» (1930), «Ударниклар бәйрәме» (1933), «Алар өчәү иде» (1935) кебек пьесаларын яза. Соңрак «Мәрҗәннәр» циклын тәшкил иткән сатирик һәм юмористик характердагы кыска хикәяләрен иҗат итә.

К.Тинчурин күпчелек әсәрләрен сәхнәгә үзе үк куя һәм спектакльдә башкаручы артист буларак та катнаша. Ул актёр буларак иҗат иткән байтак образлар татар театр сәнгатенең алтын фондына кертелергә хаклы. «Сәйяр» труппасында күренекле режиссёр һәм актёр Г.Кариев җитәкчелегендә башкарылган Җамали (Г.Камал, «Банкрот»), Газиз (Ф.Әмирхан, «Яшьләр»), Сөләйман (Ф.Әмирхан, «Тигезсезләр»), Таһир (Ф.Бурнаш, «Таһир-Зөһрә»), Гали (Г.Коләхмәтов, «Яшь гомер»), Хәмит (К.Тинчурин, «Беренче чәчәкләр»), Вахит (К.Тинчурин, «Соңгы сәлам»), Вурм (Ф.Шиллер, «Мәкер һәм мәхәббәт»), Незнамов (А.Островский, «Гаепсездән гаеплеләр»), Хлестаков (Н.Гоголь, «Ревизор»), Пётр (М.Горький, «Мещаннар») һ.б. образлар актёр К.Тинчуринның иң уңышлы эшләреннән санала. Егерменче елларда үзе язган һәм куйган әсәрләрдә башкарган Сәфәргали («Йосыф белән Зөләйха»), Искәндәр («Американ»), Надир («Сүнгән йолдызлар), Булат («Зәңгәр шәл»), Батырхан («Җилкәнсезләр») һ.б. кебек образлар да К.Тинчуринның сәхнә эшчәнлеген өйрәнүчеләрнең җитди игътибарына лаек.

Татар театрына нигез салучы, Г.Кариев мәктәбенең реалистик традицияләре дәвамчысы, аларны яңа шартларда үстерүче, баетучы бу олуг талантның режиссёрлык эшчәнлеген берничә өлкәгә бүлеп карарга була: практик режиссура, ягъни режиссёр-сәхнәгә куючы, режиссёр-оештыручы-җәмәгать эшлеклесе, режиссёр-педагог, режиссёр-теоретик. К.Тинчурин иҗатының төрле чорларында режиссёр хезмәтенең әле бер төре, әле икенчесе өстенлек ала һәм бу бүленеш, әлбәттә, объектив процессны чагылдыра.

Октябрь революциясенә кадәрге чорда К.Тинчурин, иң беренче чиратта — «Сәйяр» труппасы артисты, берничә әсәр язган драматург, аннан соң гына үз пьесаларын сәхнәгә куючы режиссёр. Режиссура сәнгатенә ул өлгереп җиткән актёр буларак килеп керә. 1915 елның көзендә Г.Кариев «Сәйяр»не үз антрепризасына күчерергә уйлый һәм, шул вакытта труппаның режиссёры В.Мортазин-Иманский Оренбургка күчеп киткәнлектән, бу урынны К.Тинчуринга тәкъдим итә. Шулай итеп, булачак режиссёрның бербөтен сәхнә әсәре тудыру сәнгате өлкәсендә тәүге адымнары Кариев кул астында ясала.

1915-1916 ел сезонында «Сәйяр» шактый зур кыенлыклар кичерә. Ел дәвамында Г.Кариевның тамак авыруы көчәя, куярга яңа әсәрләр җитешми, төрле сәбәпләр аркасында В.Мортазин, М.Иманская белән бер үк чорда диярлек Сара һәм Җәлал Байкиннар, Г.Мангушев, Н.Сакаев кебек танылган артистлар труппадан

китә. Шушы авыр шартларда да ул сезонда 28 спектакль уйнала, алдагы елларга караганда күбрәк табыш алына. Әмма вакытлы матбугат битләрендә бу елларда К.Тинчуринның режиссёр буларак спектакль куюы турында мәгълүмат юк. Театрның шул сезоны эшчәнлегенә йомгак ясаган тәнкыйтьче Г.Кәрам «Аң» журналында басылган күләмле мәкаләсендә К.Тинчуринның актёрлык эшенә киң тукталса да, режиссёрлык хезмәте турында бер сүз дә язмый. Биредә бары тик труппаның җитәкчеләре турында «мөдир мәсъүл Кариев, режиссёр Тинчурин» [1], дигән белешмә генә биреп кителә. Димәк, яшь режиссёрга күбрәк әле яңарак кына сәхнәгә аяк баскан Г.Камал I, Х.Колмәмәт, С.Айдаров, Ф.Бакиров, Әхмәдова, Шамилова кебек яшь артист һәм артисткалар белән актёрлык осталыгын күтәрү өлкәсендә эшләргә туры килгәндер дип уйларга кирәк.

Алдагы ел К.Тинчуринга драматург буларак та, режиссёр буларак та танылу алып килә. 1916-1917 ел сезонында ул бер-бер артлы үзе язган «Шомлы адым», «Соңгы сәлам» драмаларын сәхнәләштерә. Театр дөньясындагы һәр яңалыкка үтә сизгер Г.Кәрам бу турыда: «Тинчурин бу ел «Шомлы адым», «Соңгы сәлам» исемле ике пьеса мәйданга куеп, милли сәхнәмезнең репертуарын киңәйтте вә, үз тәэлифе булган «Соңгы сәлам» исемле әсәрен куеп, җитди муафәкыять казанды» [2], — дип язып үтә. Моннан соң режиссёр 1917 елның 25 августында «Ятлар» драмасын тамашачыга тәкъдим итә (кайбер чыганакларда [3] 1916 елның 25 ноябрендә куела дип бирелә. Икенче атамасы — «Шомлы адым». — Ред.), ә «Назлы кияү» спектакле исә 1916 елның 23 декабрендә үк әзер булса да, сәхнәгә бары тик Октябрь революциясеннән соң, 1918 елның 12 гыйнварында гына чыгарыла.

Октябрьгә кадәрге чорда К.Тинчурин үзенең өч әсәрен сәхнәгә куя. Бу пьесалар Г.Кариев режисурасыннан кабул ителгән сурәтләү чаралары, эш алымнары ярдәмендә сәхнәләштереләләр. Аларга «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт»тә куелган спектакльләрнең күбесендәгечә павильоннар системасына нигезләнгән сценография, персонажларның социаль дәрәҗәсенә, җәмгыять баскычының нинди биеклегендә торуына карап тегелгән кием, геройлар арасындагы мөнәсәбәтләрнең яшәеш конкретлыгыннан алынуы хас. Персонажларның сөйләшү, хәрәкәтләнү манералары да реаль тормышта очрый торган кешеләрне хәтерләтәләр.

«Соңгы сәлам», «Шомлы адым» спектакльләренең актёрлар ансамбле дә шактый үзенчәлекле. Бу беренче чорда К.Тинчурин-режиссёр күбрәк тамашада катнашучы башка артистларга түгел, үзенә — Тинчурин-актёрга таяна. Шуңа күрә дә тәүге сәхнәләштерелгән спектакльләр үзәккә омтылучан композициягә ия, «солист һәм хор» принцибына нигезләнгән. Үзәктә бер төп герой, ә калган барлык персонажлар аны аныклау, аның психологиясен, кичерешләрен, трагедиясен ачу өчен хезмәт итә. Шушы алымнар ярдәмендә режиссёр геройның язмышын, гомеренең соңгы минутларын сурәтли, үлемгә илткән төп сәбәпне күрсәтә һәм тамашачыларны герой эшләгән ялгышны кабатламаска чакыра.

Ил тарихындагы борылыш вакыйгалары сәнгать әһелләре алдына заманча яңгырашлы, чор проблемаларына авараздаш әсәрләр тудыру бурычын куя. Кәрим Тинчурин сәхнәләштергән «Ике фи-

кер», «Яшь гомер» (Г.Коләхмәтов), «Беренче таң» (Г.Ниязбаев), «Революция» (В.Исхаков), «Беренче адым» (Ш.Усманов) кебек әсәрләре иң элек вакыт таләпләренә җавап бирүе, күпләрне дулкынландырган мәсьәләләр күтәрүе, көн геройларын сәхнәгә чыгаруы белән кыйммәтле. Бу пьесаларның күбесе Г.Кариев режиссура мәктәбенең реалистик традицияләре нигезендә куелган. Ләкин шушы ук чорда К.Тинчуринның режиссёрлык эшчәнлегендә традицион реализм кысаларының киңәюе, аның яңа стиль, жанр төсмерләренә баюы турында ассызыклап әйтергә кирәк. Бу яктан караганда Г.Коләхмәтовның «Ике фикер», Ш.Усмановның «Беренче адым» әсәрләре буенча куелган спектакльләр аеруча игътибарга лаек. «Ике фикер» әле моңарчы татар театрында күрелмәгән үзенчәлекле стиле белән аерылып тора. Аның тукымасында көнкүреш конкретлыгы — шартлылык, психологик тирәнлек — аерым образларның символ, аллегория алымнары ярдәмендә чишелеше белән кушыла. Шул ук вакытта бу сәхнә әсәрләрендә туып килгән кино сәнгатенең монтаж, вакыйгаларны катлау, бер-берсе өстенә салу кебек алымнары да кулланыла. Ә «Беренче адым»да тормыш дөреслегенә агитацион театрга хас сурәтләү чаралары өстәлә. Биредә кичерешләргә, сыйнфый куралмаучылыктан башка хисләргә урын аз бирелә. Иң мөһиме — революцион тизлек, вакыйгаларның динамик агышы, төрле сыйныф вәкилләре арасындагы мөнәсәбәтләрнең соң дәрәҗәдә кискенләштерелүе.

Егерменче елларда К.Тинчурин — татар классик драматургиясенең алтын фондына кергән берничә пьеса биргән әдип, милли сәхнәбезнең үсеш юнәлешен билгеләгән режиссёр һәм театрның узганы, бүгенгесе, киләчәге турында төпле фикер йөртүче теоретик.

Алда әйтелгәнчә, 1922 елның җәендә әле яңарак кына Ташкенттан кайткан К.Тинчурин ачылу алдында торган һәм Кызыл Октябрь исемен йөртәчәк Татар дәүләт драма театрының баш режиссёры итеп билгеләнә. Режиссёр тиз арада 35 кешедән торган актёрлар коллективы туплый һәм сигез әсәрдән торган репертуар булдыра. Алар арасында Н.В.Гогольнең «Ревизор», Г.Дрегелиның «Яхшы тегелгән фрак», Ф.Бурнашның «Яшь йөрәкләр», «Җирсезләр», К.Тинчуринның «Беренче чәчәкләр», Ш.Усмановның «Бай кызы» һ.б. әсәрләр бар. Г.Камал исемендәге данлыклы Татар дәүләт академия театрының нигезе нәкъ менә шушы елларда салына.

Сезон тәмамлангач, республика матбугатында татар театрының тоткан юлы, юнәлеше, спектакльләрнең формасы турында фикер алышу башлана. Беренче мәкаләне К.Тинчурин яза. «Татар театры нинди юл белән барырга тиеш?» дип атала ул. Шушы мәкаләсендә дә, соңрак басылган «Хәзерге театрның рәвешенформасын үзгәртергә кирәк» дигән язмасында да, башка урыннардагы күпсанлы теоретик чыгышларында да режиссёр эзлекле реализм позициясендә тора. Шул ук вакытта, аның аңлавынча, реализм катып калган догма түгел. Вакыт узган саен ул яңарырга, баерга, күпмедер рәвештә үзгәрә барырга тиеш. Шуннан чыгып, спектакльләрнең форма, стиль, жанрлары да күптөрле булырга мөмкин.

«Вакытлы яңа татар театры караучының вакытын мөмкин кадәр аз алып, мөндәриҗәсе чын, күңелле һәм төрле-төрле булырга тиеш, — дип яза К.Тинчурин. — Декорация

техникасы, персональ һәм уйнаучы артистлар аз булу белән бергә, сәхнәдә музыка, нәфис сүз, пластика, бию һәм башка төрле трюклар да кертелергә тиеш» [4]. Күренгәнчә, бу мәкаләсендә режиссёр милли сәхнә сәнгатен яңа сурәтләү чаралары белән тулыландыру проблемасын да күтәрә.

Егерменче елларда куелган спектакльләр Тинчуринның режиссёрлык өлкәсендәге уйлануларының, эзләнүләренең тормышка ашуы, практик гәүдәләнеше булып саналырга хаклы. Әлеге әсәрләр реализмның нык-лы җирлегендә тора. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: бу чорда К.Тинчурин реализмы Г.Кариев традицияләреннән шактый үзгә. Чор белән бәйле рәвештә әсәрләргә яңа эчтәлек салынган. Шушы эчтәлек спектакльләрнең формасында да чагылыш таба. Хәзер инде сәхнә әсәрләрендә тормыш-көнкүреш билгеләре Октябрьгә кадәрге театрдагы шикелле үк куе түгел. Геройларның эчке кичерешләрен, психологиясен гәүдәләндерү дә беркадәр тизләтелгән. Сурәтләү чараларының күптөрлелеге, музыка, җыр, бию, юмор, сатирага бай булу, вакыйгаларның тизләтелгән агышы К.Тинчурин режиссурасының үзенчәлекле театральлеген тудыра. Үзе язган һәм куйган «Казан сөлгесе», «Сүнгән йолдызлар», «Американ», «Зәңгәр шәл», «Ил» кебек спектакльләре белән К.Тинчурин егерменче елларда режиссёрлык эшчәнлегенең иң югары баскычына күтәрелә. Аларда останың сәхнә кануннарын бөтен нечкәлекләренә кадәр аңлавы, драматургияне, артист иҗатын төптән белүе ярылып ята.

1922-1927 елларда К.Тинчурин берничә сезон Кызыл Октябрь исемендәге (1926 елдан академик театрлар исемлегенә кертелгән) коллективның баш режиссёры булып эшли, соңрак ике сезон Әстерхан Татар дәүләт драма театрына җитәкчелек итә.

Егерменче еллар — К.Тинчуринның театраль-педагогик эшчәнлеге киң җәелгән чор. Самара студиясендә башланган бу хезмәт соңрак озак вакыт Татар театр техникумында дәвам иттерелә. Режиссёр-педагог буларак Тинчурин — студентларга үтә сакчыл карашлы, эчке тактка ия, таләпчән, эрудицияле шәхес. Шәкертләрендә ул татар халкының милли әдәбиятына, сәнгатенә, рухи һәм матди культурасына мәхәббәт тәрбияләргә тырыша, сәхнәдән яңгыраган телнең сафлыгы өчен көрәшә.

1929 елда К.Тинчурин яңадан Татар дәүләт академия театрына чакырыла. Театрда әле яңарак кына кертелгән сәнгать җитәкчесе урынында бер ел эшләгәннән соң, режиссёрлар коллегиясе әгъзасы итеп күчерелә. Утызынчы елларда театрга Мәскәү, Ленинград шәһәрләрендә белем алган Р.Ишморатов, С.Булатов, Г.Ильясов, Г.Исмәгыйлов, бераз соңрак Ш.Сарымсаков, К.Тумашева кебек яшь режиссёрлар кайта. Унъеллык урталарына таба К.Тинчурин практик режиссура белән шөгыльләнүдән туктый. Аның ТДАТтагы соңгы спектакле 1934 елның 23 февралендә Р.Ишморатов белән берлектә куела. Ф.Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» драмасы буенча эшләнгән бу спектакль К.Тинчуринның егерме еллык режиссёрлык хезмәтенә йомгак ясый.

К.Тинчурин иҗаты гел уңай шартларда гына үсми. Авторга шактый гына авыр сүзләр ишетергә, кырын карашлар тоярга да туры килә. Мәсәлән, Академия театрының 1927 елда Уфадагы гастрольләре вакытында Кара Сакал псевдонимлы берәү К.Тинчурин әсәрләрен бөтенләй «юкка чыгарган» мәкалә бастыра («Сәнәк» журн., №2). Аннан күреп, тагын берничә шундыйрак эчтәлекле

тәнкыйть язылa. Әммa К.Тинчурин әсәрләренең елдан-ел зуррак уңыш казана баруы аларга карата әйтелгән тискәре карашларны һәм шикшөбһәләрне кире кага. Нәтиҗәдә тормышны һәм театр сәнгате серләрен тирәнтен белеп язылган бу әсәрләр бөтен татар сәхнәсен яулап ала. Бу К.Тинчурин иҗатына булган игътибарны көчәйткәннән-көчәйтә бара, аңардан өйрәнергә чакырган мәкаләләр күренә башлый. Мәсәлән, 30 нчы еллар башыннан Академия театрының режиссёрлар коллегиясенә җитәкчелек иткән Риза Ишморат драматургларга менә нинди сүзләр белән мөрәҗәгать итә: «Ил» һәм «Зәңгәр шәл» пьесаларының күп еллар буена безнең сәхнәдән төшмичә зур уңыш белән куелып килүләренең сере дә аларның сәнгатьчә яхшы эшләнгән булуларында. Бу әсәрләр тамашачы тарафыннан кызыксынып, йотылып каралалар. Шуңа күрә дә безнең авторларга, бигрәк тә яңа яза башлаган яшь драматургларга, К.Тинчуриннан өйрәнергә, аның язу алымнарын җентекләп тикшерергә киңәш итәр идем» [5].

1936 елның маенда киң җәмәгатьчелек аның иҗат эшчәнлегенә егерме биш ел тулу датасын зурлап бәйрәм итә. Зур тантана белән үткәрелгән юбилей язучыны тагын да дәртләндереп, илһамландырып җибәрә.

Октябрь революциясенең 20 еллыгын лаеклы каршылау максаты белән, К.Тинчурин үзалдына бик зур иҗади бурычлар куя. Бу турыда ул Татарстан Язучылар союзына түбәндәгечә хәбәр итә:

«Татарстан совет язучылары союзы янындагы драматургия секциясенә.

Октябрьнең 20 еллыгына карата эш планым.

Мин хәзерге вакытта дүрт төрле жанрда, сәхнә әсәрләре өчен дүрт төрле теманың планнары өстендә эшлим.

1. «Тормыш яхшырды, тормыш күңеллеләнде» дигән темага кечкенә күләмле, җиңел, шатлык күрсәткән бер комедия өстендә эшлим.

Бу комедия эчтәлеге һәм күләме белән, формасы ягыннан Академия сәхнәсендә һәм колхоз сәхнәләрендә уйналырлык итеп эшләүне сорый. Исеме шарт белән «Алгөл» яисә «Мәзәкчән повар», өч пәрдәдә булырга тиеш. Катнашучыларның күбесе 19 яисә 20 яшь тулган эшчеләр, комбайнёр, тракторчы һәм студентлар булыр.

2. Гражданнар сугышын чагылдырган тема.

Бу пьеса өчен Октябрь алдындагы хәлләрне һәм Казаннан чехларны куу материалын алырга уйлыйм. Бу әсәр драма жанрында булырга тиеш.

3. Стаханов хәрәкәте белән единоначалие моментларын куша алмаган вельможаның трагедиясен күрсәткән комедия. Исеме — «Ул масайды».

4. Совет мелодрамасы жанрында бер әсәр язып карарга бик кызыгам. Шул темага Академия һәм эшче, колхоз сәхнәләрендә барырлык әсәрнең планы өстендә эшлим. Исеме — «Аның туган көне» булыр.

Югарыда күрсәтелгән темаларның дүртесен дә Октябрьнең 20 еллыгына язып бетерәм, дип аңлашылмасын.

Бу дүрт теманың берсен яки күп булса икесен Октябрьнең 20 еллыгына өлгертәчәкмен, чөнки пьесалардан башка Октябрьнең 20 еллыгына 10-15 данә «Мәрҗәннәр» дигән новеллаларны да эшләп бетерергә уйлыйм».

17.5.1936

К.Тинчурин

(ТАССР ҮДА ф.7083, эш 74, Б.1. Материал «Совет әдәбияты»ның 1964 елдагы 12 санынннан алынды).

1937 елның башында еллык план түбәндәгечә конкрет төс ала:

1.«Мин хәзер «Мәрҗәннәр» өстендә эшлим, март ахырында өлгертергә уйлыйм. Күләме 12-13 табак чамасы булыр.

2.«Зәңгәр шәл» либреттосының икенче вариантын эшлим.

3. 1937 елның апреленнән башлап колхозларның беренче кешеләрен күрсәткән яңа пьеса өстендә эшли башлаячакмын. Ул пьесаны 1937 елның сентябрь азагында тәмам итәрмен дип торам... К.Тинчурин».

(Материал шуннан ук алынды).

Кызганычка каршы, бу теләкләрне тормышка ашыру насыйп булмый. К.Тинчурин өстендәге болытлар елдан-ел куера бара. Моңа кадәр үк яңгырап килгән «вак буржуа язучысы», «милли демократизм» турындагы гаепләүләр утызынчы еллар уртасына шактый куера, тискәре бер гәүдәләнеш ала. 1935 елда аны штат кыскарту сылтавы белән театрдан чыгарып ташлыйлар. Приказдагы формулировка игътибарга лаек: «Театрның иҗади йөзенә зарар китерми торган кыскартулар...» Әйтерсең лә, 25 ел буена армый-талмый милли театрның төрле өлкәләрендә бердәй уңыш белән эшләп килгән фидакарь сәнгать эшлеклесе иҗаты инде берни дә тормый! Театрда аның булу-булмавының бернинди әһәмияте юк!

Беренче һөҗүмне К.Тинчурин лаеклы кире кага. Алай гына да түгел, үзе дә һөҗүмгә хәзерләнә. Иҗади эшчәнлегенә 25 ел тулу уңае белән 1936 елда бөтен республика күләмендә уздырылган юбилей тантаналары, илнең төрле төбәкләреннән килгән котлау хатлары, телеграммалар, Татарстан хөкүмәте бүләк иткән язу машинкасы, Казан хәрби гарнизоны бүләк иткән ау мылтыгы һ.б. — үз-үзенә нык ышанган, дәрәҗәсен бәясен, сәнгатьтәге тоткан урынын белгән олы шәхеснең астыртын дошманнарына җавап сүзе булып тора.

Кәрим Тинчуринны алырга илле яшьлек юбилее көннәрендә, төгәлрәк әйтсәк, 17 сентябрьдә киләләр. Астыөскә китерелгән фатир. Арттан елап, төрмә капкасы төбенә кадәр килгән тол калачак хатын. Гатин фамилияле тикшерүченең төн уртасында уятып сорау алулары, кыйнаулары. Җиде пункттан торган гаепләү акты.

7 гаепләүнең 4се Гаяз Исхакый исеме белән бәйләнгән: «Ил» газетасы редакциясендә эшләгән, Коммунистлар партиясенә каршы көрәш җәелдергән, Казаннан ак чехларны куганда Г.Исхакый, Җ.Вәлиди, Ф.Сәйфи-Казанлы белән Тәтешкә, Самарага чигенгән, буржуаз милләтче, ак эмигрант Г.Исхакый белән хат алышкан, «Милли юл» журналын алып торган, япон шпионы Х.Исхаков белән бәйләнештә булган, аннан Г.Исхакый пьесаларын алган һ.б.

Әмма ел да ике айга сузылган сорау алулар нәтиҗәсез кала. К.Тинчурин үзенә тагылган нахак гаепләрне кире кага, үз-үзенә хыянәт итми.

Өч кешелек махсус комиссия тарафыннан 1938 елның 14 ноябрендә чыгарылган карар катгый: атарга! Карар шул ук төнне, таң алдыннан үтәлә. Кәрим Тинчуринның үлгән вакыты — 15 ноябрь, иртәнге ике туларга 10 минут...

Әдәбият-сәнгать өлкәсендәге эшчәнлегенә 25 ел тулу уңае белән үткәреләчәк юбилей көннәре алдыннан К.Тинчурин, Язучылар союзы үтенүе буенча, 1936 елның маенда үз кулы белән барлык сәхнә әсәрләрен эченә алган исемлек төзеп бирә. Бу исемлек тантанага чакыру билетында басылып та чыга. Моннан күренгәнчә, К.Тинчурин 26 сәхнә әсәре иҗат иткән, аларның өчесе башка

язучылар («Корыч орчык» (Ф.Сәйфи-Казанлы), «Тургай» (Р.Ишморат) һәм «Булат бабай гаиләсе» (К.Нәҗми)) катнашында язылган. Шуның өстенә ул башка телләрдән дүрт пьеса үзгәртеп татарчалаштырган («Хан кызы Турандык», «Чит илләрдә», «Европа коралсызлана», «Зәңгәр палас» — соңгы варианты «Кара күз» исеме белән йөртелә). Исемлектә күрсәтелгән беренче әсәрләрдән «Моназара» белән «Хәләл кәсеп»нең әлегечә табылганы юк.

Бу әсәрләр, күпсанлы татар һәм тугандаш төрки халыкларның сәхнәләрендә куелып, зур уңыш казанса да, үз иҗатына һәрвакыт таләпчән булган тыйнак табигатьле К.Тинчурин аларны бастырып таратуны аеруча җаваплы мәсьәлә дип караган. Шуның нәтижәсендә бары 1935 елда, иҗат эшчәнлегенә 25 ел тулу бәйрәме уңае белән генә, аның беренче пьесалар җыентыгы дөнья күрә. Моның сәбәпләрен драматург үзе әлеге китабына язган «Автордан» дигән кечкенә керешендә болай аңлата: «Сәхнә әсәрләрен бастырып тарату эшендә ашыкмауның уңай якларын да искә алып үтәргә кирәк... Сәхнә әсәрләре нихәтле озак һәм күп сәхнәдә уйналсалар, шулхәтле аларның кимчелекләре авторга ачыграк күренә башлый. Менә шул кимчелекләрне күрү һәм аларны бетерү өчен вакыт кирәк, әсәрнең фикер һәм сәнгать тирәнлегенә авторның үзенең ышанып җитүе дә кирәк».

Бәлки бу фикерләр бүген — күп пьесалар язылып бетәр-бетмәс сәхнәгә менгән, зур тиражлар белән басылып чыккан чорда — кемгәдер бәхәсле тоелыр. Әмма К.Тинчурин бернәрсәдә, һичшиксез, хаклы: пьеса никадәр җентекләп, ашыкмыйча эшләнсә, өстәвенә сәхнә кануннары ярдәмендә тикшерелсә, сыйфат ягыннан шулкадәр үк камил булачак. Бусы — бәхәссез. Тик таяк ике яклы. Тинчуринның шактый күп әсәрләре бастырып чыгарылмаганга, кулъязма хәлендә калган яки бөтенләй югалган.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: К.Тинчурин иҗатының иң югары баскычында торган чорда тормыштан китәргә мәҗбүр ителә. Ни кызганыч, үзе белән зур иҗат планнарын, язылачак пьесаларын, тудырасы образларын да алып китә. Тик үкенүдән файда юк. Тарихи хаталар төзәтелми. Безнең кулдан килгәне — драматургның бөтен иҗат мирасын төрле архив, музей фондларыннан, аерым шәхесләрдән бергә туплап, барлап, күптомлык итеп бастырып чыгару. Моннан соң алга таба К.Тинчуринның мирасын академик басма итеп әзерләү дә көн тәртибенә куелырга мөмкин.

К.Тинчурин — татар театрында Октябрьгә кадәр үк формалашкан Г.Кариев мәктәбенең реалистик традицияләрен бүгенге көн казанышлары белән тоташтырган сирәк шәхес. Аның пьесалары милли театрларыбызның репертуарында әһәмиятле урын тота. Бүгенге көндә сәхнәләребездә К.Тинчурин тәрбияләгән артистларның шәкертләре эшли. Театр әһелләренең һәр яңа буыны аның драматургиясендә чыныгу ала. Димәк, К.Тинчурин традицияләре исән, яши, үсә, ныгый. Халкыбыз күңелендә ул кабызган утлар, хәтәр җилләрдә дә сүнмичә, якты нурлар белән әле бүген дә балкып тора.

Әдәбият:
1. Аң, 1916. — № 10.
2. Аң, 1917. — № 7.
3. Мәхмүтов Һ. [«Ятлар» — «Шомлы адым»] // Кәрим Тинчурин: тарихи-документаль, әдәби һәм биографик җыентык / төз. И.Һадиев, Р.Батулла. — Казан: Җыен, 2011. — 688 б. — Б.412.
4. Татарстан, 1923. — 11 ноябрь.
5. Яңалиф, 1932. — № 9-10. — Б.96.



ТЕГЕ ЧАК

ЗӨЛФӘТ

Тинчуринның «теге чагын» күрдем,
Күрдем аны «секрет дело»да —
Передача илтеп, хәл белешеп,
Йөрер булганмын ла мин аңа!
Юк, сүнмәде... астан пыскый һаман
Явызлар ут төрткән бу учак! —
Ә «Зәңгәр шәл» дисәң, сискәндереп,
Һаман искә төшә «теге чак»!
«Булат, Булат кайткан!» —
сизмәдекме
Ул Булатның каян кайтканын?
Мәйсәрәгә дигән зәңгәр шәл, дип,
Кайда гына җаннар атканын?
«Теге» дигән шул чак баласы без...
Булдык мәллә илдә бер курчак?
Юкса күптән инде «булакта» без?
Әмма...
ник ычкындырмый
Теге чак?
Истә Сибгат Хәким сөйләгәннәр:
— Кайтты Хәсән абый... тегеннән.
Күргәч әйтте: «Бергә икән!» —
Нигә әйткәнлеген мин беләм...
«Сүндермичә утны саклагансыз!» —
Дигәне ул шулдыр иде лә! —
Окопларда сау саклаган башны
«Халык дошманы»на и менә!
...Безнең язмыш язылгандыр инде
Бөек илгә ялгыш тегелеп,
Эзәрлекли безне гомер буе
«Безнекелек» түгел, «тегелек»!..
И туганкай, сереңң яшермичә
Ачыктан да ачык әйт инде,
Бу җан өчен Тинчурин безнекеме,
Әллә инде «тегенекеме»?
Аларның бит җәсәдләре хәтта
Качып-посып кына күмелгән...
Тинчурин, дим... Үзебезгә язган
Сәер язмыш килә күңелгә...
...Күрдем Тинчуринның «тегендәге»
Төшерелгән яман сурәтен...
Шуннан бирле һич тә аңлый
алмыйм
Тыңлаусыз бу сәер йөрәкне.
...Бер сорау бар —
нигә сүнми һаман
Ул тергезгән гүзәл бер учак?
Әйттем. Беттем.
Мин имзамны куям,
Һәм датаны куям —
«теге чак»...

ТУКАЙ ЭНЦИКЛОПЕДИЯСЕНӘ

ТАЯН АЛЛАГА (1909), шигырь. Дини-әхлакый тәрбия бирү максатын күздә тотып, балалар өчен язылган бу әсәрнең үзәгендә — барлык вөҗүде белән ихлас, «башына бернинди бозык уй кермәгән», теле белән һич яман сүз әйтмәгән, «пакь җанлы», «пакь тәнле» гөнаһсыз яшь бала образы. Ул — чын мәгънәсендә шәрык мөселман эстетикасы һәм этикасы өчен Акыл — Җан — Тән матурлыгын һәм камиллеген үзенә туплаган рухи сафлык символы. Лирик герой, язылмаган чиста дәфтәр битен, нурдан яратылган фәрештә валчыгын хәтерләткән ап-ак йөзле бу балага гомер юлының имин-бәхетле булуын сорап, Галәмнәрнең Бөек Раббысына үз рәхмәтеңнән ташламасаң иде дип, ялварып мөрәҗәгать итәргә киңәш бирә: *«Йа Ходай, күрсәт диген, ошбу җиһанда якты юл, / Ул рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул».* Шигырьнең башында һәм азагында кабатлаулар ярдәмендә фикри терәк, бәйләгеч һәм чолгаулы кайма вазифасын үтәгән бәйтләрдә Аллаһы Тәгаләнең шәфәгате, мәрхәмәте чиксез булуга аеруча зур басым ясала: *«Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала! / Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага».* Бу бәйтләрнең эчтәлегеннән күренә ки, аларда 1907-1911 еллар аралыгында Казан зыялылары арасында кайнар бәхәсләр уяткан дин галиме Муса Бигиев хезмәтләренең, бигрәк тә аның «Рәхмәте илаһия гомумияте хакында илаһия борһаннары» китабындагы (1909) «Алланың мәрхәмәте барлык җир кешеләренә дә тигез бирелә» дигән үзәк фикернең тәэсире сизелеп тора. Тукайның бу китапка багышлап «Зур бәшарәт» (1909) исемле юмористик шигырь язуы, анда: *«Беләмсез, калмыйсыз сез утта мәңге, — / Алыр сезне йолып Муса әфәнде!»* — дип, җәмәгатьчелеккә җиңелчә шаярулы сүз ташлавы бу фаразны расласа кирәк. Сүз дә юк, Тукайның «Таян Аллага» шигырен иҗат итүгә М.Бигиев хезмәте этәргеч ясаса да, аның дини-әхлакый эчтәлеге өчен төп таяныч һәм үрнәк вазифасын Коръән тәгълиматы үтәгән. Шуңа күрә дә, лирик геройның гөнаһсыз яшь баланы кыйбла каршына утырып гаршеләргә сыгынырга чакыруы, Илаһиятнең аңа карата рәхмәтле, рәфаһәтле, сәгадәтле тереклек җибәрүен ихлас күңелдән теләве шигырьнең тулысы белән дога мотивларына корылуы һәм аның, гомумән, дога жанры әсәре булуы турында сөйли. Тукай иҗатында дога жанрының төрле төрләре булу мәсьәләсе Д.Абдуллинаның «Тукай иҗатында Коръән мотивлары» исемле хезмәтендә тәфсилле тикшерелгән (2005). «Таян Аллага» шигыренең рус шагыйре М.С.Никитинның «Молитва дитяти» әсәре белән охшашлыгын, дога жанрына тартым булуын Тукай әсәрләренә комментарий бирүчеләр дә искәртеп үтәләр.

Шигырь (мәснәви) аа бб вв рәвешендә рифмалашкан, һәр юлы 15 иҗекле, 4 ритмик буынлы 6 бәйттән тора; гарузның рәмәл төрендә язылган. Кульъязмасында исеме: «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә». Беренче мәртәбә, «Таян Аллага» дип исемләнеп, «Яңа кыйраәт» китабында (1909), ә «Балалар күңеле»ндә (1910) әүвәлге исеме белән бирелгән.

Чыганак:

Тукай Г. Әсәрләр. Академик басма. — 2 том. — 2011. — Б.72.

Әдәбият:

Абдуллина Д.А. Габдулла Тукай иҗатында Коръән мотивлары. — Казан, 2005. — Б. 81-91. (диссертация); Ганиева Р.К. Творчество Габдуллы Тукая в контексте мировой литературы // Сб. МНПК «Паритетное евразийство: Исламский Ренессанс и философия поэзии Габдуллы Тукая. — Уральск, 2011. — С.87; Абузяров Р.А., Каримов Т.А. История Евразийского центра Габдуллы Тукая. — Уральск, 2011. — С.142-143.

Резеда Ганиева,
филология фәннәре докторы

**Сәхифәне филология фәннәре докторы Зөфәр Рәмиев алып бара.*

ЧИРАТ

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ

Җиңү көне. Мин урамда йөрим,
Уйлап йөрим шигырь язарга.
Рифма эзләп шактый изалангач,
Кагыласы иттем базарга.

Кайный базар, гүя рейхстаг.
Түбәсендә — Җиңү байрагы.
...Ит чабучы, сабыр палач кебек,
Озак итеп балта кайрады.

Чапкан саен башлар оча тора,
Ит чабучы, сабыр палач кебек,
Озак итеп балта кайрады.

Чапкан саен башлар оча тора,
Ит чабучы ярсып кизәнә.
Бу базарда сатып булыр кебек
Намусны да салып бизмәнгә.

Һәрнәрсәгә аның үз бәясе,
Исе китми шигырь-мазарга.
Ите — кыйммәт,
әә баш — очсызрак...
Баш бәясе арзан базарда.

Кем чираты?
Базар палачының
Күтәрелә канлы балтасы...
Стенадан көлеп карап тора
Халыкларның үги атасы.

Аны күргәч, кинәт ирексездән
Әрнегәндәй булды муеным.
Ит чабучы. Чират. Тәгәри баш.
Ул елмаеп сыйпый мыегын.

Кем чираты?
Дәште салкын аваз,
Авыр аваз, гүя кургашын.
Күрдем кебек базар чиратында
Горур башын Фәтхи Бурнашның.

Кем чираты?
Дөньяларның бүген
Сугым базарына тиң чоры.
«Исән булса башлар, кайтырбыз!» — дип
Саубуллаша Кәрим Тинчурин.
Кем чираты?
Бар кешеләр өнсез:
Юк шаярган, көлгән, уфтанган.
Аваз килә: «Мә, партия, мине!» —
Соңгы бүләк аңа Туфаннан.

Кем чираты?
Оча миллион башлар...
Ил атасы гүя котырган...
Кем чираты?
...Күзләремне ачсам,
Базар чиратында мин торам.

Тирә-юньдә кабер салкынлыгы.
Мин ашыгып чыгам базардан.
Урамда — яз. Илдә — Җиңү язы!
Аермасын язмыш язлардан.

ИҢ КАДЕРЛЕ БАЙЛЫК

ФӘНИС ЯРУЛЛИН,
Татарстан Республикасының халык шагыйре

Сибгат абзыйны авылда олысы-кечесе хөрмәт итә. Өлкәннәр каршында ул үзенең тынгысызлыгы, учында ут биетеп эшләве белән абруй алган. Чын мәгънәсендә, типсә — тимер өзәрлек кеше. Кырык елдан артык тимерчелектә эшләү дәверендә нинди генә корычны эретмәгән дә, нинди генә тырма-сабанның гомерен озайтмаган ул. Әмма ут-күз малайларның, күбәләк-җан кызларның хыялын канатландырган, күзләрен яндырган нәрсә Сибгат абзыйның эш сорап кыюткан куллары түгел, ә матур итеп сөйләве. Юк, җиде башлы диюләр, сихерле карчыклар һәм тагын әллә нинди нәрсәләр турында сөйләми ул. Үз башыннан, ил башыннан үткәннәрне матур итеп хикәяләве белән нәни дусларының күңелен яулап ала.

— Беләсезме, оланнар, — дип сөйләп китә Сибгат абзый сыңар күзен хәйләкәр кыса төшеп. Бармак юанлыгы кашлары мут кына сикерә башладымы, көт тә тор: нинди дә булса хикмәтле сүз, гыйбрәтле сүз әйтәчәк. — Беләсезме, оланнар, — дип янә кабатлый ул, — иң кадерле байлык нәрсә?

Балалар бер-берләренә карашып куялар. Кайсы «алтын», кайсы «көмеш» ди. Җирдәге һәртөрле кыйммәтле нәрсәләр саналып чыга, әмма Сибгат абзый аларның сүзләрен расларга ашыкмый. Тынгысыз җан малайлар:

— Нәрсә соң ул иң кадерле байлык? — дип, Сибгат абзыйның хәйлә белән кысылган күзләренә карыйлар.

— Алайса мин сезгә бер нәмәстәкәй сөйлим әле. Борын-борын заманда,

кәҗә команда, саескан үрәтник булып торган чакта түгел, ә саескандай йомырка эчеп симергән үрәтникләр, кәҗәдәй аңгыра губернаторлар, козгындай үләксәгә сусаучы патшалар әрбәлюция җиленнән җәһәннәмгә очкан чакта, фронтта өченче ел инде окоп салкыны имеп ятучы әткәйдән хат килеп төште. Әни авырып ята иде. Хатны күргәч, көч хәл белән торып утырды. Аны бик кадерле нәрсәдәй саклык һәм олылау белән кулына алды, укый белгән кеше кебек кәкребөкре хәрефләргә озак кына карап торды. Төрлечә әйләндергәләп, һәр юлын күздән кичергәннән соң, сәке йөзлегенә тотынып, аягына басты.

— Кая кузгаласың, әнкәй? — дидем куркып.

— Мөгаллим абзаң янына барыргае, Сибгат улым, аннан башка хатны кем укысын?

— Мөгаллим абзыйларга үзем барырмын, сиңа бит урыныңнан кузгалырга ярамый, — дидем дә хатны эләктереп өйдән чыгып чаптым. Әмма Мөгаллим абзый өйдә юк иде. Хатны укытмаган килеш әнкәй янына һич кенә кайтасым килмәде. Әткәйнең һәр хәбәрен ничек көтеп алганлыгын белмиммени мин?! Бәлки әле әйбәт хат булса, терелеп тә китәр.

Шул өмет белән ары бәрелеп, бире сугылып йөри торгач, Мирзагыл байларның тимерләп эшләнгән урыс капкалары янына килеп чыктым. Дәүләтҗан исемле бер малайларының әллә нинди гимназия дигән шәһәрдә укып кайтканлыгы колагыма чалынганлыгы бар иде. Капкаларын этеп карадым — бикле. Әмма сигез-тугыз яшьлек малай белән җил үтә алмаган капка бармыни дөньяда?! Башта якында гына үсеп утырган талга, талдан коймага үрмәләдем дә шап итеп ишегалдына сикереп төштем, хәтта бозау хәтле этләре дә абайламый калды. Мин болдырларына барып җиткәч кенә ул «Бу нинди җанлы сөяк?» дигәндәй, күңелен юатыр өчен бер өреп куйды.

Бәхетемә каршы Мирзагыл абзый өйдә юк иде. Юкса ул этләреннән усалрак. Гимнаҗиядән кайткан Дәүләтҗан ябык калҗага караган эт шикелле теләр-теләмәс миңа күз ташлады.

— Йолкыш, ни йомыш? Ха-хаха! Нинди әйбәт рифмалаша икән бу сүзләр, — дип ыржаеп алды ул. Мин курка-курка хатымны суздым.

— Шушыны гына укып бирмәссеңме дигәнием, аб-аб-ый. — Бу утын түмәренә «абый» дип дәшәргә телем бармаса да, йомышым булгач, теш арасыннан ул сүзне этеп чыгарырга туры килде.

Дәүләтҗан хатны җирәнеп кенә кулына алды һәм укый башлады: «Бу хатны мин Петербурдан язам, кадерлеләрем. Менә буржуйларның арка сөякләренә штык кададык, озак тыпырчына алмаслар...» Шушы сүзләрдән соң Дәүләтҗанның иреннәре бүртмәчләнде, маңгаенда кызыллызәңгәрле таплар барлыкка килде. Мин ник кергәнемә үкенеп, дер-дер калтыранып тордым, ләкин борылырга соң иде.

— Кычкырып укы инде, аб-аб... — дидем, — әнигә кайтып сөйлисем бар, ул анда чирләп ята.

Ул минем сүзләремне ишетмәгәндәй һаман мыгырдануында булды. Менә бермәлне юләр кешедәй буылып-буылып көләргә тотынды. Әйтерсең ыштан төбенә кырмыска кергән дә ботларын кытыклап йөри.

— Ха-ха-ха! Кадерле байлык апкайта, имеш. Сезнең ише йолкышларга окоптан алтын тутырып җибәрәләр, ди. Ха-ха-ха!

Аның сүзләреннән мин һични аңламадым, эчен тотып ыржаеп азапланган арада хатны кулыннан тартып алдым да тышка атылдым. Кергәндә

өрмәгән эт, теге чакта мине күрми калуының үчен алырга теләпме, тешләрен кайрап каршылады. Минем ише малайларның иң йомшак җире кайда икәнен белә каһәре, сыйракны авыз итеп тә тормыйча, турыдан-туры шунда ябышты, чалбар төбе белән бер кабымлык итне эт авызында калдырып, урамга чыктым. Тәннең ямавы өстендә, әмма чалбар җәл иде. Канаган җирне кәләпүш белән каплап, әни янына ничек кайтып керергә белмичә, урамда озак йөрдем. Шунда Мөгаллим абзый очрады. Ятьрәк әтинең хатын аңа суздым. Әти, чынлап та ниндидер зур байлык алып, бер айдан кайтачагын яза иде.

— Әни! — дидем сөенечемнән авырткан җиремне дә онытып. — Әти баеп кайта икән! — Хаттаниләр язганлыгын сөйләп бирдем.

— И-и, балам, — диде әни, — үзе исән-сау кайтса, бүтәнен өмет иткән юк инде.

Әти алып кайтачак зур байлыкның ни икәнлеген уйлап, гел баш ватып йөрдем. Иң соңыннан, өстәл хәтле түгәрәк ипидер ул дип, тынычланып яши башладым. Әтинең кайтыр көннәре якынлашкан саен, сабырлыгым бетә барды. Ерактан, станция ягыннан поездларның кычкыртып үткәннәрен ишетеп, йөрәгем җилкенә иде. Хәтта күрсәтелгән көн җиткәч, әнигә:

— Мин станциягә барыйм әле, әни, — дидем. — Теге түгәрәк ипине дә күтәрешеп кайтырмын, әтинең үзенә генә авырдыр.

— Нинди түгәрәк ипи? — диде әни гаҗәпләнеп.

— Соң, әти апкайтачак байлык — киселә дә башламаган ипидер инде ул.

Әни күзләрен сөртеп куйды. Аннан, мине җибәрәсе килмичә:

— Станса бик ерак бит, Сибгат улым, — диде.

— Ерак түгел, җиде чакрым — нәрсә ул, минем тәпиләр Мирзагыл чабышкысына биргесез бит, — дидем.

Әнинең һаман да ризалашасы килмәде. Шулай да мин балавыз сыга башлагач, өс-башларымны алыштырырга кушты. Бәйрәмнәрдә генә кия торган ситсы күлмәгемне һәм әтигә күрсәтергә дип саклап торган сырмамны киеп станциягә киттем. Бу

юл инде миңа бик таныш, әни белән тегенди-мондый вак-төяк сатарга гел шушында килә идек. Йөрәгем ашкынып-ашкынып типте. Тиздән әтине күрү дәрте адымнарымны кызулатты. Тамчы да армыйча станциягә килеп җиттем. Алай бик үк еш булмаса да, поездлар үтә торды. Кайсылары туктады, кайсылары юк. Туктаганы берсе янына барып вагоннан төшүчеләрне күзәттем. Ләкин берсендә дә минем әти күренмәде. Бер вагоннан икенчесенә йөгереп йөри торгач, табаннарым ут яна башлады. Арып, өшеп, вокзалга кереп утырдым. Шунда җылыга изрәп йоклап киткәнмен. Ә уянганда караңгы төшеп килә иде инде. Әни миңа караңгы төшкәнче тормаска кушкан иде бит. Ике-өч чакрым урман юлыннан кайтасы барлыгы исемә төшеп, йөрәгем «жу» иттереп куйды. Станциягә туктамыйча ажгырып үтеп киткән поездга соңгы тапкыр күзләремне мөлдерәтеп карадым да кайтыр юлга чыктым. Курку мине бөтен нәрсәдән дә ныграк чыбыркылады. Күз бәйләнер-бәйләнмәстә урман юлына килеп тә җиттем. Шулвакыт урман юлыннан чаптырып килүче өч атлы күренде. Юлбасарлардыр дип, куак артына постым. Атлылар выжт итеп минем яннан узып киттеләр. Берсе Мирзагыл абзыйның гимнаҗиядән кайткан малае Дәүләтҗан иде.

Ат тоякларының тавышы ераклашкач, яшеренгән урынымнан чыгып, юлымны дәвам иттем. Инде урманны хәвеф-хәтәрсез генә үттем дигәндә, бер агач төбендә кара нәрсә күреп, дөресрәге, ниндидер сизенү белән абайлап алдым. Аякларым ни алга, ни артка атламады. Ул кара нәрсәгә карамаска тырышкан саен, муеным шул якка борылды. Шулвакыт әкрен генә тавышы ишетелде. Кирегә бөкләп чабарга да күп калмаган иде инде, ләкин ниндидер көч бу ниятемнән тыеп калды, үземне-үзем белештермичә аунап яткан нәрсә янына килдем. Ул кеше иде. Өстендә солдат киеме, бите-башы кара кан. Ләкин әле үлеп җитмәгәне күренә. Кызганудан, куркуны онытып, аның канлы йөзенә, чабылып ташланган кул-аякларына текәлдем. Урмандагы караңгылык та, эчкә шом салган ят авазлар да еракка китеп югалды. Ниндидер томан эчендә туракланган солдат белән мин генә калдым. Шунда солдат, нидер әйтергә теләп, иреннәрен кыймылдатты.

— Кем син, абзый кеше? Нигә болай туракладылар? — дип ачынып солдатка карап каттым. Аның күзләрендә сүрән генә очкын кабынды да сүнде. Элек үлгән кешегә карарга курка идем, бу юлы, кара урманда булуга карамастан, курыкмадым. Күңелемдә кызгану хисе, ә үтерүчеләргә нәфрәт иде. Авылга ничек кайтканымны да белмим. Бары тик шунсы гына истә калган: «Урман юлында кеше үтереп ташлаганнар!» — дип урам буенча кычкырып йөрдем. Бөтен авыл кубарылып, солдатны авылга алып кайттылар. Ул минем әти иде. Соңыннан гына белдем, әтине теге Дәүләтҗаннар үтергән икән. Байлыгын эзләгәннәр. Кесәләрендә тәмәке янчыгы белән гәҗит кисәгеннән башка нәрсә тапмагач, ачуларыннан тураклаганнар. Әмма дошманнар ул алып кайткан байлыкның күп укылудан тишелә башлаган газета кисәге икәнлеген белмәгәннәр.

Әйе, чыннан да бик кадерле байлык була ул, оланнар. Анда җирне халыкка бөтенләйгә бушлай бирү хакында язылган була.

Байлыкларның байлыгы, хәзинәләрнең хәзинәсе, бәхетләрнең бәхете ул — Җир. Дөньядагы бөтен матурлык, бөтен байлык, бөтен тереклек җирдән башлана.

ЙОЛДЫЗЛАР ТӨСТӘН ЯЗГАНДА...

РИФӘ РАХМАН,
язучы, шагыйрә, Ф.Хөсни исемендәге премия лауреаты

БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

Ярлылар комитеты башлыгы Шәйдәүләт Тәкәрлеков, теләсә, элегрәк тә Солтанморат Ходайбирдеевтән котыла алган булыр иде. Түзде, алай эшләмәде. Тота-каба дигәндәй, иң баштан алар гаиләсенә килеп ябышмавы кызгану-курку аркасында түгел-түгелен, кеше арасында үзе хакында яман сүз таралудан саклану гына иде. Авылда Аюныкылардан да байлыгы ташыганраклар җитәрлек, комитет членнарының да, нигә иң элек әнә Кәҗә Мәликәсен, Селәүчен Сабирларын раскулачивать итмибез дип, чат ябышулары бар. Вакытын көтеп, җаен белеп кенә башкарсаң, кем сине үз дошманыннан үч алды дип санаячак та, кем сиңа каршы төшәргә батырчылык итәр?!

«Правда» гәҗитендә бик шәп аңлатып язганнар, дошман элементлар партиянең үз эчендә дә җитәрлек, дигәннәр. Әле унсигезенче елда, комитетны оештырырга дип, аны каладан үзе белән алып килгән тәҗрибәле большевик Григорий абыйсы әйткән иде: «Без озакка сузылган эшне башладык, ахыры моның җиңел генә бармаячак, хәзергә урта хәллегә дә, кулакка да таш белән бәрергә ашыкмагыз, халыкны дәррәү каршы да күтәрелүе бар, эш үз җаен алгач, тарафдарлар күбәя ул, менә шулчакта аларның иң үзәгенә балта белән чапкандай бәрербез». Каршы як шул арада кул кушырып утырмаган: бай-байтагае да, чалмасын салып ташлаган мулла-монтагае да ярлы-ябагай арасына җитәрлек узган.

Инде партияне дә, колхозларны да дошманнардан чын-чынлап арындыру эше башлангач, яңаларын, бигрәк тә күзгә күренерлек мал-мөлкәте булганын алу юк та юк инде ул! Камыр Миңнисасы беркөнне керосин лавкасы

** Шушы көннәрдә авторыбыз Рифә Рахман үзенең гомер бәйрәмен — 50 яшен билгеләп үтә. Аны юбилее белән котлыйбыз! Эшендә һәм алдагы тормышында зур уңышлар телибез.*

янында сөйләнеп тора, имеш, байлар арагызга кермәсә, җыен ялкаудан, көн итүнең рәтен белмәүчедән торган күмхуҗыгыз таралып төшәсе бит сезнең, дип. Таралып та төшмибез, байларны да кертмибез! Әйберләрен дә тартып алабыз!

Җирле комитетларның урында уңышлары юк түгел. Алар булмаса, сәвит әллә кайчан, чыннан да, беткән дә булыр иде. Нибарысы ун ел узган, шул арада байлар халыкны талап үз кулларында туплаган 50 миллион гектар җир крестьянга кайтарылган диме?!

Дөрес, гәҗитләрнең язганына ышансаң, хәллерәк кешеләрнең дә соңгы запасларын талау — заман кушкан вакытлы чара гына, тормышлар иркенәеп киткәч, ярлы-хәерче калмагач, аларына яңадан көн киләсе, имеш. Әнә шул көн килгәнчегә кадәр үземнеке итәм-итәм — авылның иң чибәрен кабып йотам дигәндә генә, авызыннан тартып алынган Җанбикә үчен ничек тә кайтарырга, ире Солтанморатны кулаклар исемлегенә кертеп өлгерергә кирәк.

ВКП(б)ның волость комитетыннан килгән хатта ап-ачык күрсәтелгән: иптәш Сталин кулакны сыйныф буларак юк итәргә, яшәү өчен бөтен чыганаклардан мәхрүм калдырырга, хәтта яллы хезмәткә дә алмаска дигән. Партиянең 1925 елда узган XIV съездыннан соң да эченә шом йөгергән иде Шәйдәүләтнең. Яшь, тәҗрибәсез егет дип тормадылар, комсомоллар арасыннан сайлап, аны да съездга җибәрделәр.

Кулакларга йомшаграк мөнәсәбәт таләп иткән кайбер чыгышларны тыңлап утыргач, әллә соң югарыдагылар яңадан хәлле кешене яклыймы, хәерче-гыйбай турында кайгыртуны оныттымы дип, уйлап та куйган иде. Шулай тоелган гына, ахрысы. Съезд артыннан ук комитетка бер-бер артлы җибәрелгән карарларга караганда, чынында андыйларга бөтенләй көн күрсәтәсе түгел. Уң арты уң килеп торган мондый бер вакытта Солтанморатны ничек тә байлар исемлегенә китереп тыгарга кирәк.

Ата — улны, ул — атаны капчык төбендәге ашлык белән бәяләгән заман бу. Казаннан килгән иптәш клубта халык алдында ясаган чыгышында ап-ачык итеп әйтте: кем безнең белән түгел, ул — безгә каршы. 28 нче артиллерия полкының кызылармеецы Воронов исемле берәү әтисенең, соңгы икмәгебезне талап бетерәләр инде дигән, хатына җавапта: «Син миңа әти булсаң да, мин синең кулак җырларының бер генә сүзенә дә ышанмадым. Сиңа яхшы сабак биргәннәренә шатмын», — дигән, имеш. «Менә бу кызылармеец дисәң дә кызылармеец, — диде вәкил, — хәзер аны бөтен илгә үрнәккә куябыз».

Воронов хатының күчермәсен селки-селки, я кайсыгыз шундый ул үстердем дип мактана ала, дип сорагач, Кызыл Аланлылар арасыннан берәү дә күтәрелмәде. Әллә улларының чып-чын коммунизм эшенә бирелгәнлекләренә ышанмыйлар, әллә карт Воронов урынында калырга теләмиләр — бу хәлне үзеңне кеше иткән ата-ананы санга сукмау дип саныйлар иде.

Шәйдәүләт Тәкәрлековкә рәхәт. Аның кулыннан тотып торырлык һичкеме юк. Яхшы гадәтләре дә, яманы да — үзенеке. Григорий абыйсы әйтә: «Без синең белән — киләчәк кешеләре, башкалар артыбыздан иярергә тиеш», — ди. Менә аның сүзенә карасаң гына инде. Анда да әле Шәйдәүләт — аның баласы түгел, партия улы.

Шөгыль тапмаса — шәһәр урамында шар тибеп, ач чагында — базардан кыяр урлап, яз җиткәндә — пристаньда товар ташып үскән малай иде бит Шәйдәүләт. Соңрак чын мәгънәсендә

сәвит кулында тәрбияләнде. Әгәренки дә, большевиклар властька килгәч, клиндерче хатынның кулындагы бауга эленгән сушкиларын кычкыртып тартып алмаса, артыннан өер булып куып килгән базарчылардан качып барганда тотылмаса, Григорий абыйсы кулына килеп кермәсә — кем белә, бәлки, ул да бу көндә сәвитне эчтән таратучы бер элемент, гражданнар сугышында аклар ягыннан торып хәрәкәт иткән солдат булыр иде.

Бәхетенә аны, Григорий абыйсы әйтмешли, революция солдаты эләктергән иде. 1918 елның 17 гыйнварында, балигъ булмаганнар комиссиясенең карары белән, үсмерләр төрмәләргә утыртылмый башлагач, бигрәк азынганнар иде сукбай малай-кызлар. Безгә дөнья нипачум дигәндәй, Шәйдәүләт тә ни теләсә — шуны кыланды. Алай да караклык, хәерчелек, беттән таланып яшәү, күпер асларында, кеше ишеге төпләрендә куну туйдыра башлаган, яше дә бар иде инде Шәйдәүләтнең. Кулынннан гаепле эштә эләктергән солдат аны бу һәлакәтле агымнан тартып алды…

Тыштан бик кырыс, соры киемнән һәм җилкәсенә корал аскан, үзен Григорий Радионов дип таныштырган әлеге адәм начар кеше түгел иде, ахрысы. Ул чакта аның кем икәнлеген Шәйдәүләт аңлап та бетермәгән иде. Наркомат комиссияләренең утырышыннан да Григорий абыйсы аны үзе җитәкләп чыкты, өенә алып кайтты, чистартты, юындырды. Иске, әмма әле таза киемнәрен, җиңнәрен-балакларын сызгандыртып, Шәйдәүләткә кидерде, аннан, хәзер аңлавынча, кулындагы комиссия карарын тотып, Социаль тәэминат наркоматы күзәтүендәге балалар йортына илтеп тапшырды. Ятимнәрдән мыңгып торган йорт, борынгы монастырь булып, керәшен Гөргөри абыйсы өчен электән таныш иде. Әтисез-әнисез, йортсыз-җирсез калгач, кайчандыр ул үзе дә монастырьга килеп егылган булып чыкты.

Бер елдан коммунада яшәвеннән, олы ерткычларыннан да яшь, әмма имансыз-миһербансыз җинаятьчеләреннән дә туеп, иң яхшысы моннан качып котылу дип торганда, Григорий-Гөргөри абыйсы аны яңадан эзләп тапты. Күзәтүчесез калганнарны тәрбияләү йортлары Халык мәгарифе комитеты идарәчелегенә тапшырылган икән дә аларны, яшь буенча аерып, колонияләргә, хезмәт коммуналарына тараталар, имеш.

Егерменче елгы ачлыктан хезмәт колониясенә китеп котылуына соңыннан егет үзе дә сөенеп бетә алмады. 1921 елны Идел буеннан Балалар комиссияләре ярдәме белән башка районнарга сөрелгән 150 мең ятим арасына Шәйдәүләт тә килеп эләккән иде. Дөрес, ул чит төбәктә дә озакка калмады, Григорий абыйсы аны бөтенләй онытып бетермәгән булып чыкты: бер елдан артык та узмады — 1922 елның кышында Наркомпросcның балаларны хокукый яклау бүлеге аркылы кире Казанга — ФЗУга — фабрика-завод училищесына чакырттырып алдырды.

Казанның сазлыклар эчендә утырган бер почмагында иде әлеге уку йорты. 1830 елны ук кантонистлар (туу белән хәрби идарәдә саналган һәм кече хәрби мәктәптә укыган түбән хәрбиләрнең балигъ булмаган уллары) Бөек Ватан сугышыннан соң илне баскан тулы ятимнәр өчен ачылган әлеге училище эшчеләрнең хәрби пунктын булдыруны күздә тоткан булса да, соңрак казна дары заводының техник училищесына әйләндерелә. Григорий абыйсының сөйләвенә караганда, 1922 елның 7 ноябрендә, Октябрьнең 5 еллыгы уңаеннан, аның зданиесендә Татарстанда беренче булган фабрика-завод өйрәнчеклек мәктәбе ачканнар икән. Инде ул менә аның юлламасы белән шунда килеп эләкте.

Шәйдәүләт, училищеның икенче елын тәмамлап килгәндә, Партия комитеты Григорий абыйсын Кызыл Алан авылына коммуна төзү эшенә юллаган булып чыкты. Рөхсәт алып, үзенә ярдәмгә ул Шәйдәүләтне дә ияртте. Бу вакытка аңа инде унтугыз яшь тулып өлгергән иде.

Григорий Радионов — монастырьда яшәгәндә урыслашып бетә язган керәшен булуына карамастан, ниндидер бер татар малаен ни өчен яратты микән, дип уйлый иде Шәйдәүләт, сораштыра торгач, хатыны кире мөселманлыкка кайткан керәшен кызы булып, бала тапканда үлгән һәм шуннан бирле аның бервакытта да өйләнмәгән икәнлеген ачыклады. Большевиклар, ятимнәр бары коммуналарда тәрбияләнергә тиеш дип уйлаганга, Гөргөри дәдәе башта Шәйдәүләтне уллыкка ала алмаган икән. Инде андыйларга якын күргән кешеләреңдә, туган-тумачаңда яшәргә рөхсәт ителгәндә Шәйдәүләт балалыкүсмерлек яшеннән чыгып та өлгергән.

Казан кадәр Казаннан җибәрелгән вәкилнең я кайсыгыз шундый ул үстердем, дип мактана ала, дигән сүзләренә баштарак Шәйдәүләт тә аптырабрак калган иде, чүт кенә каршы төшмәде, аннан үзен кулга алды — башкалар кебек аңсызлык күрсәтә торган вакытмыни? Әтисе исән булса, бай яшәсә, бәлки, үзе дә аңа хатны нәкъ шулай язган булыр иде, дип уйлады. Әгәр Григорий Владимирович ихластан шулай кирәк дип саный икән, димәк, ул Шәйдәүләтнең дә Воронов кебек революция юлында туп-туры барган, йомшаклыкларга бирелмәгән чын Ватан улы булуын көтә!

Иптәш Сталин дөрес әйтә: кулакны сыйныф буларак бетерми торып, илдә колхозларның өскә чыгасы, ярлы-ябагайның шуларда рәхәт көн итәсенә ышанасы юк. Без күмәкләп яшәү җиңелрәк дип торганда, алар һаман да иген уңышын да мулданрак ала, башкасын да күбрәк җитештерә.

Авыл советының диварына «Һәр крестьянкага — бер сыер» дигән плакат элеп киткәннәр. Солтанморат кебекләрнең икенче сыерын я инде берьюлы икесен дә тартып алмый, үзен Себергә сөрми торып, ничек һәр кешене ел эчендә сыерлы итеп бетерәсең?! Политбюроның утызынчы елгы карарын да янына зурдан яздырып элдертте Шәйдәүләт. Кулакларның өч төркеме турында игълланны һәр комитет члены бисмилла урынына ятлап бетерсен, диде. Тик менә әлеге төркемнең икенчесенә, авыл җирләрендә оешып яткан контрреволюция активына Солтанморатны гына ничек кертергә икәнлеген белми иде. Аннан җае чыкты. Тавыгыбыз яшеренеп йомырка салмыймы дип шикләнеп, күрше печәнлегенә менгән Райнур — комитетчы Әптәни малае печән астына качырылган иске сандыкта капчыгы белән ашлык күреп төшкән. Ул — әнисенә, әнисе әтисенә җиткерсә, әтисе инде комитетка килеп сөйләгән: «Малай булып малай табарлык урында ашлык качырып яткыралар, башка бер урында аннан да күбрәге булмасмы? Сабанда чәчәргә җитмәде, кеше көнен көнгә ничек ялгарга белми, болар авыз тутырып ипи ашый», — диде.

Асылда Солтанморатның, киләчәкне белмәссең, бар булганны тартып алып бетерделәр диярлек, инде монысы кара көнгә дип алдан ук кеше күзеннән яшереп куйган ашлыгы контреоволюция гамәленә бик туры килә кебек иде. Комитеттагы кайбер иптәшләр: «Нинди актив булсын инде ул, нәрсәдер оештырып йөрергә аның вакыты да юк: ялны белми эшли, язкөз кырдан кайтып керми, җәй буе бакчасында казына, итек баса, болында юкә кабыгы төшерә, — дисә дә, сүзне артыкка суздырмады. — Хәзер булмаса, эшләр болайга киткәч, кай-

чан да бер ата дошманыбызга барыбер әйләнер иде», — диде дә түгәрәкләде.

Теләсәләр дә, теләмәсәләр дә, комитетчылар, башкаларны астыртын эшләрдән кисәтү йөзеннән, әтисе Хәмидулла карт белән бергә Солтанморатны контрреволюционерлар исемлегенә кертергә, авылдан үзәккә илтеп тапшырырга дигән карарга кул күтәрде. Концлагерьга сөрерләрме, башка бер җәзасын табарлармы — анысын югарыдагылар үзләре дә бик яхшы белерләр. Бу айга җибәрелгән разнарядка шулай итеп тулысынча үтәлде, кулакларның һәр ишесеннән кем дә булса табылып, районга хисап та хәзерләнеп куелды. Инде бөтен эшләрне аның кулына гына тапшырып, Казанга китеп барган Григорий абыйсының Шәйдәүләттән канәгать каласына шик юк иде.

Авыл зур булмагач, кемне раскулачивать итәргә дә белмәссең, дип көрсенде Галиәхмәт, эшләр болайга барса, гел өстән язу төшеп торса, чират үзебезгә дә җитмәгәе... Сүзен куәтләп кушылучы табылмады, барысына да инде эшләнәсе эшләр тәмамланып килә, менә-менә колхозлар төзелеп бетәр дә, бар кеше бай, кулаксыз-байсыз рәхәт тормышта яшәп китәр кебек тоела иде. Алар да чиратка эләксә, күмхуҗ дигәннәрендә кем калыр соң?!

Соңгы вакытта Кызыл Аланлыларны кулакларның беренче төркемен таптырып артык изаламый башладылар: байларның зуры, кибетләр тотканы колхозлашуның беренче елында ук атылып-куылып беткән, байлыклары тартып алынып, исемлек буенча чын хәерче дигәннәргә, канкоешта башлап йөрүчеләргә өләшенгән иде. Шәйдәүләткә ни хезмәтче тотмаган, ни көнлекче чакырмаган Ходайбирдиевләрне күрәләтә алпавыт, сәүдәгәр, мулла кебекләр исемлегенә кертү мөмкин бер эш булып тоелмады, алай да ул аннан ахыр чиктә үзе күрергә теләгән контрреволюционерны барыбер ясады.

Солтанморат авылдан китсә, Җанбикәсе үз аягы белән аның кочагына килеп керәчәк кебек иде. Хәер, инде аның ике баласын баккан карт хатын Шәйдәүләткә чынында кирәк иде микән?! Инде кайчандыр гүзәл Җанбикә-сылукайга булган мәхәббәте дә бөтенләй сүрелгән, мин-минлеген таптап узучылардан үч алу теләге генә күңеленнән китмәгән иде.

Ходайбирденекеләргә комитетта булган хәлләр көне-сәгате белән килеп җитте. Галиәхмәт әле төшлектә тамак ялгарга дип кайткач, хатынына гомеремдә беренче тапкыр, сер итеп әйтәм, тишә күрмә, иртә таңнан Солтанморатларны алып китәргә үзәктән киләселәр, дип әйткән иде, Гаделниса — Хашиягә, Хашия шул арада энәсеннән җебенә кадәр Солтанморат хатыны Җанбикәгә җиткерде. Анысы инде каенатасына түгел, ире Солтанморатка да көч-хәл белән генә әйтә алды. Әйтүен дә әйтте, хәлсезләнеп, басып торган җиренә барып та төште. Алай да әллә ни куркырлык булмады, йөзенә су гына бөркеделәр дә карватка илтеп яткырдылар.

Җанбикәнең кулында — биш айлык имчәк Гөлхәбирәсе, янында — кая барса, итәгенә тагылырга гына торган алты яшьлек Хуҗиәхмәте бар иде. Әтиләрен Себергә сөрсәләр, нишләрбез? Кәмитит мордарларының кулыннан иртәгә үк гомере киселә калса, бу ике сабый кемгә кала да, кемнең җилкәсенә таянасың?! Каенанасының да үз хәле хәл: ике көннең берендә урыннан тора алмый ята. Шул уйлар аны тәмам аяктан еккан иде.

Солтанморат белән Хәмидулла агайны таң атып беткәнчегә дә калдырмадылар. Кояш каршы як таулары өстеннән күтәрелер-күтәрелмәстә, капка төпләренә җигүле атлар ки-

леп туктады. Солтанморат капканы кичтән бикләмичә үк яткан иде. Хатынына: «Белмәссең, ачудан ватып ук кererләр, аннан аларны төзәтергә сиңа кала бит», — дигән булды. Чолан ишеген каккан тавышка уянган Җанбикәнең кичтән янәшәдәге караватка — улы Хуҗиәхмәт янына яткан Солтанморат юклыгыннан эче жу итте. Эчке киемнән генә икәнлеген уйлап та тормастан, түр якка — каенаталары йоклый торган бүлмәгә атылды:

— Әткәй, син кайда?

Киче дә кич булдымыни аның?! Җанбикә авыр уйлардан тиз генә оеп китә алмыйча тилмерде, таңга таба урын килешми мәллә, диештереп, сабые белән икенче караватка күченде, Солтанморат янәшәсенә Хуҗиәхмәтне яткырды. Керфек какмыйча, шомланып, еламсырап ята торгач, барыбер үзенекен алган — таң ката йокыга талган иде. Ул әткәсе белән ире Солтанморатның, урамнарда кеше аягы тынгач, кеше ни әйтмәс, хатынкыз сүзе генә булуы да бар, алдан кайгырмыйбызмы икән, дисәләр дә, өйдәгеләр тынычланып, хатыны йокыга да киткән кебек булгач, бакча артыннан гына, ат җигеп, үзләренең кая таба юл тотканнарын да чын-чынлап ачыклап бетермәгән килеш, авылдан чыгып качуларыннан хәбәрсез иде.

— Тсс, син дә, мин дә белмибез, йоклаган идек, — дип әйтербез, — диде, караватыннан төшеп, өстенә җилән киеп, чыгып ишек ачарга әзерләнеп торучы Гөләфтар карчык. — Аларның юклыгына кайгырма, килен, исән икәнлекләренә сөен!

Җанбикә дәшмәде, чөнки ни дияргә дә белмәде. Әнкәсенә ияреп, ишектән кулга алучылар килеп кергәнче, өсбашын да алмаштырмый, кымшанмый катып торуында булды. Кулга алынырга тиешлеләрнең юкка чыгуыннан ул районнан килүчеләргә караганда да аптыраганрак иде. Алар артыннан, сөйләнә-сөйләнә, ишектә Шәйдәүләт үзе күренде:

— Нәрсә, контрреволюционерлар төнлә дә йокламый, сәвит белән көрәшәмени, алайса сезне кулаклар исемлегенә кертеп бер дә ялгышмаганбыз икән. Менә бит ирләрегезнең һәркаюсы кыңгыр юлда.

Шәйдәүләткә районнан килүчеләрнең тиз генә борылып ишегалдына чыкканы өйдәге хәлләрне җиткергән иде булса кирәк.

— Хуш. Ярый. Минем белән санлашмасагыз, әнә үзегез белән районныкылар башкачарак сөйләшер, — дигән булды ул. — Безгә аермасы юк: бар байлык сезгә калган икән, инде сез җавап бирәсез булып чыга. Хуҗиәхмәтеңне уят та, киендереп-киенеп, кесәңә сәвит рөхсәт иткән 500 тәңкәңне тыгып, арбага чыгып утыр. Минем үземә барыбер: ике кеше югалган икән, алар урынына икегезне алабыз да — безгә кушылганы бетә!

Шәйдәүләт бик яхшы белә: Солтанморат белән Хәмидулла абзасының эше «расстрел» белән тәмамланса, бу икәвесен генә түгел, башкаларын да барыбер моннан күренми торган якларга акыртып сөрәселәр. Беркатлы Солтанморат, исән дә калам, хатын белән балаларны да яман исемемнән коткарам, дип уйлагандыр инде... Юлларның мең төрлесен Шәйдәүләт абзыкаең әллә кайчан, аннан да алдарак эзләп табып, әллә ничә төрле рәвештә сайлаган!

Чыннан да, ярыйсы гына яшәгән икән Солтанморат! Өстәлләрендә бер дигән, шомартып, ялтыратып куелган самавыр утыра. Почмак тирәсенәрәк ишекләре уеп ясалган шкаф терәтелгән. Утырганнары да кәкре каеннан эптәрләгән сәке түгел, аркалы урындык булган икән! Гөләфтар карчык эшләр болайга китәр дип һич уйламаган иде, чарыйлап елап, баядан бирле өйне күзәтеп тор-

ган Шәйдәүләтнең мылтыклы кулына килеп ябышты:

— Ат, суй! Себергә сөр! Төрмәгә утырт! Менә мине! Миңа барыбер үләсе! Киленгә генә тимә! Кулымда сабый баласы кала! Исән-имин үстерә алырмынмы, иртәгә-бүген дип кабер якасында торган карчык бит мин! Киленне кызганмасаң, улы Хуҗиәхмәтне уйлар идең. Синең дә инде мүкәләп йөргән малаең бар бит.

Әйе, бар иде. Андый малайны, итәгенә салып, Җанбикә алып кайтасы иде Шәйдәүләткә, үзе яратмаган, әче телле Нурисламия түгел! Шәйдәүләт дәшмәде. Мылтыгын мич авызына терәде дә өстәл янына килеп утырды:

— Чәй яса әле, салкын булса да, Гөләфтар апа!

Карчык комитет кисәгенең оятсызлыгына, имансызлыгына таң калды, әмма буйсынды. Күңеле йомшамасмы, влач Шәйдәүләтләр ягында, теләсәң дә, битенә төкерә алмыйсың дип, ташаякларның матуррагын, ватылмаганрагын сайлап алды да самавыр борынына үрелде.

Чәй эчеп торырлык вакыт идемени?! Шәйдәүләт ахырдан үзе дә нинди мәгънәсезлек эшләгәнлеген аңлады. Бу карчыкка ачуы булмаса да, килене Җанбикәгә саклаганы гөберле бака кебек бугазына утырган һәм төкерек тә йотмаслык хәлгә китергән иде. Гөләфтар түтәе ясаган салкын чәйне эчкәндә дә ул үпкә төерләрен йотып җибәрә алмады — ачуы тагын да яңара гына төште. Гөләфтар карчыкның чәй ясаганда дерелдәгән кулларын күргәч, иманы уянасы урынга бугаз төбеннән котырыгы килгән шикелле, ә менә Җанбикәләрне эчертмә, алар хәзер кәҗүнни йортта гына ашаячак, дип ихахайлап көлеп үк җибәрде.

Җанбикә Шәйдәүләт күрсәткән кыланмышларның, ясалма ихахаймихахайларның, үзләрен җиңү сөенече булмыйча, юләрләнә башлаган адәмнең гаҗизлектән башын ташка бәрүе белән бер икәнен аңлады. Ыграк аңлый барган саен, горурлыгы, ныклыгы да арта төште.

Хатын тизрәк Шәйдәүләттән котылу, бу мәхшәрләрне дәвам итмәс өчен, чәй эчү түгел, киенеп тә тормаска риза. Җиңә алмый иде аны кайчандыр кочакка ала алмыйча тилмергән бу имансызның Себергә сөрүе дә, төрмәгә олактыруы да, ирсез-җирсез калдыруы да... Сер бирмәсә дә, күренеп тора бит: Шәйдәүләтнең соңгы өметләре җимерелүдән, Җанбикәнең ялварып, ялынып аягына егылмавыннан йөрәгенә, күзләренә кан савып килә...

Кулга алучыларга ияреп, кулакларны юкка чыгару тамашасына Галиәхмәт тә килгән иде. Дөресрәге, үзләре белән барырга аңа Шәйдәүләт кушты. Мондый җирләрдән ераграк торуың яхшырак булса да, берни кыла алмыйсың. Колхозны төзи башлаганда, эшләр болайга китәр дип белсәме... Аягына кияргә тишек оегы юк килеш тә комитет дигәннәренә сайланмаган, коммуналарына да беренчеләрдән үк кермәгән булыр иде.

Галиәхмәтнең чын ачуы Солтанморат кебекләргә идемени соң?! Ул бар яшәгән гомерендә урыс алпавытына хезмәт итте: аның абзарында мал карады, аның көтүен көтте, аның вактөяк йомышына йөгерде. Ул байның сыер-сарыклары белән таш абзар почмагының күтәртмәсендә ятып йоклады, этләреннән калганын гына ашады дигәндәй... Ачуы да әлеге дә баягы Степан Ивановичка иде. Шуңа күрә генә Галиәхмәт, алпавыт байлыклары ярлыларга таратылганда, рәхәтләнеп аның үз авылларындагы кибет йортына күченде. Ул моның өчен оялмады да, үкенмәде дә, моны дөрес түгел бер эш дип санамады да. Галиәхмәткә яшәргә урын булса да бик җиткән иде. Башкалар алпавыт байлыгын сугышаталаша бүлешкәндә дә, ул бер читтән

генә карап торды. Бүтәннәр типкәләп кенә калдырган иске-москыга да кагылмады.

Галиәхмәтнең тормышы, бер карасаң, хәзер байларныкыннан ким идемени?! Ташпулат йорты бар. Йорт артында киртә белән әйләндереп алган бакчасы. Кибет киштәләреннән өстәл-сәке ясап куйды. Савыт-сабасы, кашагасы-пәрдәсе дигәндәй, хатыны Гаделниса белән ияреп килде. Ул атаанасына бер кыз иде. Бераздан алары да Галиәхмәт йортына күченделәр. Инде бөтен җирләре тиеште. Комитет байлардан тартып алган сыерларның берсен җәен бабасы Сәгыйдулла белән күтәргән бурага да кертеп утырткач, күңеле күкләргә тиде.

—Түбәне тактадан ук ябарбыз, — диде Сәгыйдулла,—безнең йортныкына әле бернәрсә булмаган, шуннан гына сүтеп алырбыз.

—Ашыкмыйк әле,—дип каршы төште аңа Галиәхмәт,—гаилә булгач, тора-бара бала-чагасы да ишәер. Башка чыгарам дисәң — бер дигән нигез бит.Сезнең өстегездә торгач, бакчасына утыртырсың, анысы да янда гына булыр.

Әле байда торганда, тамак туйганчы бер ашасам дип хыялланган Галиәхмәт йортка-җиргә тиенгәч, күңеленә тагын да рәхәтрәк яшәү уе кереп оялый башлаганын тойды. Тоймаса, туплаңган байлыкларның кайберәүләрне тимер рәшәткә артына кертеп утыртуын күрмәсә, кем белә, ул тормышын тагын да яхшыртам дип җан-фәрман тырышкан, кеше малына кулын да ныграк сузган булыр иде. Ә болай... күңеленә беррәттән киләчәкне шомланып көтү уе кереп оялады, тегеңә кайчан килә, безгә — кайчан, һәрчак шулай булырмы кебегрәк уйлар эчен таракан кебек кимерә башлады.

Эчтәге ике минне үзара килештерү бик җиңелләрдән түгел иде, шуңа күрә Галиәхмәт комитетта артык активлык күрсәтүдән дә сакланды, көндәлек тормышында да кирәгенчәрәк кенә яшәргә тырышты, әмма һәрвакытта да ул дигәнчә генә килеп чыкмый иде. Бер яктан, күңелен кеше рәтенә керүдән рәхәтлек хисе биләде, икенче яктан, дөньяның куласа икәнлеген белү уе җәрәхәтләде: властьта бүген — Әхмәтша, иртәгә яңадан патшаларның булуы бик ихтимал. Азмы-күпме иман нуры да калган, большевиклар кылган гамәлләрнең кешене кеше ашавы дип тә аңлый иде Галиәхмәт. Я син — аларны, я алар — сине... Шулай булгач, ярлылар комитетына керүнең файдасы бар да бар инде. Әле менә алар патшаны бәреп төшермәсә, Галиәхмәт һаман да шул Степан Ивановичның мал ызбасында ятасы түгел идемени?!

Уйлый башласаң, бу уйларның очына чыга алмассың. Алай карыйсың — алай дөрес, болай карыйсың — болай тугрырак шикелле. Большевикларның, ары таба да ныгып китеп, дошман тарафларыннан котылгач, үз эшләренә тотыну ихтималы да юк түгел... Я, нинди контр булсын инде Солтанморат?! Кеше малын талап җыйганмы? Зур җире бармы? Хезмәтче тотамы? Халыкны большевикка, сәвиткә каршы котыртып йөргәнме?

Чиратның, чыннан да, үзенә дә җитүе бар шикелле... Бабасы каралтысыннан да, агач түбәле абзарларыңнан да баш тартуың хәерлерәк. Моңа кадәр купец өендә яшәмәгән. Сыер сыер инде ул, аңа кабыклы түбә ни дә, такталы ни, өстенә яңгыр-кар явып тормагач. Галиәхмәт башкача уйлаганда да, бигрәк тә хатыны белән чәйләп утырганда, шулай дип сөйләргә тырышты. Ул, бабасына каршы килеп ни дә булса әйткәндә, иң элек шул сүзгә үзен ышандырырга тырыша иде шикелле.

Хатыны Гаделниса Аюныкыларга

чыбык очы тиешле кеше булганга, Галиәхмәт шундый авыр бер вакытта, янына барып, җиңгәсен юатырга теләсә дә, базмады, махорка төрә башлаганны сылтау итеп, ишегалдына чыгып китте. Чоланда, инде ялгызы калгач, беркемнең дә ишетмәсен белгәч кенә, анда да теш арасыннан, иртәгә чират безгә дә җитмәгәе, дип мыгырданды. Мыгырданды, әмма әлеге дә баягы махорканы көйрәтеп баскыч төбендә торганда, әйткәнемне ишетмәгән булсалар гына ярарые дип уйлады, көн дә телгә килә хәерсез нәмәрсә, нинди эчпошыргыч уй булды соң әле?..

Кичтән генә ирен алып китәселәрен ишеткәннән дә хәлсезләнеп егылган Җанбикәгә әллә көч кереп киткән иде?! Гөләфтар карчык ни уйларга да белмәде. Әле килененең яшь чагында, чибәрлеге-уңганлыгы белән бөтен авылга дан тотканда, артыннан йөрүчеләр арасында Сәвит Шәйдәүләтнең, килмешәк Тәкәрлекнең дә булганын ишеткәне бар, малае белән ызгышып-сугышып йөргәнен дә хәтерли, әмма хәни заманнардагы хәлләр өчен Кызыл Алан коммунасының башлыгы бу кадәр үч тотадыр дип башына да китерми иде. Гөләфтар карчык улы белән картына дип кичтән әзерләгән төенчекләрен мич артыннан гына тартып чыгарды да килененә сузды:

— Юлда булса да капкалап алырсыз. Кечкенә генә шешә белән су да тыктым.

Шәйдәүләт шунда эшнең нәрсәдә икәнлеген сизде. Кеше тиктомалдан юл хәстәрен күреп куймый бит инде. Серне кемдер тишкән, үз араларындагы контрреволюцион бер элемент, һичшиксез, тишкән иде. Нәрсә булса булган, инде тавыштан котыласы юк, монда Солтанморат белән Хәмидулла урынына Җанбикә белән малаен җибәрүдән башка чара да табарлык түгел дип уйлады ул эченнән, минем кочакта төн чыгасың килмәгәч, этап белән чыгарсың... Ә аннан... арабыздагы контрларга да нәүбәт җитәр...

Җанбикә, йокы бүлмәсенә кереп, Хуҗиәхмәт йоклаган сәке янына килде. Малай әллә кайчан уянган, әллә йокыга да китмәгән иде инде?! Димәк, ул белгән, әтисе аңа әйткән, дип уйлады Җанбикә. Ана кеше җылы урынында соңгы тапкыр төн кунган бәгырь кисәгенә йомшак кына дәште:

— Балакаем, иртә булса да тор инде, китәсебез бар. Киен, яме. Улым, җылырак киен! Барыр юллар бик озак булмагае...

— Мин әзер инде!

Хуҗиәхмәт караватыннан сикереп төшкәндә, Җанбикә аның өске киемнәрдән икәнлегенә игътибар итте. Малай, әнисен тартып китерде дә, икенче яктагыларга ишетелмәслек итеп:

— Әтине озатканда киенгәннән чишенеп тә тормадым, — диде.

Рөхсәт ителгән акчадан артыгы юк та иде. Җанбикә аны, кулъяулыкка төреп, куен кесәсенә тыкты, төенчеккә ризык төйнәп, җылырак киемнәренә төренеп, калын шәл ябынгач, малаен җитәкләп кече якка — аш өстәлле бүлмәгә чыкты. Кулга алучылар урыннарыннан кымшанмыйча көтә иделәр. Җанбикә шкаф янында боегып торган каенанасына карады, аннан елмаю катыш бер кыяфәт чыгарып:

— Җыенып беттек бугай, әнкәй. Солтанморат белән әткәй табылса, әйт, минем өчен борчылмасыннар, ничек тә исән кайтырбыз. Бер гаепсезгә алып китүләрен белсәләр, Казанда безне бер көн дә тотмаслар. Һәр җирдә мондагылар кебек начар кешеләр утырмый бит инде. Сәвит безнең кебек гади кеше өчен ул, — дигән булды.

Әле яз, төннәрен, бигрәк тә таңда шактый салкын иде. Чыгып утырдылар. Күрше-күлән күренмәде. Кеше йөргәнгә этләр өргәне ишетелгән иде, алай да чыкмаганнар... Аларның да

яшисе, бу авылда ничек тә көн итеп каласы бар шул…

Җанбикә китте. Шәйдәүләт күрше малае хәбәр иткән сандыкны алып төшәргә дип печәнлеккә юнәлде. Бүген эшләгән эшләремә бер дә үкенерлек түгел, нык тормышлы Солтанморат, дип уйлады ул кабат, сайгак баскычлардан менгәндә. — Каралты-курасы да төзек, йорты да зур. Ачлы-туклы яшәсә, хатыны тутырган тавык кебек булмас иде, әнә бит, бит очларына кадәр янып тора, шул яшьтә, ике бала анасы булгач… Абзарында санарлык малы — сыеры-аты бар икән… кулак инде, кулак!

Шул урында аның малларны — байлыкны исәпкә алырга кирәклеге күңеленә килде. Баштан ук эшлисе иде аны, баштан ук! Алдан ук кертәсе иде Шәйдәүләтне кулаклар исемлегенә. Ике аты булган кеше кулак булмый кем булсын?! Суд ясый-нитә калсалар, Җанбикә, без кулак түгел, дип сүзендә нык торса, күрше малаеның яшергән ашлыкны күрүен дә танымаса, шул язып алынган әйберләрнең исемлеге белән борыннарына гына төртәсе бит!

Шәйдәүләт менеп җитмәде, кире төште. Атлар ябылган яңа абзар ишекләрен, якты керсенгә, киң каерып ачты да эчкә узды. Арата артында ат булса, иелеп керүчегә башын сузар иде… Алардан җилләр искән, ахрысы… Аңлашылды, дип уйлады Шәйдәүләт, кем беләндер сөйләшкән шикелле, аңлашылды, чыгып сызганнар икән болар. Сызганнар… Юртакларында гына… Кайтырлар, ерак китә алмаслар… Китсәләр-китмәсәләр, Шәйдәүләт хәсрәте түгел. Документ буенча барыбер бер эләгерләр. Анысына инде башкалар бәя бирер…

Шәйдәүләт, ике баскычны бер итеп дигәндәй, кире печәнлеккә менеп китте. Шактый караңгы иде. Ай кебек кенә уйган тәрәзәдән кояш нуры төшми диярлек, бөтен җирдә кыштан ашатылып бетми калган печән. Алар аркылы ни дә булса күренерлек түгел. Мылтык очы белән анда актарынды Шәйдәүләт, монда — сандык та, аның эчендәге ашлык та табылмады. Ярар, анысын иртәгә таптырырбыз, башта малайның үзе белән эзләрбез, сөйләшербез дип, аргы очка — комитет йортына юнәлде. Ашлыкны Солтанморат белән Хәмидулла урманга, үзләре белгән бер урынга яшергәннәр, бу хакта чыгып киткәндә Хуҗиәхмәтнең колагына гына: «Бик килеп терәлсәгез, фәлән-фәлән җирдән табарсыз», — дип әйтеп өлгергәннәр иде.

Малай ул төшне белә. Әле җәен печәнлектә малларга ризык әзерләгәндә, куе урман эчендә әтисенә үзе үк табып биргән иде аны. Эре-эре ташлар белән әйләндереп җир астына инде күптән эшләнгән чокырга шаярып-уйнап йөргәндә үзе дә сизмәстән төшеп китте ул. Чокырга яхшы итеп коры-сары түшәлгән булган, ахрысы, әмма ачык калдырылган урыннан язгы сулар төшепме чергән иде. Әтисе белән чокырны тазарттылар, мүкләнгән, урыныннан купкан яссы ташы белән авызын яптылар да, корысары белән каплап куйдылар.

— Бу хакта беркемгә әйтәсе булма, — диде Солтанморат.— Белмәссең, кирәге чыгуы да бар. Хуҗасы күптән килмәгәнгә, ташлап калдырганга охшаган…

Шулай булып чыкты да…

Алты яшь авылда кечкенә яшь түгел инде ул. Хуҗиәхмәт тә — әллә кайчан кул арасына кергән бала. Җанбикәнең ярдәмчесе, әтисенең дә өмете. Су китерәсе булса да, мич тергезергә дә, мал астын җыештырырга да Хуҗиәхмәт кирәк. Аңа уен эләкми диярлек.

Балалык яшеннән дә чыкмаган Хуҗиәхмәт бер безгә генә кирәк түгел

икән, менә бит, алырга дип ат җигеп килгәннәр, дип авыз кыйшайтты Җанбикә, арбага утыргач, башын артта торган Шәйдәүләткә горур ташлаган булып:

— Әйдә, элдерттек төрмәгезгә! — дип кычкырды.

Кискен күренгән кебек кыланса да, күңеленең бик йомшаган чагы иде хатынның. Үзе белән яткан караватта иренен чупылдатып Гөлхәбирәсе кала. Бот буе Хуҗиәхмәте бер карусыз кәҗүнни йортка китеп бара...

Җанбикә, җыясы җыелгач, киясе киелгәч, исәплисен исәпләп, хушлашып чыгып барганда, ишек кырындагы чаршау белән каплап куелган элгечлек янында тагын бер кат тукталды. Чүпрәк аркылы гына киемнәрне барлап карагандай итте. Аның бу хәрәкәте Солтанморат белән каенатасының көртә-мазарын барлап карауга охшаган иде. Алар гадәттә эленеп торган элгечләр, чыннан да, буш иде. Димәк, әйләнеп кайту — планнарында түгел. Димәк, абзар-кура тирәсеннән генә эзләүнең, дәшеп карауның мәгънәсе юк...

Хуҗиәхмәт тә этине озатканда, ди бит...

Бу югалту чын-чынлап хатынның башына нәкъ шушы минутта барып җитте. Ул йөрәгенә китереп бәргән ачы хәсрәткә түзмәде, башыннан ишелеп төшкән яулыгын-шәлен салып селтәнде дә шуларга йөзен каплап елап ук җибәрде. Бераздан тынды. Яшьләрен сөртте. Чыкты. Нәрсә өчендер гаепле, кыенсынган кебек кенә, каенанасына күтәрелеп карады:

— Бәхил бул инде, әнкәй. Кызымны карап үстерә күр. Инде бөтен өмет синдә. Көрешсәк тә, көрешмәсәк тә — Хода кулында. Җай чыкса, бер-бер хәбәр җиткерермен. Гөлхәбирәгә сөтне савып тәрәзә төбендә калдырдым. Уятсам, имезсәм, аерылып китә алмам шикелле. Шушы тавышка да уянмасын әле, и сабый! Биш айлык имчәк тә дип тормадылар би-и-т!

— Артык күп бызгылдыйсың, — диде аңа каршы Шәйдәүләт. — Без сезне качкыннар урынына гына алабыз, югыйсә кызыңны да үзең белән этаптан этапка йөрттерергә булыр иде. Үзең беләсең, Камали байның хатынын гына түгел, улын да, киленен дә, имчәк кызларын да алып киттеләр. Карт этләрне аткач, калганнарын Себергә сөргәннәр. Бергә булсаң, ансына да сөенер идең кебек, күреп торам. Әмма монда шатланырлык нәрсә бар микән?! Шәйдәүләт абзыкаеңа рәхмәтле буласы урынга! Бер яшькә җиткәч, кызларын, тартып алып, наркомздрав яслесенә тапшырганнар. Син дә шуны телисеңме?! Бик теләсәң, булдырабыз без аны!

Кулга алучылар арасында НКВД хезмәткәре дә бар иде. Хатын:

— Күп сөйләнмәгез, Шәйдәүләт Рухуллович, балалар язмышын Сез хәл итмисез, менә без хәл итәбез. Алай да ярый килгәнмен икән, сизгән кебек булды бу. Хуҗиәхмәт минем белән төркемләү-тарату пунктына китәр, туу таныкнамәләрен хәзер үк кулыма тапшырыгыз, — диде.

Шәйдәүләт үзе дә Җанбикәдән тартып алган кәгазьләрне контр элементларның балалары белән эшләү өчен НКВД тарафыннан махсус җибәрелгән хатынның кулына китереп төртте:

— Менә бит! Сезгә бирергә дип кулымда тотып торам. Икесенеке дә — шушында. Кайсын кая тапшырасын үзегез беләсез.

Хатын дәшмәде. Хуҗиәхмәтнекеләрне аерып алды да калганын Җанбикәнең үзенә тоттырды.

Әйе, әле яз, таңда шактый салкын иде. Арбага чыгып утырганда, чыннан да, ник бер орынып торган күрше күренсен...

Ахыры киләсе санда.

КӘРИМ ТИНЧУРИННЫҢ КЕСӘ СӘГАТЕ

АСИЯ ЮНЫСОВА

Ай бу сәгать — ап-ак циферблат,
Ак җирлектә рим саннары.
Кем уйлаган аның иясенә
Гомер елын бик аз санарын.

Һәрбер сәгать вакыт символы ул,
Ә җиһанда вакыт олы сер.
Күкрәгендә кайнар йөрәк барда
Шушы сергә хуҗа режиссёр.

Елгыр сәгать угы ваемсыз ул —
Мизгел сәйләннәрдән ел туктый.
Театр дип янып-көйгән дәвер
Ашыктырып торган бу укны.

Алтатардан ядрә атылганда
Калкан булып йөрәк өстендә —
Яткан булса әгәр бу сәгать,
Ятим калмас иде бер сәнгать.

Явызлыктан койган тиле ядрә
Сәгатьләрен кыйган ул чорның.
Туктап калган гомер тынлыгында
Үлмәс исем яна — Тинчурин!

ЯҢА КИТАПЛАР



Галләм Р., Фәсхетдинов К.,
Әхмәдуллина М.
ГАСЫРЛАРНЫ КИЧКӘН НАЛАСА
/ Мөх.-төз. Исрафил Насыйбуллин. —
Казан: Ихлас, 2012. — 248 б.

«Өздереп гармун уйныйлар Наласа авылында...» кебек җитди, сагышлы, яки «Әй, Наласа, Наласа ла, Наласаны су баса....» кебек дәртле һәм шул ук вакытта ярымшаярулы бу шигъри юллар җир шарының теләсә кайсы кыйтгасында яшәп, татар рухын саклаучы барлык милләттәшләребезгә дә таныштыр, мөгаен. Ә чынбарлыкта нинди авыл соң ул Наласа, аның үткәне, бүгенгесе ничек? Авыл кайчан барлыкка килгән дә аның милләтебез тарихында урыны нинди? Бу сорауларга без «Гасырларны кичкән Наласа» исемле саллы хезмәтне укып белә алабыз.

Китапның I бүлеге Наласа авылының XVI гасыр башыннан алып 1917 елга кадәрге социаль-икътисади тормышын яктыртуга багышлана. Бу бүлектә авылны XV гасыр ахырларында билгеле бер социаль-икътисади сәбәпләр аркасында Нократ, Налису (Нәлисү) буйларыннан Казан, Арча тирәләренә күчеп кайткан кабиләләр нигезләгән дигән фикер әйтелә. Ә авылга икенче халык дулкыны 1552 елда Казан яулап алынганнан соң күченергә мәҗбүр булган. Наласа авылының XVI һәм XVII гасыр башына кадәрге тарихы Арча ягының Казан ханлыгы чорыннан ук мәгълүм булган Иске Ашыт, Иске Кишет, Түбән Оры, Урта Сәрдә кебек авыллар белән бер яссылыкта карала. Бу аңлашыла да, чөнки шушы дәвердә Наласа авылында да Казан арты авылларына хас булган процесслар барган. Бүлекнең кушымтасында авылдагы топонимнар, аларның тарихларын язуга да урын бирелә. Әби-бабалар сөйләгән легенда-риваятьләр язу-теркәү кенәгәләре, генераль ызанлау документлары, 1883 елда йорт хуҗалары, XX гасыр башындагы авыл сәүдәгәрләре һәм сәүдә нокталарының исемлекләре кебек документлар белән өлешчә дәлилләнә.

Л.Гобәйдуллин фотосы

Наласа авылы урамында XVI гасырның беренче яртысына караган (Казан ханлыгы дәвере) кабер ташы

Китапның II бүлеге Совет чорын һәм аннан соңгы ике дистә елны яктыртуга багышланган. Хәрби коммунизм сәясәте, ачлык, яңа икътисади сәясәтнең нәтиҗәләре һәм репрессия наласалыларны да читләтеп узмаган. Шулай ук авыл ир-егетләренең Ватанны саклап сугышуларын яктырту белән бергә, үгез җигеп, көн-төн кырда эшләүче хатын-кызларга да мәдхия җырлана. Өлкән буынның сугыш чорына нисбәтле хәтер-хатирәләре, истәлекләре материалны документаль яктан ныгыта, дәлилле итә. Узган гасырның икенче яртысында авыл халкының тырыш хезмәте, авылда төрле хуҗалык һәм социаль-көнкүреш корылмаларының саны арту, 1990-2000 елларда базар икътисадына күчү кебек вакыйгалар турында языла.

III бүлекнең тулаем 1917 елдан алып хәзерге көнгә кадәрге мәктәп тарихын яктыртуга багышлануы шактый урынлы, чөнки мәктәп — авылның йөрәге, аның рухи һәм матди тормышының үткәне һәм киләчәге. Бүлектә төрле елларда укыткан укытучыларның исемлекләре бирелә, мәктәп җитәкчеләренең тормыш юллары, укучыларның ирешкән уңышлары тасвирлана, хәтер-хатирәләр барлана.

IV бүлекнең Наласа авылында туып үскән күренекле шәхесләрнең тормыш юлларын һәм эшчәнлекләрен өйрәнүгә багышлануы да әһәмияткә ия. Чөнки тарихны кешеләр тудыра, ә тарих ул — дистәләгән биографияләр. Бу шәхесләр арасында милләтебез горурлыгы булган күренекле җәмәгать эшлеклеләре, галимнәр, төрле тармакларда атказанган хезмәткәрләр, орденлы колхозчылар, язучылар, көрәшчеләр бар. Кушымтада күпбалалы аналар, төрле елларда авыл советы хезмәткәрләре, күмәк хуҗалык җитәкчеләре һәм 2012 елның 1 апреленә авылда яшәүчеләрнең исемлекләре бирелә.

Төрле авторларның Наласа авылы турында язылган шигырьләре белән төгәлләнүе хезмәтне бизи, нур өстенә нур булып тора.

Дүрт бүлектән торган әлеге китапта авыл тарихы районда, республикада булган вакыйгалар фонында яктыртыла, ил күләмендә барган вакыйгаларның, чор проблемаларының наласалыларны да читләтеп узмавы авыл халкының истәлекләренә, тарихи чыганакларга нигезләнеп дәлилләнә. Наласа тарихында булган һәрбер вакыйга җентекле тасвирлана һәм анализлана. Без китапны укыганда, авылның икътисади яктан үсеш динамикасын, шуңа бәйле рәвештә халыкның тормыш-көнкүрешенең, яшәү рәвешенең яхшыруын, рухи дөньядагы

үзгәрешләрне, мәдәният, мәгарифнең алга китүен, кайбер тармакларда яңарышны һәм шул исәптән зур, бәяләп бетергесез югалтуларны да ачык күрәбез. Гомумән, һәр бүлек-бүлекчәдә диярлек икътисади һәм рухи дөньядагы үсеш белән бергә югалтуны да янәшә кую, авыл халкының ирешкән уңышлары аша укучыны сөендерү, югалтуларны тасвирлап, укучыда ачыну, сызлану хисләре тудыра алу — авторларның һәм төзүченең зур уңышыдыр, мөгаен. Фәннилек белән бергә әдәби башлангычларның бергә үрелеп баруы, тарихи сюжетларны образлы сурәтләү китапны укырга җиңеләйтә, гади халык өчен аңлаешлы итә.

Әмма 500 еллык Наласа тарихын яктырткан китапта авылның 1917 елга кадәрге тарихын тасвирлаган сәхифәләренә нибары 37 бит кенә бирелгән. Бу бүлектә, шактый урын алуларына да карамастан, ревизская сказка һәм метрикә кенәгәләрен, төрле XVIII-XX йөз башына караган документларны күбрәк бирү, XIX-XX йөз башы кабер ташы истәлекләрен, нәсел шәҗәрәләрен тәкъдим итү, аларга төплерәк анализ бирү фәнни яктан да, гамәли яктан да урынлы булыр иде.

Авыллар тарихын өйрәнү һәрвакытта да тарих фәнендә иң актуаль юнәлеш булып кала бирә. Яшь буынга үз төбәгенең, авылының ил тарихына керткән өлешен күрсәтү, аннан чыккан шәхесләрне, гореф-гадәтләрне һәм йолаларны өйрәтү милли горурлык хисе тәрбияли. Ә милли горурлыгы булган кеше, кайда гына яшәмәсен, беркайчан да үз илен, үз туган җирен онытмый, аны сагынап искә ала, сагынып кайта, туганлык хисләрен югалтмый һәм нәсел җепләрен өзми. Алар арасында, авылда төпләнеп калып, киләчәктә авыл икътисадын, мәдәниятен үстерүгә турыдан-туры өлеш кертүчеләр дә булыр. Урта буын кешеләре, бу китапны укып, анда үзләренең кылган гамәлләрен, тарихтагы урыннарын күреп, киләчәктә тагын да тарих битләренә язардай якты җыр калдырыр өчен көрәшерләр. Өлкән буын кешеләре өчен бу китап хәтер-хатирәне яңартырга, үткәннәрне сагынып искә алырга, китап сәхифәләрендә үз исем-фамилияләрен күреп, ачы күз яшьләре аша куанырга, шатланырга сәбәп булыр.

Республикабызда 500 еллык тарихы булган Наласа авылының үткәне һәм бүгенгесе турында китап язылу бик тә кирәкле һәм күтеп алынган гамәл иде. Республикабыздагы башка авылларның тарихлары да күбрәк өйрәнелсен һәм язылсын иде. Наласа кебек, тарих сәхифәләрендә якты эз калдырган, хәзерге вакытта да тормыш гөрләп кайнап торган авыллар бездә бихисап. Бу китап төбәкләр тарихын өйрәнүдә бер үрнәк булыр дигән өметтә калабыз.

Ленар Гобәйдуллин

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

15 АВГУСТ — АРХЕОЛОГЛАР КӨНЕ

Археологларның һөнәри бәйрәмнәре Болгар шәһәрендә тантаналы рәвештә узды. Бәйрәмгә археологларны котларга ТР Дәүләт киңәшчесе, ТР Тарихи һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу фондының попечительлек советы рәисе Минтимер Шәймиев килде, ул анда археологик эзләнүләрне тагын да масштаблырак итеп уздыру һәм барлык фәнни таләпләрне дә сакларга кирәклеген ассызыклады. Мәгълүм ки, Болгар шәһәрендә археологлар өчен эш җитәрлек, чөнки 400 гектар мәйданның бары тик 4 гектар җире генә фәнни яктан өйрәнелгән. Археологларның быелгы табышлары да куандырырлык: казу эшләре вакытларында Болгар, Алтын Урда дәверләренә бәйле йөзләгән предмет табылган. Алар арасыннан XIV гасырга караган 12 көмеш бизәнү әйбере игътибарны аеруча җәлеп итә. Бу табышлар, бер тапкыр чистартылып, тикшереп чыкканнан соң, Болгар музей-тыюлыгы фондларын тулыландырачак. Мәдәни чара вакытында археологлар, табылган әйберләрне җентекләп фәнни өйрәнү, китаплар чыгару өчен, Археология институтын оештырырга кирәклеген әйттеләр.

ДРАМАТУРГ ТУФАН МИҢНУЛЛИННЫ ИСКӘ АЛУ

25 август — драматург Туфан Миңнуллинның туган көнендә бер төркем татар зыялылары Яңа татар бистәсендәге зиратта әдип каберенә чәчәкләр куйды. Искә алу Кама Тамагы районында дәвам итте. Район үзәгендә Татарстан Республикасы язучылары катнашында Туфан Миңнуллин музее ачылды. Кунаклар Олы Мәрәтхуҗа авылында драматургның туган йортында булдылар, кичен Г.Камал театры артистлары «Гөргөри кияүләре» әсәрен сәхнәләштерде. Бер үк вакытта Кама Тамагында Салават башкорт дәүләт драма театры артистлары башкаруында Туфан Миңнуллинның «Әллә ялгыш, әллә язмыш» дип исемләнгән спектакле куелды.

V БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР ЯШЬЛӘРЕ ФОРУМЫ

27-31 август көннәрендә башкалабыз Казанда V Бөтендөнья татар яшьләре форумы үтте. Анда дөньяның төрле почмакларыннан 800 дән артык вәкил катнашты. Икенче көнне яшьләр «Татар яшьләре һәм Web 2.0», «Татар халкының тарихи мирасы һәм милләтне саклап калу юллары», «Бүгенге татар яшьләренең рухи кыйммәтләре», «Милли мәгариф һәм татар телен өйрәтүдә, саклап калуда яңа технологияләр» кебек секцияләрдә катнаштылар. 29 август көнне кунаклар «Милли татар брендлары: эчтәлеге һәм рәвеше» дигән темага дискуссия оештырдылар, Арча шәһәрендә «Кичке уен» бәйрәмендә (*фотода*) күңел ачтылар. 30 август көнне форум яшьләре Республика көне уңаеннан оештырылган мәдәни чараларда һәм «Авыл кызы» бәйгесенең финалында катнаштылар. Форум дөньяның төрле почмакларында яшәүче татар яшьләре өчен танышу, аралашу, күңел ачу, фикер алышу мәйданчыгы булды.

БОЛГАР ЦИВИЛИЗАЦИЯСЕ МУЗЕЕН ОЕШТЫРУ ТУРЫНДА КИҢӘШМӘ

3 сентябрь көнне Казан Кремлендә ТР Дәүләт киңәшчесе, ТР Тарихи һәм мәдәният һәйкәлләрен торгызу фондының попечительлек советы рәисе Минтимер Шәймиев Болгар цивилизациясе музее төзү турында киңәшмә үткәрде. Музей Болгар шәһәренең Елга вокзалы бинасының 2-5 катларында урнашачак. Булачак музейның экспозицияләр концепциясе Казан федераль университетының Тарих институты һәм ТР ФА Тарих институты галимнәре тарафыннан эшләнгән. Музей «Борынгы Болгарны ачу», «Болгар цивилизациясенең барлыкка килүе», «Борынгы Болгар», «Төбәкнең табигате» дигән бүлекләрдән торачак. М.Шәймиев тарафыннан Болгар цивилизациясе музееның экспозицияләре 2013 елның 1 июненә хәзер булырга тиеш дигән күрсәтмә бирелде.

БЕРЕНЧЕ ЯКУПОВ УКУЛАРЫ

4 сентябрьдә Россия ислам университетында беренче Якупов укулары булды. Ул Вәлиулла хәзрәт Якуповның туган көненә багышланды. Укуларда дин эшлеклеләре, дәүләт хезмәткәрләре, галимнәр катнашты. Алар тарафыннан дини укыту системасы, традицион ислам, толерантлык мөнәсәбәтләрен саклау кебек мәсьәләләр күтәрелде. Вәлиулла Якуповның фәнни-дини тәгълиматларын, мирасын системалы рәвештә өйрәнү, аларны җыентык итеп әзерләп нәшер итү зарурлыгы турында да сөйләштеләр. Шулай ук «Бүгенге җәмгыятьтә традицион ислам кыйммәтләре» темасын яктырткан иң яшь журналист мәкаләсе өчен Вәлиулла хәзрәт исемендәге премияне раслау, булачак музей проекты концепциясен әзерләү, Апанай мәчетендә истәлек тактасы кую кебек карарлар кабул ителде.